АКАДЕМИЯ НАУК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ИНСТИТУТ ЯЗЫКА, ЛИТЕРАТУРЫ И ИСКУССТВА
имени ГАЛИМДЖАНА ИБРАГИМОВА

Из сокровищницы научных экспедиций

# НАЦИОНАЛЬНО-КУЛЬТУРНОЕ НАСЛЕДИЕ

*Мамадыш*

КАЗАНЬ · 2017

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ исемендәге
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән

# МИЛЛИ-МӘДӘНИ МИРАСЫБЫЗ

## *Мамадыш*

КАЗАН • 2017

УДК 39(470.41)+008(470.41)
ББК 70(2Р354)
М48

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының
Гыйльми советы карарына нигезләнеп басыла*

**Редколлегия:**

***К.М. Миңнуллин** (рәис), **А.П. Иванов, Д.Б. Рамазанова, М.Х. Вәлиев, И.И. Ямалтдинов, Л.Х. Мөхәммәтҗанова***

**Төзүче һәм фәнни мөхәррир**
***М.Р. Булатова***

**М48** **Милли-мәдәни мирасыбыз: Мамадыш.** – Казан, 2017. – 344 б. – (Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән; уникенче китап).

ISBN 978-5-93091-211-1

«Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» дигән сериядә дөнья күргән чираттагы китап Мамадыш төбәгендә яшәүче милләттәшләребез, аларның гореф-гадәтләре, тел үзенчәлекләре турында бай мәгълүмат бирә. Бу җыентыкта борынгы ташбилгеләр, шәҗәрәләр, тарихи шәхесләргә багышланган язмалар да урын алды. Шулай ук анда җирле халыкның авыз иҗаты, җыр-моңнары, осталарның кул эшләре, авыллар тарихы белән танышырга мөмкин. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәренең тикшеренү-эзләнүләрен туплаган әлеге басма үз укучыларын табар һәм андагы язмалар һәркемдә зур кызыксыну уятыр, дип ышанабыз.

**ISBN 978-5-93091-211-1**

© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2017

## СҮЗ БАШЫ

Фән – халыктан, халык исә үз чиратында фәннән аерылгысыз. Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты – татарларның телен, әдәбиятын, халык иҗатын, музыкаль һәм тасвирый сәнгатен югары фән дәрәҗәсендә өйрәнә торган гыйльми-тикшеренү үзәге. Институт үзенең эшчәнлеге дәвамында татар халкының барлык этник төркемнәренең рухи һәм милли-мәдәни мирасын барлау, туплау һәм өйрәнүгә зур игътибар бирә. Тел, әдәбият, фольклор, сәнгать белеме үсеше өчен фәнни экспедицияләр уздыруның әһәмияте әйтеп бетергесез.

Халкыбыз яши торган төбәкләрдә узган экспедицияләрдә тупланган байлыкны китап итеп бастырып чыгару Институт тарафыннан традицион рәвештә башкарыла. Актаныш, Апас, Кукмара, Чүпрәле, Мамадыш һ.б. районнарга, Башкортстан, Мари Эл, Удмуртия Республикалары, Түбән Новгород, Курган, Оренбург, Омск, Самара һ.б. татарлар күпләп яши торган өлкәләргә оештырылган экспедиция материаллары, соңгы елларда гамәлгә куелган «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» исемле сериядә аерым китап булып басыла килә.

Иң зур байлык – халыкта. Бөек Тукай юкка гына: «Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул», – димәгән. Гасырлар дәвамында тупланган

тормыш тәҗрибәсе, зирәк акыл, тапкыр фикерләр, тәрбия алымнары, әхлак нормалары, күңел дөньясының, матурлыкның үзенчәлекле чагылышы, хәерле гамәлләрне аңлау-тоемлау рәвеше, дин, фәлсәфә, хәтер – болар барысы да тере формада халыкта яши, аның яшәү-көнкүреш шартларында реальләшә торган тиңсез хәзинә. Әлеге бәһасез олы байлык һәр дәвердә үсеш-үзгәрештә. Галимнең бурычы – әнә шул хәрәкәтнең кабатланмас чаткыларын, әһәмиятле мизгелләрен билгеләп калу, бөртекләп җыйнау, теркәү, өйрәнү аша мөһим ачышлар ясау, халыкныкын халыкка кире кайтару.

Мөселман һәм керәшен татарлары яши торган төбәк буларак, Мамадыш галимнәрне күптәннән кызыксындыра. Моннан 65 ел элек, 1948 елда, Институт (ул чактагы исеме – СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институты) Татарстанның Тәкәнеш районына (1963 елда Тәкәнеш районы Мамадыш районына кушыла) фольклор экспедициясе оештыра. Экспедициядә фольклорчы галимнәр Х. Ярми һәм Х. Гатина катнаша һәм Институтның фольклор фондына күп кенә материаллар туплап алып кайта. 1959 елдан башлап дүрт ел рәттән Мамадыш төбәген өйрәнергә Институтның тел белгечләре − диалектологлары килә, район авылларында эшли. 1973 елда бүгенге көндә филология фәннәре докторы, профессор М. Әхмәтҗанов Мамадыш якларына археографик экспедиция максаты белән юл ала һәм, кульязмалар җыю белән беррәттән, борынгы кабер ташларын да өйрәнеп кайта.

Мамадыш төбәгенә моңа кадәр фольклорчы, диалектолог, археограф, текстолог галимнәр тарафыннан ясалган игътибар үз нәтиҗәләрен биргән: җыелган материаллар эшкәртелеп, фәнни әйләнешкә кертелгән, төрле җыентыкларда, шул исәптән академик басмаларда урын алган, гыйльми күзлектән өйрәнелеп, алар нигезендә фәнни хезмәтләр язылган, гомумән әйткәндә, нократ татарларыннан җыелган рухи энҗеләр милли мирасыбыз буларак үз бәясен алган.

Алда әйтелгәнчә, 2013 елның җәендә Мамадыш районына Институттан янә бер комплекслы экспедиция оештырылды. Территориясе ягыннан ул Татарстанда иң зур административ берәмлекләрдән санала. Билгеле булганча, әлеге район – керәшен татарлары күпләп яши торган төбәкләрнең берсе. Керәшен татарлары − Идел буе − Урал яны татарлары составындагы этноконфессиональ төркем. Аларның күбесе татар теленең урта диалектында

сөйләшә. Татар халкының бай тарихлы әлеге этник төркеменең мәдәни мирасы, йолалары, кием-салымы, теле һ.б. үзенчәлекләре күп кенә галимнәр тарафыннан өйрәнелеп килә. Әлеге хезмәттә урын алган материаллар да шушы юнәлештә тагын бер адым булып тора.

Мамадыш төбәге татарлары урта диалектта сөйләшәләр, бередәге тел үзенчәлекләре фәндә казан арты мамадыш сөйләше һәм казан арты керәшен сөйләше дигән терминнар белән билгеләнә. Тел белгечләре (филология фәннәре докторы Ф. Баязитова, аспирантлар А. Гайниева, А. Хөсәенова) традицион культурага, гореф-гадәт, йолаларга караган текстлар нигезендә этнолингвистик материаллар тупладылар, җирле сөйләш үзенчәлекләрен ачыклау белән шөгыльләнделәр.

Эпиграфик һәм археографик мирасны өйрәнү буенча филология фәннәре кандидаты А. Гайнетдинов һәм аспирант Г. Нургатина эшләде. Халыктан борынгы кулъязмалар, ташъязма истәлек үрнәкләре җыелып, Институтның Язма һәм музыкаль мирас үзәгенә барлыгы 919 берәмлек материал тапшырылды. Алар арасында басма һәм кулъязма китаплар, дәфтәргә, аерым битләргә теркәүле иске язулар, кулъязма һәм басма шәмаилләр, документ кәгазьләр, фотографияләр һ.б. бар. Материаллар арасында мәгълүм шагыйрь Колмөхәммәднең шәҗәрәсе, моңа кадәр билгеле булмаган яңа әсәре табылуны аерым билгеләп үтәргә кирәк. Моннан тыш А. Гайнетдинов тарафыннан Түбән Ушма, Өчиле (Үсәли), Кече Кирмән, Түбән Тәкәнеш, Шәмәк, Көмеш Күл, Шәдче, Урта Шүләнгер, Түбән Шүләнгер,Түбән Сон, Кече Сон, Баскан, Олыяз, Ямаш, Түбән Козгынчы, Ишки, Түбән Яке авыллары зиратларында йөзгә якын таш өйрәнелде.

Фольклорчылардан филология фәннәре кандидаты, экспедиция җитәкчесе И. Ямалтдинов һәм филология фәннәре кандидаты, Түбән Ушма авылы кызы, доцент, бүгенге көндә филология фәннәре докторы Л. Мөхәммәтҗанова төп игътибарларын халык авыз иҗаты үрнәкләрен барлауга юнәлттеләр. Фольклорчы галимнәрнең халык вәкилләре белән әңгәмә корулары нәтиҗәсендә шушы төбәккә генә хас булган топонимик, тарихи һәм мифологик риваятьләр, хикәятләр, авыл тарихлары, мәкаль-әйтемнәр, җырлар, йола фольклорына караган үрнәкләр, халык уеннары, төрле ышануларга бәйле барлыкка килгән текстлар, бәетләр, мөнәҗәтләр, мәзәкләр, мәзәк хәлләр һ.б. язып алынды. Биш дистәгә якын

кешедән 300 гә якын авыз иҗаты үрнәкләрен язып алу, вакытында табылган якутлар кебек, гаять кыйммәтле табыш буларак бәяләнергә хаклы.

Сәнгать фәннәре кандидаты Э. Каюмова мөселман татарлары яши торган 20 авылда, керәшеннәр яши торган 6 авылда булып, музыкаль фольклорның бүгенге торышын барлады.

Л. Шкляева һәм И. Фәррахова гамәли сәнгать юнәлешендә эшләделәр.

Йортларның тышкы һәм эчке бизәлешенә игътибар юнәлтеп, сандык төпләрендә ята торган чигүле сөлгеләр, тастымаллар, карават җәймәләре, шәмаил үрнәкләре белән таныштылар, агач эше, милли киемнәр тегү һ.б. буенча эзләнүләр алып барып, этник мәдәният өлкәсен баета торган шактый кызыклы материаллар таптылар, барлыгы 100 дән артык информант белән очраштылар.

Әлеге китап үз эченә, 2013 елның җәендә уздырылган экспедициядән тыш, Институт галимнәренең Мамадыш якларына кагылышлы соңгы еллардагы кайбер башка эзләнү-тикшеренү материалларын да ала (филология фәннәре докторлары М. Әхмәтҗановның – эпиграфик язмаларга, археологик истәлекләргә, шәҗәрә һәм авыл риваятьләренә, Д. Рамазанованың – мамадыш сөйләшенә, Ф. Гарипованың – авыллар тарихына, И. Закированың – халык иҗатына, филология фәннәре кандидаты Г. Хаҗиева-Демирбашның ир-ат исемнәренә багышланган хезмәтләре).

Көмеш сулы Нократ буендагы гүзәл табигатьле Мамадыш халкының рухи чишмәләре мул икән. Мамадышлыларның борынгы тарихында, сөйләмендә чагылган төбәккә хас аһәңендә, буыннан-буынга тапшырыла килгән риваятьләрендә рухи тормышыбызның иң гүзәл бизәкләре чагыла. Районда җыелган бай һәм кызыклы мәгълүматлар шундый нәтиҗәгә килергә тулы мөмкинлек бирә, тупланган материалларга ясалган күзәтүләрдә дә нәкъ менә шул ассызыклана.

***Ким Миңнуллин,***
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институты директоры*

## БЕЗНЕҢ ИЛЛӘР – НОКРАТ ИЛЕ

*Марсель Әхмәтҗанов*

Мамадыш ягы – Татарстанның борынгы тарихлы төбәкләреннән берсе.

Тәүдә төбәкнең тарихына кагылышлы чыганакларны барлап үтик. Урыс миссионеры И.А. Износковның (1835–1917 елдан соң) 1882 елда Казанда басылган «Два реферата, читанные на IV-м археологическом съезде в Казани в 1877 г.» исемле хезмәтендә Мамадыш ягы авыллары тарихыннан кызыклы фактлар теркәлгән. Җирле тарихчылардан Габдулла Ушмавиның «Ушма тарихы» 1970 елда язылып, аның бер күчермәсе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана (99 кол., 1 тасвир, 176 эш берәмлеге). Шулай ук Үсәли тарихчысы Хәсәнша Әхмәтшинның (1892 елда туган) язма тарихыннан күчермәләр, Катмыш авылы тарихчысы Шаһи Сафин, Катмышта яшәгән мәрхүм Нигъмәтҗан Әхмәтҗанов язмалары да игътибарга лаек.

Татар эпиграфик язмаларын (кабер ташындагы язуларны) өйрәнгән галим Һарун Йосыповның да Мамадыш төбәгендәге тарихны ачуда искә алырлык хезмәтләре күп. Ул Татар Кирмәне, Түбән Яке, Бөрсет Сукачы авылларындагы XIV, XVI гасырлардан калган ташларны укып тикшерә.

Болардан тыш Мамадыш төбәгендә XVIII–XIX гасырларда яшәп иҗат иткән әдип-шагыйрьләрнең кулъязма әсәрләре дә тарихи чыганак булып хезмәт итә ала.

Төбәкнең иң борынгы тарихи чыганаклары дип елга атамаларын күрсәтергә мөмкин. Бүгенге Татарстан җөмһүрияте биләгән җирләргә III–IV гасырларда төрки телле сөн (һун) ырулары

килгәнлегенә Турай археологик истәлеге һәм Аксубай төбәге Кечкенә Сүнчәләй янында табылган һун казаннары дәлил. Сон елгасы исеме дә һун-сөннәрнең Мамадыш төбәгендә яшәүләренә ишарәли.

X–XIII гасырларда бу яклар Болгар дәүләте биләмәләренә әйләнә. Болгарларның бу төбәктә яшәвен раслаган тарихи чыганаклар шактый күп һәм ышанычлылар. Батый хан гаскәрләре 1236 елда Болгар дәүләтен яулап, аның урынына Болгар олысы ясый. Олыс үзәге булып корылган Болгар шәһәрен тәүдә Батый хан 1242–1249 елларда үзенең башкаласы итә, Түбән Иделдә Сарай шәһәре төзелгәч, үзәкне шунда күчерә. Батый хан яуларыннан соң Урта Иделдә болгар кавемнәре, кайберәүләр фикеренчә, юкка чыкмаган, алар яшәп калганнар. Болгар өлкәсе Алтын Урда дәүләте олысына әйләнгәч, яулап алу җәрәхәтләре чагыштырмача тиз төзәлгән: Нократның югары агымыннан алып хәзерге Батраки шәһәренә, Зөя елгасыннан Уфа шәһәре астына кадәр киң мәйданда болгар мөселманнарының кабертaшлары сакланган. Ул ташлар XIII гасыр ахыры – 1359 еллар арасында эшләнеп, язылып куелганнар. Билгеле, таш яздырып кую өчен халык кулында мал да булырга тиеш. Гаҗәп ки, бик бай дип саналган борынгы Болгар дәүләтендә 1236 елгача бер кабер ташы яздырып куярлык та кеше булмаган. XIV гасырның беренче яртысында яздырып куелган болгар телендәге ташлар Мамадыш төбәгендә ике урында бар. Татар Кирмәне авылы янында – 9 таш, Түбән Яке янында бер таш сакланган. Менә ул таштагы язу:

> «Бисмилләһи әр-рахмани әр-рәхим.
> Әл-хөкем Аллаһ, әл-гали, әл-кәбир.
> Көлли нәфсе диакати
> Әл-мәүвте сәм әлинә тәрҗигун, тарих җийат җүр
> Әл виҗем җал, шәүвәл вон бийалем көн вафат
> Былыт Минаҗ ул...
> Бәлүики рәхмәт Аллаһ...
> Рәхмәти вәсигати...»

*Тәрҗемәсе:*

«Куәтле һәм рәхимле Аллаһның исеме белән. Бөек һәм зур Аллаһның хөкеменә, һәр туган җан әҗәл ширбәтен эчәр һәм Аллаһ каршына килер. Тарихтан җиде йөз илле өченче ел, шәүвәлнең

унбише көнендә вафат булды Минһаҗ улы... билгесе. Аллаһның рәхмәте... киң рәхмәте булсын».

Таш, димәк, 1352 елның 25 ноябрендә куелган. Болгар мөселманнарының теле татар телебезгә аз охшаган, аны, чуваш теленә якын, диләр. Ләкин ул чуваш теле дә булып җитмәгән.

Татар Кирмәне зиратында болгарларның һиҗри белән 737 (миладн – 1336), 738 (1337), 740 (1340) һәм Түбән Яке авылында 741 (1340) елларда куелган, шундый ук телдә язылган вафат тарихлары бар. Болар Нократ иделе буйларында бу заманда инде мөселманнарның тирән тамыр җибәргән булуын күрсәтәләр. Тагын шуны да искәртү зарур: бу ташлар сакланган урыннардагы борынгы авылларның исемнәре башкача булган. Әүвәлге болгар авылларының исемнәрен белү хәзер мөмкин дә түгел инде.

XIV гасырда, бөтен Урта Иделдәге кебек, Нократ елгасы буе халкы да татарлашып бетә. Моның сәбәбе – XIII гасырдан башлап, Нократ елгасы буйларына көньяктан төрки-татарларның күчеп килүе була. XIV гасырда Иделнең түбән агымындагы татарлар, бигрәк тә шәһәр халкы, җәй җитүгә, Урта Иделгә күтәрелә торган була. Чөнки Идел буендагы яшел болыннар, урман һавасы бу якларны оҗмах почмагы ясаган. Балык Бистәсе төбәгендә Кама (Чулман) елгасы буенда урнашкан Бирдебәк һәм Кадрәк авылларының килеп чыгышларын бәян иткән риваятьләрдә әйтелгәнчә, ул җирләргә җәйләү өчен Бирдебәк хан күчеп килә торган булган. Ул үзенең туганы Кадрәк хан белән тау башына зур учак ягып, төтен чыгарып хәбәрләшеп яшәгән (Бирдебәк авылыннан 1904 елда туган Хөснетдин Шәмсетдин улы риваяте буенча).

XIV гасырның 60 нчы елларыннан башлап Нократ (Вятка) елгасы Урта Идел буена Бөек Новгородтан төшүче ушкуйниклар юлына әйләнә. Ушкуйниклар зур сугыш көймәләрендә Нократ елгасы буенча төшкәннәр. Бу елганың исемен дә шуларга бәйләп, «Новгород» сүзен татар теленә җайлаштырып, Нократ елгасы дип атаганнар. Нократ буйларына чагыштырмача соң килеп чыккан марилар да Нократ суын «Наугрaл видче» дип исемләгәннәр. Бу мисалда «Новгород»ның «Нократ»ка әйләнү тарихын тагын да ныграк ачыклана.

Нократ елгасының болгарча ничек аталган булуын кистереп әйтерлек чыганаклар юк кебек. 922 елны гарәп сәяхәтчесе Ибне Фадлан Урта Иделгә килгәндә Ватыг исемле елганы кичүләрен яза.

Бу елганы Татарстанның Болгар шәһәре янында аккан хәзерге Утка елгасы дип хисаплыйлар. Минемчә, бүгенге Вятка елгасы да шулай ук Ватыг исемен йөрткән. Хәзер удмуртларның бер этник төркеме дип саналган бисермәннәр, әле XIX гасырда да Җүкәтау шәһәре тирәләрендә яшәп, Болгар олысы халкының бер өлешен тәшкил иткәннәр. Нәкъ менә шулардан Нократ елгасы атамасы Ватыг, Ватка (Вятка) рәвешендә урыс теленә кереп калган. Бисермәннәр мөселман булып, аларның шактый өлеше татарлашып та киткән. 1360 елда Бөек Новгородтан ушкуйниклар килеп Җүкәтау шәһәрен талыйлар. Урыс елъязмасы бу хакта «ушкуйниклар Жүкәтауны сугышып алдылар, бик күп татарларны үтерделәр», дип хәбәр итә. Шушы һөҗүмнән соң Җүкәтау бикләре Алтын Урда мәмләкәте башкаласы Сарайга яклау сорап баралар.

Сарай хөкүмәте, хәлне төзәтү өчен, Болгар олысына 1361 елда Булат Тимер бикне юллый. Ул Болгар олысын нығыту чарасына керешә. Булат Тимер Нуган бик улы Болгар олысы идарәчесе Җанибәк хан (1343–1357) тарафыннан ук билгеләнгән булган. Моны 1366 елда Болгар шәһәрендә сугылган тәңкә раслый. Шул елда урыс ушкуйниклары һәм кенәзләренең яулары яңадан башлана. Алар Нократ һәм Кама буйларына бөлдергеч һөҗүмнәрен кабатлыйлар. Төп болгарлар шушы һөҗүмнәр вакытында тар-мар ителеп, татарлар белән тәмам берләшеп, кушылып бетүгә йөз тоталар. 1367 елгы урыс кенәзләренең берләшкән һөҗүме вакытында Болгар олысы тагын тар-мар ителә. Булат Тимер Сарай тарафына кача һәм анда тәхеткә менгән яңа хан Газиз тарафыннан үтерелә.

1369 елны Болгар олысын Хәсән Солтан идарә итә башлый. Аңа урыс кенәзләренен 1369, 1370, 1371, 1374, 1376, 1377 елларда туктаусыз ясаган һөҗүмнәрен татырга туры килә. Урыс елъязмалары Нократ, Кама һәм Идел буенда гел татарлар хакында гына сүз алып баралар, болгар халкы кенәзе түгел, ә Болгар олысы кенәзе (биге) хакында гына сөйлиләр. Урыс елъязмаларында болгарларның халык буларак теркәлмәве Урта Иделдә 1360 елдан соң бары татар халкы гына яшәгәнлеген раслый. Дөрес, урыс кенәзләренең Казанга, Җүкәтауга, Кирмәнчеккә һөҗүмнәре вакытында бик күп татарларны һәм бисермәннәрне кырып салулары хакында хәбәр бар. Бисермәннәрнең Нократ буенда яки Каманың сул ягында да XIV йөздә яшәү ихтималлары бар. Аларның теле удмурт теленең бер диалекты булып хисаплана. Каманың сул ягында археологлар

угыр кабиләләренә нисбәтле археологик истәлекләр ачканнар иде. Бисерманнәр шул угыр кабиләсенең варислары булса кирәк. Татарлар аларны «почырманнар» дип атыйлар. Бу «почырманнар» бүгенге көндә дә Киров өлкәсендә һәм Удмурт Республикасында нократ татарлары белән янәшә авылларда яшиләр. Бисерманнәрне иске документларда «чуаш» дип атау очраклары да бар. Почырманнарда (бисерманнәрдә) ислам дине йогынтысы булганлыгы аларның мөселман фамилияләре йөртү очракларыннан күренә.

1367 елда Венеция шәһәреннән чыккан итальян галимнәре Доминико һәм Франциско Пициганилар Алтын Урда дәүләте биләгән җирләрне картага төшерәләр. Бу картада Кама буенда Карманчухо (Кирмәнчек) һәм Сакатин (Җүкәтау) шәһәрләре барлыгы да күрсәтелгән. Алардан Җүкәтауның хәзерге Чистай шәһәре зонасында, ә Кирмәнчекнең Нократ иделе буенда булганлыгы фараз ителә. Кирмәнчек хәзерге Татар Кирмәне авылы тирәсендә булып, әле авыл янындагы XIV гасыр кабер ташлары Кирмәнчек шәһәренә нисбәтле булганга охшый. Шәһәрнең исеме төрки-татар теленә нисбәтле сүздән гыйбарәт. Димәк, аның корылуы – төрки-татарлар эшчәнлеге җимеше. Әүвәлге Алтын Урда җирләрендә ул дәверләрдәге татар теленнән ясалган берничә «кирмән» атамасы катнашкан топоним мәгълүм: Аккирмән (Одесса), Кременчуг, Янги Кирмән, Хан Кирмән, Таш Кирмән һ.б.

Мамадыш төбәгенә XIV гасырның соңгы чирегендә, Идел буыеннан Аксак Тимер яулары узу сәбәпле, Кама аръягыннан һәм хәтта Кырым, Кара диңгез буйларыннан татарларның күчеп килүе көчәя. Аксак Тимер тарафыннан 1391, 1395 елларда Идел буена ясалган походлар вакытында Болгар һәм Биләр кебек шәһәрләр дә җимерелә. Халык телендә Биләр шәһәреннән Нократ буена күчеп килүчеләр турында риваятьләр шушы дәверләрнең тарихи авазы булса кирәк. Менә шундый тарихлардан бер сәхифә: «Түбән Сон авылындагы Шәпи картның әйтүенә караганда, Кама аръягындагы Биләр тирәсеннән бер хатын өч улы белән Каманың бу ягына күчеп чыккан. Ул малайларның берсе Түбән Сонга, берсе Кече Сонга, берсе Югары Сонга (Сон суының уң ягына) килеп утырганнар».

Ләкин бу хәбәрләр, авыллар бер кешедән генә үсеп киткән, дигән фикергә китерергә тиеш түгел. Моның мисалы Кече Сон картлары хәбәрләрендә күренә. Менә 1902 елда туган Могътәсиб Мөкъмин улы риваяте:

«Кирмән янына, суның теге ягына, башта җиде бабай килеп утырган. Соңыннан алар, бик юл өсте, дип, узгынчылар борчуыннан туеп, бу якка күчеп утырганнар».

«Кече Сон кырында ханнар булган. Алар өч хуҗалык булып Кече Сонга кайтканнар. Тагын Чүчи карчык булган. Ул "Чүчи башы" дигән җирдә яшәгән. Аның кабере янында чишмә чыккан». Бу сүзләрне Кече Сонның мәрхүм Гыймади карт сөйли торган иде.

Икенче бер информатор сөйләгән риваять:

«Кече Сон элек "Иске авыл" дигән җирдә Әркәнәй елгасы буенда урнашкан булган. Анда су булмагач, бу урынга күчкәннәр. Алар дүрт хуҗалык булганнар. Берсе – Рим, икенчесе – Сәйпеш... Иске авылдан Туктатыл, Әптелмән, Тиктормас исемле бабалар күчеп утырганнар».

«Иске авылдан беренче булып Солтан исемле карт килеп утырган. Иске авылдан алар җиде хуҗалык булганнар. Солтан бабай чишмәсе дә бар» (Миңнегали Гыйльманов сүзләре).

Миңнегали Гыйльманов укытучы булып эшләгән. Аның кулында авыл тарихы буенча язма булып, Сабада укыган вакытында югала. Аның сүзләрен 1921 елны туган Кыям Салиховтан ишеттек. Язма тарихта тагы, Чәүчи изге кыз була, Чәүчинең атасы хуҗа була, дип әйтелгән (хуҗа дип Алтын Урда дәверендәге югары катлау аристократиясенең бер төркем вәкилләрен атаганнар).

Түбән Сон авылында 1895 елда туган Мөхәммәтҗан Хөсәеновтан 1973 елның 31 августында язып алынган хәбәрләрне укып үтик:

«Бүләрдән килгән Габдерахман бабай бу якта урын сайлап, йоклап караган, тыныч урынмы икән дип. Яман төшләр күрми генә тыныч йоклаган һәм монда авылга нигез корырга булган. Габдерахман су чатына килеп йорт салган. Ул елга буенча йомычкалар агып килгәнне күргән, югары якта да авыл бар икәнен белгән.

Габдерахман бабай Бүләрдән килгән вакытларда монда урыслар да килеп авыл кора башлаган булалар, ләкин Бүләрдән мөселманнар күпләп килә башлагач, урыслар, урыннарын ташлап Дегетле авылына китеп урнашалар. Урыслар, килгәндә, Теләүле чишмәсе янында багана утыртып, аңа тәре беркетеп калдырганнар. Шунлыктан хәзер дә ул чишмәне Теләүле чишмәсе дип йөриләр». XIV гасыр ахырында Болгар, Биләр шәһәрләрендә олыс биге булып Габдулла хан торган. Чыгышы белән Кырымнан килгән, Җүчи нәселеннән булган Габдулла хан (Кара бик) 1395 елгы яу вакытында Аксак Ти-

мер тарафыннан үтерелә. Аның балалары һәм аларга буйсынган кешеләр Казанга һәм Нократ җирләренә күчеп утыралар. Габдулла ханның улы Гали бик үтерелеп, Казанда аның урынын Мәхмүдәк хан ала. Гали бик тарафдарлары Нократ елгасы буйларында тупланыбрак калалар, ләкин үзәкләре Нократның югары өлешендәге Карино (Кара) авылы санала.

Нократ буйларына Габдулла хан карамагындагы күп татар ырулары килеп урнаша. Аларның исемнәре авыл атамаларында сакланып калган: Нократ буендагы Шөн, Шөнбашы, Иске Җөрек (Йөрек) һ.б. Бу дәвердә Нократ буена мәшһүр Идегәй нәселләре дә килеп утырган булуы Габдулла Ушмави тарихында сакланган. Аннан аңлашылганча, Идегәйнең Котыш (Габделкотдус) исемле улы каядыр Ушма авыллары тирәсендә урнашкан була. Нократ буйлап төшкән урыс ушкуйниклары Котыш авылына да һөҗүм итәләр. Идегәй би балалары белән ушкуйниклар арасында канлы сугыш булып, Котыш һәм башка татар авыллары туздырыла, яндырыла. Татарлар соңыннан яңа авыллар төзеп яши башлыйлар. Котыш авылы хатирәсенә ел саен Котыш җыены оештырып, үзләренең кан-кардәшлек тойгыларын яңартып, искә алып торалар. XIV–XV йөзләрдә Нократ буендагы татар ырулары бу дәвердә Кама аръягында оешкан Нугай урдасы татарлары белән аралашып яшәгәннәр. Шунлыктан Нугай урдасы идарәчеләренең Нократ буена дәгъвалары зур була.

Урта Кирмән авылында яшәгән, 1889 елда туган Шәмсениса әбинең 1973 елның 6 сентябрендә сөйләгән риваяте бу җәһәттән шактый кызыклы:

«Безнең авыл “Кала тавы”ннан килгән, аның исеме Хан Кирмән була (*башка бер информатор әйтүе буенча “Хан Гермән”*). Кала тавында хан патшасы торган. Шуат чокыры буенда хан кальгасының кирпечләре таралып яткан, халык аларны мич чыгарырга һәм башка максатларда ташыган.

Бер заманны Түбән Кирмән авылы урынына урыслар килеп утыра, икенче яктан чуваш, чирмешләр, арлар килә башлаганнар. Арташка арлар килеп утырган, Нормага чувашлар килеп утыра. Шуат чокыры янында чувашларның Теләү чишмәсе була. Чувашлар шул чишмәгә барып күзләрен юмасалар, сукыраябыз дип ышанганнар.

Шундый ят кавемнәр аралашып килеп утыргач, хан патшасы әйткән: “Әй балалар, безнең монда ар, чуаш, урыс килеп тулды,

безгә яңа тыныч урын табарга кирәк", – дип. Һәм ул бер ун кешене Казан ягына җибәрә. Җибәргәндә әйтә: "Тигез, матур җир табыгыз, тапкач, өч тапкыр шобага салыгыз, кемгә шобага төшсә, шуны тереләй җиргә күмегез" – дигән. Теге кешеләр Кабан күле буена барып җитеп, урынны бик ошатканнар һәм шобага салганнар. Шобага өч рәт хан малаена чыккан. Хезмәтчеләр хан малаен кызганып, ул урынга эт күмеп кайтканнар. Шуннан кайтып ханга күренгәннәр. Хан сораган: "Нигә унау кайттыгыз?" – дигән. Тегеләр әйткәннәр: "Шобага өч рәт синең улыңа чыкты, аны кызганып, ул җиргә эт күмеп кайттык", – дигәннәр. Хан: «Эт урынына ырлашып, мәче урынына тырманып яшәрбез инде алайса», – дигән.

Шуннан соң хан патшасы яңа урынга күчеп китә. Яңа җирдә ханның хатыны үлә. Ул яшь хатынга, Чимбикәгә өйләнә. Чимбикә безнең Кирмән авылыныкы булган. Чимбикә бик матур кыз була. Аның матурлыгын урыс патшасы да ишетә һәм аңа яшерен хат яза. Чимбикә урыс патшасы белән яшерен хат языша башлый. Хан бу эшне сизә һәм кайгысыннан үлеп китә. Хан үлгәч, болар тагын да языша башлыйлар. Урыс патшасы Чимбикәнең рәсемен соратып ала һәм аңа рәсем аша гашыйк була, Чимбикәгә үзенә кияүгә чыгарга тәкъдим ясый. Чимбикә әйтә: "Мин сиңа чыгармын, тик син җиде төндә, кеше күрмәгәндә, җиде катлы мәчет сал", – ди. Урыс патшасы бөтен осталарны җыеп бу эшне эшләтә. Чимбикә уйга кала хәзер, мин моңа кияүгә чыксам, динсез булам бит, ди. Чимбикә патшага әйтә: "Инде хәзер, син мәчеткә баскычлар да яса инде, минем югарыдан менеп карыйсым килә", – ди. Чимбикә "карыйм" дип мәчет башына менеп китә һәм шуннан сикереп төшеп үлә.

Чимбикәнең атасы Ядгәр ханны Кирмән зиратына күмгәннәр диләр. Әүвәл заманда күмгәндә кешенең башын гына кисеп алып күмә торган булганнар».

Бу – XVI гасырда Нугай урдасы татарлары арасында Сөембикә турындагы тарихның бер версиясе. Димәк, Сөембикәнең язмышы турында халыкта төрле легендалар таралган булган.

Мамадыш ягындагы борынгы Райхан авылы хакындагы риваятьтә аны Гәрәй (Сафа Гәрәй) хан исеме белән бәйлиләр.

Бер генә татар авылы да, Урта Кирмән авылы легендасындагыча, Сөембикәне үзенеке итеп санамый. Шунлыктан Урта Кирмәннең Сөембикә белән бәйләнеше бар. Бу очраклы хәл түгел, чөнки

алда китерелгән легендада Идегәй балаларының Ушма тирәсендә булган Котыш авылында яшәгәнлеге сөйләнде. Сөембикә үзе дә Идегәй би балаларының кызы була.

Мамадыш төбәгенең XV–XVI гасырларда Нугай урдасы татарлары белән нык бәйле булганлыгын башка авылларның риваятьләре дә сөйли.

Мәсәлән, Баскан авылы тарихы (риваяте) Казан ханлыгы дәверенә карый. Риваятьтән күренгәнчә, авылның исеме Акчура була. Бу авыл ике бабадан башланган: Сәли һәм Имәнкол. Акчура авылын урманнан чыгып юлбасарлар баскан. Шуннан аның исеме «Баскан» булып китә. Ләкин Акчура авылы (Баскан) иске урында калмый яңа урынга күчеп утырган. Минемчә, ул урын Бөрсет Сукачы авылы булса кирәк. Монда һиҗри буенча 946, милади буенча 1539–1540 елда куелган, Казан дәвереннән калган бер кабер ташы бар. Ул ташның тарихы (догалары алынмады) түбәндәгечә:

«Тарих тукыз йөз кырык алтыда, зөлхиҗҗә аенда Карач углы Карачура дарел-фәнадин дарел-бәкая рихләт (*күчте*)». Бу таштагы тарих белән Акчура авылы арасындагы кардәшлек бәйләнеше булырга охшый. Карач(ж) исеме дә кызыклы. Теләче төбәгендә Карачты (Яңа Җөри) исемле авыл бар. Гадәттә, Казан ханлыгы дәверендәге авылларның шактые этнонимнардан һәм аларны биләгән морзалар исеменнән алынган була.

Еники Чишмә авылы халкы телендә: «Безнең авыл Чистай ягындагы Змеево авылы булган җирдән килгән. Еники Чишмә авылы морзалар нәселеннән. Авыл кешеләре патша хөкүмәте заманында, әүвәлге морзалык грамотасын үзләренә яңа властьтан морзалык хокукын кайтаруны сорыйлар да теркәп, ләкин аларга морзалык хокукы бирелми».

«Югары Бөрсетнең күпчелек халкы Әҗикә баба нәселеннән. Безнең бабаларыбыз морзалар булган. Алар хәзерге Владимир авылы (керәшен татарлары авылы) белән ике арада җир тотканнар. Иван Грозный татарларны чукындырып йөргәндә морза бабайлар аръякка, Кама ягына киткәннәр. Чукынгач, Владимир авылы халкы морзаларны куган. Идел буендагы Панаука Җөри авылының җире була. Колышчы авылы элек татар-мөселман авылы булган. Карамалы авылы элек урыс авылы булган. Өчиле (Усали) авылы җире безнең морза бабайлар җире булган. Безнең морза бабайның исеме Корбангали (Корби), ул ялгыз калган. Югары Бөрсетнең төтенен

күреп, бу авылга килгән. Корби бабай сигезенче буын морза нәселе булган. Корби бабайның шәҗәрәсе ут чыгып янган. Морзаларның карталары була, алтын белән язылган. Ул язулар татарча да, урысча да булмаган. Мамадыш ягында Ушма авылы морза авылы, Алкиннар да морзалар булганнар». Бу риваятьләр 1973 елда Корби нәселеннән Мәүлә Мөгаллим хуҗа улы (1897 елда туган), Әҗикә нәселеннән Мөхәммәтҗан Габдерәфикъ улы (1899 елда туган) сөйләүләре буенча язып алынды.

Кече Бөрсет авылы Болгар шәһәреннән килгән мукшылар авылы булган. Бу бик кызыклы факт, чөнки бүгенге Шәһре Болгарда сакланган XIV гасыр татар төрбәсендә мукшы хатыны күмелү факъты археологларга мәгълүм.

Отарка исемле авылда ханнарның мал яба торган урыннарының эзе сакланган.

Казан ханлыгының соңгы елларында Мамадыш төбәге ханлыкның чик буе районына әйләнә. Урыс дәүләте 1489 елда Казан кулындагы Вятка (Хлынов) шәһәре тирәләрен үзенә куша. Нократның югары өлешендәге татарлар урыс дәүләтенә хезмәткә күчәләр. Алар Казан ханлыгына каршы Мәскәү коралына әйләнәләр. 1550 елдан башлап Казан ханлыгын Мәскәү һәм аның тарафдарлары – Касыйм ханлыгы, Нократ солтанлыгы, өлешчә Нугай урдасы камап ала. Нократ елгасы буенда Нократ (Вятка) татарлары Казанга каршы һөҗүмдә катнаша башлыйлар. Алар мари урманнары аркылы Ашыт һәм Казанка буендагы татар авылларына аулар оештыралар, аларны талыйлар. 1551 елның июнь аенда Казаннан чыгып киткән Сафа Гәрәй хан тарафдарларына, Нократ аша кичкән чакта, һөҗүм ясыйлар: Бәхтияр Җүҗин җитәкчелегендәге вяткалылар Кошчак углан җитәкчелегендәге 300 кешелек отрядны тар-мар итәләр. 46 угланны, шул исәптән Кошчак угланны (Сөембикәнең таянычын) тоткын итеп Мәскәүгә озаталар. Мәскәүдә әсирләрнең барысын да асып яки башын чабып җәзалап үтерәләр.

1552 елда Казан шәһәре Явыз Иван гаскәрләре тарафыннан җимерелгәч, татар халкына карата рәхимсез геноцид сәясәте уздырыла башлый. Әсирләрне төркем-төркем итеп урыс дәүләтенең төньяк өлкәләренә тараталар, төрмәләргә утыртып җәзалыйлар. Чукынырга теләмәгән татарларны бәкеләргә батырып үтерәләр.

Яулап алучылар авылларны калдырмыйлар, бөтен бер дәүләтне вәхшиләрчә туздыралар. Боларны Идел буена Батый ясаган поход

нәтиҗәсе белән чагыштырып та булмый. Батый хан яулары үтеп 40 ел да узмый, Болгар олысындагы шәһәр һәм авылларда тормыш кайный башлый. Зөя буеннан Уфа елгасына һәм Нократның югары өлешеннән Самарага хәтле җирләрдә халык кулында мал туплану билгесе булган кабер ташлары куела башлый. Ә 1552 елдан соң элекке Казан ханлыгы җирләрендә икътисади җанлану фәкать 1680–1700 еллар арасында (120–130 елдан соң) гына булып ала, аннан инде XIX гасырның икенче яртысында гына рәткә керә.

Мамадыш төбәгендә бу дәверләргә караган риваятьләргә 1552 елдан соң ничек итеп аз сандагы халыкның авыллар кора башлавы, чукындырылу, төп татар җирләренә урыс, чуваш, мари (чирмеш), ар халыкларының вәкилләрен утырту, азатлык өчен көрәш темалары килеп керә. Шушы тарихи вакыйгаларның Мамадыш төбәгендә ничек тасвирланганын түбәндәге риваятьләрдән укып белә алабыз.

Аларның берсе – Югары Бөрсет авылы риваяте.

«Авыл хәзерге урыннан бер чакрым читтә Коры Кыерлы дигән урында урнашкан була. Башта ул өч кенә йорттан тора. Бер мәлне бу авылдан Бохарай исемле кеше урманда җиләк җыеп йөргәндә адашып, бик шәп ага торган чишмә янына килеп чыга. Бохарай чишмәне ошатып авылына кайтып сөйли, әйдәгез, шунда күчик, ди. Авыл халкы аның сүзен кабул итеп, шул чишмә янына күчеп килләләр. Чишмәне Бохарай чишмәсе дип атыйлар.

Югары Бөрсеттән чакрым ярым җирдә Кече Бөрсет исемле авыл бар. Владимир (Чиялек) авылы керәшен татарларының мөселман бабалары шул авылда торганнар. Шунлыктан Владимир авылын Кече Бөрсет дип тә атап йөргәннәр. Чиялек татарлары чукындырылганчы балыкчылык белән шөгыльләнгәннәр. Шул чакларда алардан өч кеше аерылып, Бөрсет Сөкәче авылын нигезләгән. Елга Бөрсет исемле булып, алар балыкны сөкә белән тота торган булалар.

Албай авылы мөселман татарлар авылы булган. Аны көчләп чукындырган вакытта бер өлеш халык аннан күчеп киткән. Шундыйлардан Югары Бөрсеткә Әҗикә баба, Корби (Корбангали) морзалар күчә. Албай авылында мөселман калмый. Албайда курыккан, буйсынган татарларның чукынырга риза булганнары Әбде авылындагы поптан хач (тәре) алып кайталар.

Чукындыруның рәвешләре төрлечә була. Казанны алганда әсир төшкән кешеләрнең бер ише чукыну бәрабәренә исән калдырыла.

Шуның мисалын Мамадыш төбәгендә бүген урыс авылларына әйләнгән Нагашево (Нугай), Тау Иле, Чаксы авыллары тарихында күрәбез. Урыс миссионеры И.А. Износков мәгълүматларыннан аңлашылганча, «Мамадыш өязендәге Нагаш (Нугай) һәм Чаксы авылларын татар ханы Нагаш (Нугай) Казанны урыслар яулап алганчы ук салган була. Урманчы авылын шулай ук кайсыдыр бикнең кул астында булган татарлар корганнар.

Бу авыллар тирәсендә Бик тавы исемле тау бар. Чистай өязендәге Түбән һәм Югары Кондрат авыллары (алар хәзер дә Чистай районына карыйлар, бу авылларда татарлар белән чувашлар яши), моннан өч йөз еллар элек, ягъни Казан мөстәкыйль булган дәвердә, Төркестаннан күчеп килгән Туркан морза тарафыннан салынган булганнар. Бу авылларның исемнәре Казаратым (Кадаратым) исемле мөселман изгесенең атыннан калган имеш».

Бу мисалда Нократ буенда һәм Чистай тирәләрендә Нугай татарларының утраклыкка күчү очраклары чагыла. Кондрат исеме татар һәм башка кыпчак халыкларында булган Коңгырат кабиләсе исеменең бер варианты гына булса кирәк.

«Омар һәм Благовещенское авылларында бүген урыс халкы яши. Бу авылларны Уразбахты авылы татарлары салган булган. Уразбахтыны әлегә кадәр Иске Омар дип тә атыйлар. Урыслар бу якларга XVI гасырның икенче яртысында яки XVII гасыр башлагрында күчереп утыртылалар. Бу урыслар Казан митрополитларының коллары була. Омар авылына урыслар килеп утыргач, андагы татарларның бер өлеше башка җирләргә күчеп китәләр, ә Омарда калганнары урыслашып бетәләр. Омар авылындагы Полутатаринов, Тахтаров, Зиндеев, Кулущеев, Инусов, Басалаев, Алакаев, Булыгин, Сапаров, Мансуров, Сулеменов фамилияләрен йөрткән урыслар бар да татардан азган халык».

Мамадыш төбәгендәге Тау Иле авылында да элек татарлар яшәгән. Бу авылның татарлары Питрәч төбәгенә караган Татар Тау Иле авылына күчеп утырганнар. Тау Иле авылында татарлар яшәгән заманда кирпечтән салган мәчет тә була. Тик аның кирпеч ташларын урыс халкы үз ярагына ташып бетергән. Риваятьләргә карагандa, татарларның Тау Иленнән китүенә бер поп сәбәпче була. Поп коега тәре ташлый да, бу урын изге урын, менә коедан тәре чыкты, дип ялганлап, татарларны кудырта. Бу хәлне Тау Иле урыслары теленнән ишеткәннәр.

Нократ буе урыс кул астына кергәч, анда татарларны бик каты җәберләгәннәр. Шуңа да карамастан, Казан ягындагы кайбер татарлар Мамадыш төбәгенә качып килеп урнашканнар.

Явыз Иван заманында имана салымы ике тиен көмеш булган. Шуны түләмәгәннәрне төтенле мунчага ябып җәзалаганнар. Ясак түләгәннәр Түбән Сонда калган, түли алмаганнары чукындырылып, Колышчы авылына аерып утыртылган.

Катмыш авылына, телләрдә йөргән риваятьләргә караганда, берничә кеше Түбән Сон авылыннан күчеп килә. Килгән кешеләр Шыгым, Шыкма, Шыкмат исемле бабалар булалар. Катмыш авылындагы суның катылыгын күреп, бу авылга алар Катмыш исеме кушканнар. Катмыш халкы борын-борыннан Иделдә бурлак булып көймәләр сөйрәп йөргәннәр. Алар белән бурлак йөргәндә, бер чукынмаган Әлтирүк исемле чуваш та ияреп кайта. Катмышта Әлтирүк ислам динен кабул итеп, монда яшәп кала. Бу кеше Гыйбадулла исемле кешегә эшләп йөри һәм аның кызына өйләнә.

1720 еллар тирәсендә Катмыштан җиде хуҗалык китеп, Ык буендагы Катмыш исемле янә бер авыл коралар. Алар арасында Акай батыр дигән кеше дә була.

Урыс Кирмәне авылы моннан 350 еллар элек (XVII гасыр уртаеы) корылган. Алар сал агызучылар, бурлаклар булган.

«Урта Сон авылын Чискал, Япал, Миңнегол бабайлар нигезләгән. Авыл халкы нигездә өч нәселдән тора: Җәгъфәр, Фаяз, Чискал нәселләре.

Пугачев вакытына кадәр Урта Сон урынында мукшы авылы була. Сугыш вакытында мукшы авылы туздырылып, Кыерлыдан югарыда искә алынган бабалар килеп утыра. Җәгъфәр белән Фаяз тату яшиләр, бик эшчән булалар. Күп җирләрдә ышна ачып икмәк үстерәләр. Керәшеннән мөселман булган Чискал боларны талап тора. Шуннан соң Җәгъфәр белән Фаяз балалары берләшеп, Чискалны акылга өйрәтергә уйлыйлар. Чискалның юлы елга аша салынган басмадан үтә торган була. Аны сагалап торалар да суга бәреп төшерәләр. Шуннан соң Чискал талап ашаудан туктый» (1885 елда туган Мөбарәкҗан Әхмәтсафа риваяте).

Казанны урыс алгач, кала тирәсендәге татар авылларын яндырып бетергәннәр. Казанга 30–40 чакрым җирдә татарлар авыл ясап утырырга тиеш булмаганнар. Шул дәвердә Казан янындагы Чирмеш исемле авылның исән калган халкы, Мамадыш ягындагы бер елга

буена килеп, Алман дигән авыл кора. Алман кешеләре елгага төшеп бата башлагач, Ишмөхәммәт (Ишке) исемле кеше яңа урынга күчеп китә. Бүгенге Шәмәк һәм Тау Иле авылларының бабалары хәзерге Татарстанның Тау ягыннан күчеп килгәнгә охшый. Чөнки анда да Шәмәк һәм Тау Иле исемле бер-береннән әллә ни ерак булмаган авыллар хәзер дә бар. Тау ягыннан Казан артына күчү XVI–XVIII гасырлар буе дәвам иткән.

XVII гасырга кергәч, Нократ буеның Казанны алган чакта туздырылып, кешеләре аз калган җирләрен үзләштерү дәвам итә. Патша хөкүмәте Мамадыш төбәге җирләрен Нократ морзаларына, Вятка урысларына, Тау ягыннан килгән чувашларга, мариларга, арларга бүлгәләп бирә. Татардан гайре милләт вәкилләренең күбесе шушы дәвердә килеп төпләнеп калганнар.

Мамадыш шәһәре урынына Мамадыш баба дигән кеше килеп утырган. Аннан монахлар килеп, үгез тиресе хәтле генә җир бир, дип сорыйлар да, Мамадыш баба бирергә була. Монахлар үгез суеп, тиресен туныйлар, аны нечкә итеп телеп, бик зур җирне әйләндереп алалар. Шул урынга чиркәү салалар. Мамадыш баба җирсез кала.

Түбән Ушмага башта Айбулат, Максыд, Биктимер, Юлтимер, Мамадыш, Атнаш исемле кешеләр килеп утыра (Түбән Ушмада 1887 елда туган, 1973 елда Олы Әтнә авылында яшәүче Өммегөлсем апа безгә үзенең шәҗәрәсен яздырган иде: Өммегөлсем, атасы Исхак, бабасы Хәсән, аның атасы Мөхәммәтҗан, аның атасы Биккенә, Биккенә атасы Бикбау, Бикбауныкы Атнаш, Атнашныкы Мамадыш).

Югары Ушманы икенче исем белән Морза дип, шулай ук аны урысча Ярмаково дип тә атаганнар. Аннан аңлашылганча, Югары Ушма авылын Ярмәк морза биләгән икән. Бу хакта түбәндәге риваять тә кызыклы:

«Югары Ушмага иң беренче булып Ярмөхәммәд (Ярмәк) исемле морза килеп утырган. Ул бик бай кеше була. Авыл тирәсендәге сазлык урманнарны бетереп, колларыннан көтүлекләр эшләткән ул җирләрдә. Авылны шуңа “Морза авылы” дип йөрткәннәр күрше авыллар, ә урыслар “Ярмак” дип атаганнар. Нократ буенда яшәгән Кара бик нәселе шәҗәрәсендә Йәрмәк морза исемле кеше бар. Кара бикгән таралган морзалар Арча, Биектау, Кукмара, Саба, Алабуга, Әгерҗе төбәкләрендә җирләр алып утырганнар». Шунлыктан Югары Ушманы нигезләгәч, Ярмәк морзаны да шушы нәселгә нисбәт

итәргә җирлек бар. Бу авылда 1973 елның 7 сентябрендә булганда, шушында 1902 елда туган Хәлимә апа Исламованың нәсел шәҗәрәсен язып алган идек: Хәлимәнең атасы Исхак (1924 елны 58 яшьтә үлгән), аның атасы Ислам, Исламның атасы Мөхәммәтҗан, Мөхәммәтҗанның атасы Рәхмәтулла, Рәхмәтулланың атасы Котлыбай, Котлыбайның атасы Йуашбик, Йуашбикнең атасы Туйгилде, Туйгилденең атасы Исламкол морза, Исламколның атасы Рахманкол морза, Рахманколның атасы Йәрмәк морза. Йәрмәк морза Югары Ушманы нигезләгән Йәрмәк морза исеме белән туры килә. Бу нәселнең бабаларының исемнәре Нократтан чыккан Кара бик нәселе шәҗәрәсе исемнәренә тәңгәл. Әлбәттә, телдән әйтелү сәбәпле бабаларның, буыннарның тәртибе беркадәр буталган һәм аерым буыннар төшеп калган. Кара бик шәҗәрәсен, мәсәлән, Рахманкол морзаның атасы Морат морза, Моратның атасы Ибраһим морза, Ибраһимның атасы Йәрмәк морза, Йәрмәкнең атасы Дусмөхәммәт морза, Дусмөхәммәтнең атасы Пәйке морза, аның атасы Биги бик, аның атасы Чуаш бик, аның атасы Әлсуфый, аның атасы Гали бик, аның атасы Кара бик белән тәмамлана.

XVIII гасырның башларыннан Кара бик нәселеннән булган Нократ морзалары, патша хөкүмәте алдындагы хезмәтләре өчен, Казан ханлыгыннан калган җирләргә хуҗа итеп утыртылалар. Бу нәселдән булган морзалар: Бәйке, Ырпыс, Әҗкә, Туйхуҗа, Уразай, Тукай, Йамаш, Чынбулат, Җанбулат (Йанбулат) һәм башкалар хәзерге Арча, Әтнә, Балтач, Кукмара, Мамадыш, Алабуга, Әгерҗе төбәкләрендәге авылларга нигез салалар.

Шушы вакытларда Мамадыш төбәгендәге Ямаш авылын нигезләгән Ямаш морзаны Кара бик нәселеннән дип уйларга урын бар. Ямаш морзаның шәҗәрәсе Шиһабетдин Мәрҗанинең «Мостафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» исемле китабының икенче томында (Казан, 1900, 334–335 бб.) бәян ителә. Лаеш ягында Айтуган бине Җамаш яшәгән. Җанбулатның (Янбулатның) Ашыт елгасы буендагы Чынбулат авылын нигезләгән бертуганы була (Чынбулат хәзерге Әтнә төбәгенә керә). Бу Чынбулат авылын халык «Чымбылат» рәвешендә әйтә. 1973 елның 19 июлендә археологик экспедиция вакытында минем үземә Чынбулат авылында булырга һәм аның тарихына бәйле кайбер фактларны язып алырга туры килгән иде:

«Чымбылатка башта Чымбылат һәм Тымбылат исемле ике кеше килеп утырган, диләр. Шуннан Чымбылат исеме калган авылга.

Чымбылат авылы өч нәселдән таралган. Баштагы икесе бик дус булган. Берәү соңыннан, Яңа Шашы авылыннан күчеп килеп, Болак янына утырган. Чымбылат авылының бабалары моннан 300 еллар элек Нократ ягыннан килгәннәр. Аларның беренчеләре арасында Әбҗәли баба булган. Нократта Чымбылат нәселе бар. Әбҗәли баба шул нәселдән булса кирәк. Ул чукындырудан качып килгән, диләр. Тымбылат, Чымбылатны калдырып, Мамайга киткән (Чымбылат янындагы авылга).

Нократ нәселе булган Нургали (1900 елда туган), аның атасы Хәсбиулла, аның атасы Хәмидулла, аның атасы Галимулла, аның атасы Хәбибулла һ. б.»

Әлеге мәгълүматлар Ямаш морзаның Нократтан килгәнлегенә дәлил булып хезмәт итә.

Шәҗәрәдәге 7 нче буынның 14 нче урынында торучы Исмәгыйль Апанай Хафиз улы, Лаеш ягындагы Җанбулат авылыннан килеп, Казанның Иске Бистәсендә гомер иткән, 1794 елда үлгән. Казанда алар нәселеннән чыккан күп кенә күренекле кешеләр мәгълүм. Әйтик «Азат халык» газетасы мөхәррире Габдулла мулла Апанаевны, беренче тапкыр кыллы оркестр оештырган Вәли Апанаевны, диңгез офицеры Габделхәмит Апанаевны, миллионер Бәдретдин Апанаевны һ.б.ны искә алып үтәргә мөмкин.

Инде кабат Мамадыш төбәгенә, Нократ буйларына әйләнеп кайтыйк һәм XV–XVIII йөз вакыйгаларына тукталыйк.

Мамадыш төбәгенең Тәкәнеш тирәләрендә тарихи мәгълүмат алырлык кешеләр аз очрады. Алар биргән мәгълүматлар түбәндә бәян ителә.

«Тәкәнеш авылы урыны элек сазлыклы, елгалар белән араланган булган. Монда Кабык Күпер исемле авылдан кешеләр килеп, Дегет базы дип йөртелгән җиргә йортлар корганнар. Тәкәнеш тугыз нәселдән үскән. Иң зур нәсел – Сәлтинеке, ярты Тәкәнеш шул нәселдән. Аннан кала Эти нәселе зур.

Югары Тәкәнешнең зират урынына башта ике карт килеп утырганнар. Алар канаулар казып, суларны агызып, сазлыкларны киптергәннәр. Йортлары яныннан агып үткән елга суындаерактан агып килгән йомычкаларны күреп, анда да авыл барын белгәннәр».

Вахит авылы урынын Макчим дигән чирмеш биләгән була. Вахит исемле кеше килеп, Макчим белән җирен алыша. Макчимнан калган авылны Иске Макчим яки Ямаш дип йөртәләр. Ямаш мор-

за турында язган идек инде. Бу авылда Ямаш яшәсә дә, аның балалары монда калмый, башка урыннарга күчүләре аңлашыла. Ямаш үзе дә Иске Макчим дигән авылда торып калмаган ахры, хәзерге Балык Бистәсе төбәгенә күчеп, анда да Ямаш исемле авыл корган. Аннан ерак булмаган Янбулат (Җанбулат) авылы аның улыныкы була. Иске Макчим авылыннан күренекле татар галиме Шәмсетдин Күлтәсинең бабалары чыккан.

Югары Козгынчы авылы хәзерге урыныннан чакрым ярымга читтәрәк урнашкан була. Ул – бу тирәдәге иң борынгы авыл. Иске зираты бар, ләкин язулы ташлары юк. Бу авылның урманында Явыз Иван заманында качып йөргәндә үтерелгән кешеләрнең каберләре бар, дип сөйлиләр. Кыраул зиратында иске язулы ташлар бар.

Түбән Козгынчы авылы элек «Чыршы арты» дип аталган. Кыраул Әбдедән күчеп килгән. Тимершәех бабаның аталары биш буын элек Киләй дигән авылдан күчеп килгәннәр. Түбән Козгынчылар Югары Козгынчыдан күчкән дигән сүз дә бар халык телендә.

Мамадыш төбәгеннән Пугачев хәрәкәтендә катнашучылар күп булган. Катмыш авылыннан атаклы татар батыры Бәхтияр Канкаевның көрәштәше Рахманкол чыккан. Бу шәҗәрә Рахманкол бабаның нәселеннән булган Нигъмәтҗан бабайның 1880 елдагы кульязмасыннан алынды: Нигъмәтҗанның атасы Әхмәтҗан, Әхмәтҗанның атасы Габделхалик, аның атасы Габдерәшит, Габдерәшитнең атасы Рахманкол.

Бәян ителгән тарихларга күз салсаң, бер нәтиҗә чыгарырга мөмкин: Нократ буйларында XVII гасыр ахырынача татар халкына тынычлап яшәргә мөмкинлек булмый. Ушкуйниклар, Казан дәүләте егылу, көчләп чукындыру сәясәте Мамадыш төбәге тарихында канлы сәхифәләр булып язылганнар.

Нократ елгасының югары агымы буендагы татарларны урыс боярлары XVII гасырда яшәгән урыннарыннан төрле якка күчереп тараталар, алар урынына урысларны күчереп утырталар. Мәсәлән Удмуртиядәге Нократ Аланы (Вятские Поляны) районындагы Иске Пенәгәр авылы Нократ буеннан куылып, Кукмара поселогы кырына күчеп утырган. Нократ елгасының югары агымында утырган Карино (Нократ) авылы тирәсендә татарлар бик аз санда кала. Шул дәверләрдән ул тирәләрдәге татарларның бер җыры сакланып калган. Аны язып алган укытучы Н. Касыймов җырны «Кистем татарлары җыры» дип атаган.

Безнең илләр бу ил түгел,
Безнең илләр – Нократ.
Киттек, инде кайталмабыз,
Сез калдыгыз бик ерак.

Ага саллар, ага саллар,
Ага саллар еракка.
Сал өстендә ага маллар,
Еракка, Нократка.

Аръяк бит ул, ерак бит ул,
Бара-бара арыйсың.
Татар кызларын тапмагач,
Ар кызларын карыйсың.

Нократның түбән агымында татарлар катламы көчле булган, азмы-күпме яңа элементлар килеп кушылса да, үзләренең телләрен нык саклаганнар. Килеп утырган татарларның этник тарихында төркиләрнең угыз кавемнәре нык катнашкан. Угыз теленең үзенчәлекле авазы булган сакау «з» авазын куллану да шуңа бер дәлил.

XVII гасырда Нократ буена килеп утырган татарларның борынгы ыру-кабиләчелек бәйләнешләре чагылышы булган «җыеннар» яңадан җанланып, яңа төсмерләр өстәлеп яши башлый. Бүгенге көндә җыен бәйрәме тәртипләрен начар беләләр инде. Халык телендә калган җыен исемнәре: Котыш җыены, Комазан җыены, Кирмән җыены, Тукташ җыены, Ызлан җыены, Шүләнгер җыены, Төенчек җыены һ. б.

Яшьләр, кара-каршы тезелешеп басып, «Илекле» дип аталган җәйге күңел ачулар уздырганнар.

XVIII гасырга аяк баскач, Мамадыш төбәге, бөтен Идел буе, Урал шикелле үк, татар халкының милли азатлык көрәше мәйданына әйләнеп китә.

1735 елны Кама аръягында чукындыруга, көчләп урыслаштыруга каршы Акай явы башлана.

Тарихи чыганаклар Акайны татар диләр. Оренбург якларында колонизаторларның күп кенә ныгытмаларын туздырып, Акай гаскәре Минзәлә кальгасы тирәләрен тар-мар китерә. Пьяный Бор янында Кама елгасын кичеп, Акай яулары Казанга таба юл тоталар. Казанга җитәргә 30 чакрымнар җирдә Акай явы урыс гаскәрләреннән җиңелә. Акай тарафдарлары чигенәләр. Мамадыш янында Нократ елгасын кичкәч, аларның эзләре югала.

1773–1775 елларда Мамадыш төбәге халкы Пугачев яуларында катнаша.

Тарихи документларда Югары Бөрсет авылыннан йөзбашы Әҗикәйнең полковник Бәхтияр Канкаевка җибәрелгәне языла. Югары Бөрсеттә Әҗикә бабаның нәселе һаман да дәвам итә. Омар авылы крестьяннарының Бәхтияр Канкаев отрядына кушылганда теркәлгән исемлекләре сакланган. Шулай ук Мамадыш төбәгендәге Дегетле, Әрнәш, Котыш, Покровское авыллары кешеләренең Бәхтияр Канкаев отрядында булулары билгеле.

XIX гасырның беренче яртысында Алкин фамилияле борынгы морзалардан килгән нәсел Ушма авыллары янында Алкин авылын нигезли. Алар әүвәл Уфа ягында яшәгәннәр. Уфа якларына исә XVII гасырның беренче яртысында хәзерге Мордовия Республикасы биләгән җирләрдән күчеп килгәннәр. Уфа ягында Алкиннарның чура-коллары була. Казан университетын тәмамлаган Шаһиәхмәт Алкин ул колларны, Ушма авыллары яныннан җир сатып алып, күчереп утырта. Ул полковник дәрәҗәсендә була, белеме ягыннан – юрист. Шаһиәхмәт Алкин үзе Казанда яши. Аның улы Сәедгәрәй Алкин (1867–1919) XX гасыр башында Казанда күренекле җәмәгать эшлеклесе, нашир була. Алкиннар татар мәдәнияте тарихында да эз калдырган нәсел. Аларның Казанда хәзерге Тукай урамындагы йортында (ул йорт хәзер дә төзек) 1903 елда беренче мәртәбә татар сәхнә тамашалары уйнала башлый.

Сәедгәрәй Алкин Казанда татар телендә 1905–1911 елларда «Казан мөхбире» исемле газета чыгара. Ул, Казан университетының юридик факультетын тәмамлаган адвокат буларак, Казан мөселманнарының дини ихтыяҗларын яклап берничә мәртәбә Петербургта була. Казан шәһәр думасында гласный (депутат) хезмәтен башкара. Газета чыгаруда аңа Акчуриннар да ярдәм итә. Абруйлы адвокатны беренче Дәүләт Думасына сайлыйлар. Дума мөнбәреннән Сәедгәрәй Алкин урыс, француз телләрендә эчтәлекле докладлар сөйләгән, аз җирле крестьяннарның мәнфәгатен яклаган. Беренче Дума куып таратылгач, Выборгка барып, Думаны куып таратуга протест чагылышы булган Өндәмәгә кул куючыларның да берсе ул була. Бу эше өчен патша хөкүмәте аны өч ай төрмәдә тота, ике ел ярымга юристлык хокукыннан мәхрүм итә. Шунлыктан Сәедгәрәй Алкин икенче, өченче Думаларга депутат булып сайлана алмый. Урыс түрәләре татардан ачык фикерле, гадел, телләр белгән

депутатлар булуын теләмәгәннәр. Сәедгәрәй Алкинның сеңлесенең кызы Мәдинә әйтүенә караганда, ул кеше Казанда 1919 елда үлгән булса кирәк.

Мамадыш төбәгенең узган гасырларда эз калдырган шагыйре, педагог һәм философ Кол Мөхәммәд бине Солтанбик әл-Ушмави әле соңгы елларда гына җәмәгатьчелеккә мәгълүм булды.

Кол Мөхәммәд иҗаты XIX йөз татар әдәбияты тарихында мөһим урын били, киләчәктә аның шигъри мирасы өйрәнелергә лаек.

XIX йөздә Мамадыш төбәгеннән чыккан күренекле мәгърифәтчеләрдән Шәдче авылы имамы Җамалетдин Бикташины күрсәтергә кирәк.

Кайбер мәгълүматларга караганда, XIX гасыр ахырында татар календарьлары төзеп чыгара башлаган Шәрәфетдин Кәшәфетдин улы Шәһидуллин да Мамадыш ягындагы Шәмәк авылында 1870 елларда туган булган.

Мамадыш төбәгенең Кече Сон авылы белән тагын бер татар язучысы, мәгърифәтче Таҗетдин бине Ялчыголның (1768–1838) бәйләнеше бар. Ул 1785 елның 24 маенда чит илдән кайтышлый Кече Сон авылында атасын дәфен кыла (җирли).

Мамадыш төбәгенең, Нократ буе татарларының этник-сәяси тарихын – гомум татар халкының этник тарихының көзгесе дип карарга мөмкин.

# ӨЙРӘНЕЛГӘН ТАШ ШОМАРЫР, ОНЫТЫЛГАН ТАШ МҮКЛӘНЕР

*Айдар Гайнетдинов*

Мамадыш районына институтның иң беренче фольклор экспедициясе 1948 елның ноябрь аенда оештырыла. Аны атаклы галим Хәмит Ярми җитәкли. Экспедициядә аның хәләл җефете Халидә Гатина да катнаша. Институт хезмәткәрләре ай буе, яуган карларга, яңгырларга карамыйча, халык авыз иҗаты әсәрләрен җыеп йөриләр. Нигездә, алар Никифорово (Чия башы) авылында эшлиләр һәм шактый күп кенә фольклор материалларын туплап алып кайталар.

Ул елларда безнең хезмәткәрләргә фольклор әсәрләрен тупларга ярдәм иткән бер кеше дә онытылмаган – исем-фамилияләре теркәлеп куелган, һәрберсенең сөйләп, җырлап күрсәткән, бүләк иткән халык авыз иҗаты әсәрләре институтыбызның Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана.

Институтта эшләүче танылган галим Марсель Әхмәтҗанов 1973 елда Мамадышның үзендә һәм районның күп авылларында булып, 600 гә якын борынгы кулъязма таба, шуның белән беррәттән борынгы кабер ташларын да өйрәнеп кайта.

1980 елда Нәҗип Исмәгыйлев (Нәкъкаш) Кыраул (Сарбаш-Пустошь), Кече Сон, Өчиле (Үсәли), Түбән Яке, Алан авылларына бара һәм беркадәр археографик материал таба.

Шулай ук тел белеме галимнәре дә берничә мәртәбә Мамадыш районының күп кенә авылларында диалектология буенча материал җыеп кайталар.

1948 елдан соң Институт галимнәренең Мамадыш районына халык авыз иҗаты, ә 1980 елдан бирле археографик материал җыю

өчен чыкканнары булмады. Анда бару өстебездә фарыз гамәл кебек торды. Ниһаять 2013 елның 10 июнендә шул якларга юлга чыктык.

Шуны да әйтергә кирәк, безнең фәнни экспедициябез комплекслы иде: анда фольклор, археография, тел, сәнгатькә караган материалларны җыючылар катнашты.

Эшне Түбән Ушма авылыннан башладык һәм ялгышмадык та. Өйдән-өйгә кереп сораштыра торгач, шунда ук, дүрт кульязма китап табылды. Аларның икесе гарәп грамматикасына кагылышлы, өченчесендә төрле догалар, аларның хасиятләре турында язылган, дүртенчесе җыентык рәвешендә тупланган. Соңгысы бигрәк тә кыйммәтле табышлардан санала, чөнки анда шагыйрь Колмөхәммәд бине Солтанбәкнең 1812 елда гарәп теленнән иҗади тәрҗемә итеп язылган «Нәсаих мәнзумә» һ.б. әсәрләре китерелә. Аларны әдипнең туганы Нигъмәтулла бине Мөхәммәдсафа Солтанбәков үзенең кызы укысын өчен 1902 елның 14 ноябрендә күчереп язган булган. «Нәсаих мәнзумә» әсәреннән бер өзек:

*«Йир йөзендә ничә төрле гыйбрәтләр вардыр сиңа,*
*Ач күзеңне гыйбрәтилә назарыңны сал аңа.*
*Наим ирүр гафләтилә адәм углы дөньяда,*
*Уйгануы ул гафләтдин бәгъдәл-бәгус гукъбәдә».*

Җыентыкта шулай ук көйләп уку өчен «Бәдәвам», «Көйле иман», «Көйле намаз» һ.б. шундый дини әсәрләр күп китерелгән, прозадан «Тәгъбирнамә» урын алган.

Бер китапта көннәр турында кызыклы гына язмалар бирелгән. Анда атнаның һәр көне ни эшләү өчен килешә, уңышлы була икәнлеге тәфсилләп язылган. Мәсәлән, шимбә көнне нәрсәләр эшләү өчен бик яхшы: «Шимбә көн – ауга чыкмак, йорт гыймарәт итмәк, сәфәр чыкмак, кан алдырмак, дәва кылмак, хәҗәт теләмәк, никах итмәк».

Хәзерге заманда һәр авылда кульязма китап табу – ул бик сирәк күренеш. Гадәттә, аларның төшеп калган битләре яки аерым кәгазь битләре генә табылып, шулар белән канәгатьләнергә дә туры килгәли. Түбән Ушма авылында да шундый 28 кульязма бит таба алдык. Ул битләрдә, бу авыл электән үк бик дини авыл булганлыктан, бик күп догалар урын алган. Алар арасында ниндиләре генә юк: «Нурнамә», «Догаи мәрҗан», «Исме әгъзам», «Салават» һ.б. Язмалар арасында шигъри формада язылган бер кызыклы авыз ачу догасы игътибарны җәлеп итте:

*«Руза тоттым ният белән,*
*Авыз мин ачтым нигъмәт белән,*
*Ходай биргән дәүләт белән».*

Бүгенге көндә шул рәвешле авыз ачучылар бармы икән әле? Чөнки хәзер бер дини китапта да мондый төр шигъри догаларны очратып булмый. Бу бик тә кызганыч, дин әһелләре, традицион догаларга игътибарны арттырабыз, дип күпме генә сөйләсәләр дә, боларына әһәмият биреп җиткермиләр.

Халык авыз иҗатына караган әсәрләр дә табылды. Мәсәлән, «Ана мөнәҗәте» шундыйлардан:

*«Тугыз ай күтәреп йөрдем, егерме ике ай сөт имездем,*
*Бу ни гаҗәб, бу ни хикмәт, баладин катылык күрдем».*

Моннан тыш «Аятел-көрси», «Хуш килдегез», «Өземтә» һ.б. мөнәҗәтләр бар.

Бу авылда басма китаплар да табылды. Әмма аларның күбесе тулы түгел иде: йә башы юк, йә ахыры юк, дигәндәй. Шуңа күрә андый китапларны без күп җыймадык. Беренчедән, аларда басылган әсәрләрнең тулы вариантлары Институт архивында күп саклана инде, икенчедән, кешеләр үзләре ул китапларны өйләрендә кадерләп сакласа, әби-бабалардан калган, татар халкы мирасына караган истәлекләргә карата мәхәббәт, хөрмәт, сакчыл караш арта. Киләчәк буын аларны үз өйләрендә изге нәрсә кебек кадерләп кенә сакланганнарын күреп үссә, бу рухи кыйммәтләрне хөрмәтләүгә юнәлдерелгән тәрбия чарасы булып хезмәт итәргә мөмкин. Шул сәбәпле, борынгы басма Коръән китапларын да, хәтта тулы булса да, бик яхшы сакланып, яңа кебек күренсә дә, без бөтенләй җыймадык. Бу изге китап һәр мөселман йортында сакланырга тиеш.

Шулай да чагыштырмача тулырак күренгән түбәндәге китапларны алып кайттык: «Кальгаи хәйбәр», «Шәрх «Гайнел-гыйлем», «Алты бармак» һ.б. Шундый төр китаплардан әби-бабаларыбыз үгет-нәсыйхәтләр укып тәрбияләнгәннәр.

Икенче көнне Түбән Ушма авылында алган яхшы тәэсирләр белән Өчиле (Үсәли) исемле авылга юл тоттык. Әлеге авылны халык «өч өйле» дигән сүзләрдән ясалган дип саный. Авылга нигез салучылар итеп өч кешене атыйлар: Юнысай баба, Биги баба һәм Тукай баба. Алар бу җирләргә килеп урнашып үзләре һәм гаиләләре өчен өч өй салалар һәм яши башлыйлар. Башка халык шуларның

өйләрен күреп, «өч өйле» дип йөртә башлаган, соңрак, сүзләре бераз үзгәреп, «Өчәли» (Өчиле, аннан Үсәли) формасына әйләнгән имеш.

Борынгы кулъязмалардан бигрәк, безне бу яктагы борынгы биналар таң калдырды. XIX гасыр ахырында төзелгән волость конторасы, XX йөз башында салынган мәчет, элекке кибет, шәхси йортлар, хәзерге китапханә бинасы – барысы да архитектура истәлекләре булып саналырга хаклы. Мәчетне төзегәндә, аны төзүче осталар тарафыннан кайчан салынуын белдереп, ап-ачык итеп, бер кирпечкә гарәп графикасында, кабер ташларындагы шикелле, «1909 нчы елда» дип, уеп язылып куелган.

Үсәли авылында берничә кулъязма китап та табылды. Беренчесендә гарәп телендәге «Китабе Кафия», татар телендәге «Китабе Әбү Шахма» һ.б. хезмәтләр урын алган. Палеографик билгеләре буенча ул XIX гасыр ахырына карый. Шулай ук «Кисекбаш китабы», төш юрау, тән тартмак хакында язылган ике борынгы кулъязма китап та игътибарга лаек.

Кулъязма битләргә килгәндә, 30 дан артык аерым битләр табылды. Алар арасында мөһер-шәриф догасы бар. Дини әдәбияттан тыш, мөнәҗәтләр, хатлар да очрый.

Басма китаплардан уңдык дип әйтергә мөмкин, чөнки барлыгы 14 басма китап табылды: «Китаб әл-лөбаб» (гарәп телендә), «Рәхәти дел», «Кисекбаш китабы», «Рисаләи Газизә», «Догаи исме әгъзам һәм башка шәриф догалар», «Китабе рисаләти фил-җәнаиз», «Хасияте дога кәнҗел-гареш», «Гайнел-гыйлем», «Мәүлиденнәби» һ.б. Бер басма Коръән кып-кызыл тукыма белән төрелеп эшләнгән.

Бөрсет-Сукачы авылында кулъязма китаплар очрамаса да, 62 кулъязма бит табылды. Аларда төрле догалар, мөнәҗәтләр, җырлар, төш юраулар, хатлар, шәҗәрәләр, кыйссалар һ.б. язылган.

Бер мөнәҗәттән өзек тә китереп узыйк:

*«Анадин тугса угланлар,*
*Хәзерләрләр шәриф исемен,*
*Гомер бетеп, әҗәл җитсә,*
*Керер гүргә газиз җисемең.*

*Адәм баласының өч туе,*
*Аның берсе исем туе,*
*Икенчесе никах туе,*
*Өченчесе үлем туе.»*

Җырлардан мисал:

*«Уфа тавы, Уфа тавы,*
*Уфа тавы түгәрәк,*
*Яннарыңа барыр идем,*
*Булсам сары күбәләк.*

*Безнең турда салкын чишмә,*
*Җиләк пешә ярында,*
*Миннән артык түгел әле*
*Сөя торган ярың да».*

Шуның белән беррәттән, XX йөзнең урталарында күчерелгән Коръәннең «Йасин» сүрәсе язылган ике кулъязма дәфтәр дә таптык. Димәк, бу якларда Коръән сүрәләре күчерү традициясе әле XX гасырда да дәвам иткән һәм актив булган.

Басма китапларга да тап булдык: гарәп телендәге «Тәгълим әссаләһ», «Мохтасар Кудури», «Китаб әл-әнмүзәҗ» хезмәтләре һәм Коръән мәгънәләренең татар телендәге «Тәфсир фәваид» исемле тәрҗемәсе.

Авыл зур булса да, археографик материал, башка авыллар белән чагыштырганда, бераз азрак булды. Шулай да 1 кулъязма китап («Исагуҗи» хезмәте), 29 кулъязма бит, 20 басма китап, 1 басма бит, 2 кулъязма дәфтәр, 1 кулъязма шамаил табу бәхетенә ирештек. Басма китапларны санап үтик: «Рисаләтер-рахмәтия фи бәяниләрагыя», «Догаи исме әгъзам һәм башка шәриф догалар», «Шәраител-иман», «Хөтбәи Адәм хасиятьләре берлән», «Ходай Тәгаләнең мең дә бер исемнәре хасиятьләре берлән», «Шурутес-салаһ», «Мөһиммәтел-мөслимин», «Төхфәтел-мөлек тәрҗемәсе», «Тәгълимес-саләһ», «Ахырзаман китабы», «Мөселманнарның мәркәз диния нәзарәтендә...», «Тарикаи мөхәммәдия», «Мөхәммәдия», «Кыйсасел-әнбия», «Исагуҗи» һ.б.

Шәмәк авылында 3 кулъязма бит, 7 кулъязма дәфтәр табылды. Алар арасында бәетләр, мөнәҗәтләр, багышлаулар күп очрый. Хәтта барыбызга да таныш булган «Сак-Сок» бәетенең бер варианты да табылды. Ул «Татар халык иҗаты» томлыкларында китерелгән бәетләрдән берникадәр аерыла:

*«Ишек алдында җигелгән пар ат,*
*Әнкәй каргагач, яралды канат.*
*Моңлый моңларсың, сайрый сайрарсың,*
*Балаңны очырдың, кемгә еларсың?*

*Кигән бүрегемне алып куегыз,*
*Намаз алдыннан дога кылыгыз».*

Басылган китапларда аналары сары күлмәк кигән диелсә, бу бәеттә исә *кумач* күлмәк дип телгә алына.

Моннан тыш, «Бичара шәкерт малай», «Мөхәммәдгали», «Фатыйма сүзе» һ.б. бәетләр, «Нәфескә хитаб», «Кадер кич», «Газиз аналар» «Лә иләһә иллаллаһ», «Тугды рәсүл» һ.б. мөнәҗәтләр, төрле шигырьләр табылуын билгеләп үтәргә кирәк.

Бер кулъязма биттә үзенчәлекле, кызыклы никах яңарту рәвеше язылган. Янәсе, никах яңартасы кеше хатынына әйтер: «Син, фәлән фәлән кызы, үзеңнең хәләлең фәлән фәлән углына вәкил кылдыңмы?» Хатыны: «Вәкил кылдым», – дип әйтер. Соңыннан ире: «Әгузү билләһи минәш-шәйтанир-раҗим. Бисмилләһир-рахмәнир-рахим. Үземнең тәхтә никахымда булган хатыным фәлән фәлән кызы тарафындан вәкәләтән, үз тарафымдан әсаләте зәүҗәти имраәти әйай», – дип өч мәртәбә әйтер һәм белгән догасы белән дога кылыр икән. Бүгенге көндә бу рәвешле никах яңартулар бер дә күзәтелми, күренми һәм ишетелми. Әллә хәзерге дин әһелләре «традицион татар исламы»н белмиләрме, әллә гаиләләр бик «ныкмы» яңартып торуның кирәге юкмы?..

Басма китапларга килгәндә, «Җәннәтел-әсма», «Һәза хасияте догаи дәүләт», «Кырык хәдис», «Мохтасар иман», «Хәзрәте имам әгъзам васыяте имам Әбү Йосыфка», «Мәҗмәгыл-газават», «Пәйгамбәребезнең кыйссасы», «Рисаләте фи бәян фазыйләти догаи мөстәҗаб», «Көйле иман», «Мәҗмәгыл-дәгъвәт», «Дәкаикыл-әхбар», «Һәза китабе мәрткә киткән...», «Мәймүнәбану хикәятедер», «Гакыйдәи мәнзумә», «Һәза гыйбрәтнамә...», «Һәза китабе мәсҗид...», «Тәгъбирнамә», «Рисаләте фи бәян...», «Тәрбияле бала», «Халеттәракиб», «Бәдәвам китабы», «Касыйдәи бурда» һ.б. табылды.

Көмеш Күл исемле бик матур авылда да булдык. Авылда, күпме генә тырышып та, иске кулъязмалар һәм сирәк басма китаплар таба алмагач, авыл имамы Әбүзәр хәзрәт янына бардык. Бәхеткә, ул халык зиратка алып барып куйган «байлык»ны безгә тапшырырга булды. Алар исә иң кыйммәтле табышлар дип саналырга хаклы, чөнки шагыйрь Колмөхәммәднең шәҗәрәсе язылган кулъязма китап табылды. Аны заманында әлеге әдипнең туганы Нигъмәтулла бине мулла Мөхәммәдсафа Солтанбәков, үзенең һәм башка әдипләрнең әсәрләре белән бергә, 1890 елның 9 октябрендә бик пөхтә

итеп күчереп язган булган. Шәҗәрәне ул шигъри формада биреп, нәселенең дәвамчыларын бик тәфсилләп, аларның тормышы, хәлләре турында язган. Моннан тыш, схема белән дә күрсәтеп, берникадәр мәгълүмат биреп узган. Мәсәлән, Колмөхәммәднең атасы Солтанбәк «башкорт казаклары» дип аталган хәрби төркем (исеме шулай йөртелсә дә, ул татар сугышчыларыннан гыйбарәт булган) гаскәрендә хезмәт иткән. Китапта хәтта Нигъмәтулла ясаган мәчет манаралары сурәтләре дә урын алган.

Китап башындагы битләргә зарар килгән булса да, шактый күп өлеше, дымлылыктан череп бетәргә өлгермичә, сакланып калган. Бу китап Түбән Ушма авылында табылган Колмөхәммәд әсәрләренә өстәлеп, әлеге шагыйрьнең иҗат мирасын баетты, тулыландырды. Әгәр дә бу экспедиция вакытында фәкать шушы ике китап кына табылган булса да, инде бик уңышлы дип саналырга лаек иде.

Шул китап белән, бергә зур форматта өч басма китап та табылды. Аларның берсе – Коръән тәфсире, калганнары шәригатьнең төрле мәсьәләләрен яктырталар.

Шәдче авылында да берникадәр археографик материал туплый алдык: «Догаи мөстәҗаб», «Бәдәвам китабы», «Бакырган китабы», «Кырык хәдис», «Тәрҗемәи Әмали», «Кыйссадан хосса», «Мөһиммәтел-мөслимин».

Мамадыш шәһәренең үзендә дә шактый бай табышларыбыз булды. Нигездә, без аларны шәһәр мәдрәсәсеннән алдык.

Ямаш авылында сан ягыннан аз күренсә дә, сыйфат ягыннан бай, кызыклы материаллар табылды.

Югары Кыерлы авылында палеографик билгеләре буенча XIX гасырга караган гарәп грамматикасы буенча кулъязма китап табышларның кыйммәтлесе булды. Моннан тыш «Исме әгъзам», «Догаи Кадәхен-нур...», «Шәрхе Рамазан догасы», «Нәвадир» һ.б. басма китаплар табылды.

Тарих укытучысы Земфира Гыйлаева ярдәме белән Түбән Шүләнгердә «Хәзрәти Мәрьям», «Рисаләте фи бәян... «, Коръән тәрҗемәсе, «Исме әгъзам», «Кырык хәдис» һ.б. шундый басма китапларга ия булдык. Урта Шүләнгердә исә бары тик кулдан язылган бер шәмаил генә таптык, әмма ул шактый борынгылыгы белән кәефебезне күтәрде.

Ни өчендер, Урта Сон авылында археографик материал азрак табылды. Ә менә Түбән Сонда исә табылган материалның иге-чиге

булмады: 3 кульязма китап, 1 кульязма бит, 1 басма бит, 20 басма китап, 13 кульязма дәфтәр, 1 кульязма шамаил, 1 фоторәсем. Дәфтәрләрнең күбесе Хәсбикамал Мохитытдин кызыныкы булган булса кирәк. Чөнки берсендә түбәндәгечә юллар язылып куелган:

«Ушбуны йазгучы Мохитытдин кызы Хәсбикамал укучыларга бездән күб сәлам бәгъдә хәерле гомерләр теләб калабызлар һәм йалгыш хәрефләр бик күб булыр. Бу әби моны йаза белмәгәч, нә өчен кийәгазь исраф иткән диб салкын карамагызлар. Вәс-сәлам». Каты кәгазьне киндер тукыма белән төреп китап рәвешендә эшләнгән гади бер дәфтәр кызыклы гына табыш булды. Аны 1961 елның 15 мартында Хәсбикамал Мохитытдин кызы ясап, шунда кайбер Коръән сүрәләрен, салаватлар, багышлаулар, мөнәҗәтләр язган. Димәк, китап ясау традициясе үткән гасырның 60 нчы елларында да дәвам ителгән.

Юл уңаеннан Баскан авылына да тиз генә кереп чыгарга өлгердек, гәрчә, бу авылда эшләү безнең планга кермәсә дә. Капка төбенә чыгып утырган бер әби безгә тоташ бәетләр язылган 2 кульязма дәфтәр тапшырды. Анда нинди генә мөнәҗәтләр, бәетләр, шигырьләр юк ... Бәетләргә килгәндә, аларның кайберләренең башында аңлатма да бирелә. Мәсәлән: Малтабар авылында элек уракка барганда атлары дулап чокырга төшеп үлгән игезәк кызлар бәете; Бакчасарай кешесен Тауларга базарга барганда үтергәннәр һ.б.

Сәртек авылында басма китаплардан «Бәдәвам», «Тәрҗемәтелмәсаил», «Китабел-мөгамәләт» һ.б. табылды.

Ишки авылын басма китаплар авылы дип тә атарга мөмкин, чөнки иң күп китап анда табылды. Аларның кайберләрен булса да әйтеп үтик: «Әүвәлен-нәзафәти...», «Коръән тәһлилләре...», «Исме әгъзам», «Һәза хасияте догаи дәүләт», «Һәртөрле маэсур догалар» (ташбасма), «Кыйссаи Сәйфелмөлек», «Догаи мөстәҗаб», «Раунакыл-ислам», «Фән әт-тәҗвид», «Төхфәтел-мөлек тәрҗемәсе», «Касыйдәи рубубия», «Әзкәр әс-саләһ», «Тәгълимел-гыйбадәт», «Кыйраәт Коръән», «Мохтасар гыйльме хәл», «Ислам тарихы», «Хәзаинел-изан», «Дарарел-мәсаил...» һ.б.

Көек-Ерыкса авылындагы табышыбыз 2 кульязма китап, 24 кульязма бит, 4 кульязма дәфтәрдән гыйбарәт булды.

Түбән Яке авылында – 1 кульязма китап, 3 кульязма бит, 2 басма китап, Уразбахтыда 4 кульязма бит, 2 басма китап, 7 кульязма дәфтәр табылуын да искәртеп узарга кирәк.

Ырым трафаретлары элек авылларда өшкерүче әбиләр, халык табиблары кулларында бик киң таралган булып, Совет заманында алар юкка чыкканнар. Борынгы ырымнар, беренче чиратта, төрле авыру-сырхаулардан дәвалау системасының аерылгысыз бер өлеше булган. Хәсәнша авылында борынгы татар ырымнары табылуы бик куанычлы булды. Шуннан бер өзек тәкъдим итәбез: «Нә кем башы зәхмәте ирсә, нә кем күз зәхмәте ирсә, нә кем тел зәхмәте ирсә, нә кем кул агырыгы ирсә, нә кем айак зәхмәте ирсә, нә тәндәге җөмлә зәхмәтләре ирсә, Тәңре кодрәте берлән мән ачдум».

Археографик материаллар шактый күп табылу сәбәпле, барысын да бу мәкалә эчендә генә тасвирлап, сөйләп бетерү мөмкин түгел.

Алар барысы да бик кадерләп кенә саклана. Чөнки, беренчедән, алар татар халкының кыйммәтле мирасын тәшкил итә, икенчедән, бу материаллар Институт хезмәткәрләре тарафыннан бик зур тырышлыклар белән җыелган. Теләгән кешегә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә бу байлыклар белән танышу, өйрәнү мөмкинчелеге бар.

Түбән Ушмадан ерак түгел генә Күчтем (Хафизовка) авылы урнашкан. Кешеләр шул Түбән Ушмадан күченгәнгә күрә авылга шундый исем бирелгән. Анда бер изгеләр чишмәсе дә бар икән. Ул чишмә сигез улактан тора. Су шулардан агып төшә. Чишмә янында ике гыйбадәт йорты салынып куелган. Анда кереп намаз уку, дога кылу мөмкинчелеге бар, тәһарәтне исә чишмә суы белән алырга була. Йортларның берсе иске, икенчесе – яңа. Яңасын Нәбиуллина Гүзәлия ун еллар элек бурадан төзетә, күпер салдыра, халыкка су алу уңайлы булсын өчен, торбалар ярдәмендә суны ерымнан чыгарып, якынайтып, икенче чишмә ясата. Чишмә янында бер таш табылды, аны кабер ташы дип уйлаган идек, ләкин алай булмады. Аның үлчәмнәре: 110×39×15. Түбәндәге сүзләр язылган:

«Лә иләһә иллаллаһ, Мөхәммәдүн расулүллаһ,
ошбу чишмәгә килүб, ошбунда
улгучы газизләр хөрмәтинә
шифа йайинкә ...
адәмләр гафил улмайасызлар
шундагы газиз рухыйна
сәдака кыйлуб йайинкә берәр Коръән аятен»

Ташның уң ягында: «Укуб йайинкә (яки) нәфел намазы укуб багышлайасызлар», сул кырыена: «Дога-Хәер өмид идүб куйды Әхмәдша Әхмәд углы Атнашуф», – дип язылган.

Ташның артында «1924» саны күрсәтелгән һәм «Арташ Гыйльман Даут (?) угылы исеме язылган. Димәк, аны Әхмәдша Әхмәд углы Атнашов, 1924 елда Гыйльман исемле кешегә яздыртып, куйган булып чыга.

Атнашовлар нәселе Түбән Ушма авылында төпләнеп яшәгән һәм авыл зиратында шул нәсел белән бәйле булган кешеләр каберләренә куелган матур итеп эшләнгән берничә таш сакланган. М. Әхмәтҗанов фикеренчә, Түбән Ушмага иң беренче тапкыр Айбулат, Максыд, Биктимер, Юлтимер, Мамадыш, Атнаш исемле җиде кеше килеп утырган. Атнаш исә Мамадышның улы. Авыл эпитафияләрендә очрый торган Атнаш нәкъ менә шул җиде кешенең берсе булса кирәк.

Түбән Ушма авылында ун борынгы кабер ташы табылды.

1. «Бисмилләһиррахмәниррахим,
зәликә тәкъдир әл-газиз әл-галим
сахибә әл-кубур Сахибҗамал Мөхийетдин кызы
Югары Ушмының миладия 1913 нче
сәнәдә апрельнең 6 сында дарел-бакайа рихләт әйләде
61 яшендә, Аллаһ Тәгалә рәхмәт әйләсүн»

Бисмилла сүзе матур тугра формасында каллиграфик стиль белән язылган. Аның астында татар традицион бизәкләре төшерелгән.

Ташның арткы ягында яздыручы исеме язылып куелган:

«Яздыргучы
Хәбибрахман бине Гыйлаҗ-
еддин Минһаҗетдин углы»

Әлеге язмалар өстендә аска карап тора торган ярым ай сурәте ясалган.

Бу ташның биеклеге 81 сантиметр, киңлеге 42,5 сантиметр, калынлыгы исә 17 сантиметр тәшкил итә. Язмалары күпертмә язу белән язылган.

Ташларда бөтенләй тыныш билгеләре куелмый, биредә һәм алга таба да алар җөмлә кисәкләрен аеру өчен безнең тарафтан өстәлде.

2. «Бисмилләһ,
лә иләһә иллаллаһ,

Мөхәммәдүр-расулүллаһ,
Әшһәдү əн лə иләһә и-
ллаллаһү вә әшһәдү әннә
Мөхәммәдәр-расулүллаһ,
ошбу кабер ху-
җасы Сиражед-
дин Ибраһим углы
85 яшендә вафат»

Ташның үлчәме: 71×37×17. Сүзләре эчкә уелып, ягъни уйма язу белән язылган. Ташның арткы ягында да, кырыйларында да бернәрсә язылмаган. Ул карап торышка бик гади итеп ясалган, өске ягында гына өстән югарыга таба үрмәләүче ике сабакка охшаш орнамент ясалган.

3. «Йа, Рәхим,
Мөхәммәджан Гобәйдулла углы-
ның әһлиясе Бибинәзыйфә
Габделвахид кызы вафат
булды 1877 нче елда
сентябрьнең 18 ндә
81 йәшендә яздырды»

Ташның үлчәме: 102×38×11. Бу таш күпертмә язулы. «Йа, Рәхим» сүзләре ясалган гөмбәз эчендә язылган. Аның ике кырыенда, тулы сабаклары һәм яфраклары белән бергә, берәр чәчәк ясалган.

Арткы ягындагы язу:

«Кияве Мөхәммәдшакир Һибатулла
хаҗи углы, 1886»

Ташның бу ягы да күпертмә язулы. Язмалар өстендә квадрат эчендә бик матур тугра язылган. Аның почмаклары яфраклы биш аерчалы чәчәкләр белән бизәлгән.

4. «Тарих мәсихия елдан
1870 нче елда июньнең
7 нче йәүмендә Дауд Гобәйдулла
углы Атнашуф әһлийәсе
Бибиҗәмилә Әхмәджан кызы вафат...»

Астагы ахыргы юлы җиргә кереп торганлыктан һәм сүзләре ашалганлыктан укып булмады. Үлчәме: 103×47×7,5.

Ташның артында исә түбәндәгечә язылган:

«Әл-мәүт.
Дога-хәер өмид кыйлуб йаздырды
кияве Мөхәммәдшакир Һибатулла
хаҗи углы»

Димәк, өченче, дүртенче ташларны да бер үк кеше яздырган. Алар бер-берсенә охшаш, шуңа күрә, бер үк кеше эшләткәч, бер үк кеше ясагандыр. Ташның ике ягы да күпертмә язулы.

5. «Һиҗрийә 1361 сәнә шәгъбан 5шендә җомга көн
Әхмәд бине әл-хаҗ әл-хәрәмәйн Мөхәммәдҗан Атнашуф
59нчы йәшендә дарел-фәнадан дарел-бәкайә
рихләт кыйлды, Хак Тәгалә гыйззәтү рәхмәт
әйләсүн»

Язулар өстендә тугра формасында: «Лә иләһә иллаллаһ, Мөхәммәдүр-расулүллаһ...» сүзләре бирелгән.

Ташның үлчәме: 83×38,5×18, күпертмә язулы.

Күргәнебезчә, монысы да Атнашевлар нәселе дәвамчысы булып чыкты.

Ташның икенче ягында да түбәндәге сүзләр бар:

«Румийә илән 1891 нче елда
4 мартда Әхмәд Мөхәммәдҗан хаҗи углы Атнашуф»

Шулай ук таш кырыйларында да язмалар күренә:

«Әдүдүньйа әүвәлүһа
сөрур
вә әүсәтуһа
горур
вә ахируһа
кобүр»

Татарчага тәрҗемәсе: «Дөнья: аның башы – сөенү, уртасы – горурлану, ахыры – кабер». Чыннан да, рифма белән язылган бу сүзләрдә хаклык, хикмәт бар.

Икенче кырыендагы язмалар инде ачык күренмәс хәлгә килгәннәр:

«Рәхимәһуллаһ ... вә калә ... Мөхәммәд ...»

6. «Түбән Ушмының Дауд Гобәйдулла углы Атнашуф вафат булды тарих

1886 нчы елда март-
ның 8 ндә шинбә көн
сәгать 8 дә, илле
йәшендә ирде, йаздырды
догаи хәер өмид кыйлуб»

Үлчәме: 113×36×12,5, күпертмә язу белән язылган.

Арткы ягында да шул ук ысул белән:

«Йаздырды Өлге Киеге Һибатулла
Хаҗи Мөхәммәдшакир углы»

7. «Лә иләһә иллаллаһ,
һиҗрийә 1331 нче дүшәнбе
шәүвәлдә көн
11 Зәйнетдин Шәйхикамал (?) углы
дарел-фәнадән дарел-бәкайә
рихләт кыйлды»

Бу яктагы текст нindидер буяу белән артык пычранган булу сәбәпле, ачык түгел, дөрес итеп укып булмый.

Үлчәме: 67×39×12.

Арткы ягында түбәндәге сүзләр сырланган:

«Тарих ... 1913 елда
сентябрьнең 9 нда...»

Ташның бер кырыендагы язмалар ачык күренә:

«Әдүдүньйа әүвәлүһа сөрур вә әүсәтуһа горур вә ахируһа кобүр». Тәрҗемәсе: «Дөнья: аның башы – сөенү, уртасы – горурлану, ахыры – кабер».

Икенче кырыенда исә бер ни дә язылмаган.

8. «Нәввәраллаһү Тәгаһ (Тәгалә) кабрәһү тарих һиҗрийә илән
мең дә 288 нче сәнәдә сәфәр аеның
1 нче йәүмендә Шәмсебану Мөхәммәдҗан хаҗи мәр-
хүм кызы, Мөхәмммәдшакир Һибатулла хаҗи углы-
ның җәмәгате 32 йәшендә дарел-фәнадин
дарел-бәкайә рихләт әйләде рәхимул-лаһү
рәхмәтән васигатән вә җәгаләл-лаһү мәркадүһү раудатән мин рийазый
әл-җәннәти... амин»

Үлчәме: 103×37×20, күпертмә язулы.

9. «Тарих 1247 рабигыль-әүвәл....»

Үлчәме: 63×60,5×9, уйку язулы.

Болардан тыш берничә язусыз борынгы ташлар да очрады. Андыйларны, гадәттә, яздыртырга, эшләтергә акчасы булмаган фәкыйрь кешеләр куйган.

Түбән Ушма авылының бер башында әле тагын бер каберлек бар. Аның чардуганы да бар, ләкин ташы юк һәм беркайчан куелмаган да. Әлеге кабердә 1918 елда акгвардиячеләр тарафыннан үтерелгән билгесез ике кызыл сугышчы җирләнгән. Авыл мәктәбенең музей җитәкчесе Хәлим Сәлахетдинов сөйләвенчә, алар 1918 елда Түбән Ушмага килеп, авылда аклар бармы, дип сораштырып йөриләр. Алар зират каршында торучы Борһан исемле кешедә куналар. Икенче көнне берничә кибеткә керәләр һәм Комазан авылының кайда икәнлеген, бу авылда кемнәр яшәгәнлекне сорашалар, үзләрен Комазан кешеләре дип таныштыралар. Гариф Шакиров (Чәпән Гарифе) дигән кеше боларны күреп, шикләнә төшә һәм старостага барып әләкли. Теге кешеләр инде урманга таба киткән була, аларны куа башлыйлар. Урманга җиткәндә куып тоталар, кире авылга алып кайталар һәм Апак Габдрахман амбарына ябып куялар. Шуннан соң алардан сорау алу башлана. Тегеләр исә барыбер үзләрен кызыллар гаскәрендә торганнарын әйтми. Икенче көнне Чәүкә тавына алып менеп, аталар. Аларның берсе озын буйлы, сары чәчле, икенчесе тәбәнәгрәк, карарак була. Атып үтергәч, аклар аларның гәүдәләрен дә күмәргә кушмыйлар. Ләкин авыл халкының ризасызлыгы нәтиҗәсендә, ниһаять, күмеп куярга ризалашалар. Бу эшне авылның иң ярлы кешесе Гали Дияровка (Дияр Галие) йөклиләр. Ул фәкыйрьлеге сәбәпле, мәетләрнең аяк киемнәрен салдырып, үзенә ала, каберне дә бик сай итеп кенә казып, икесен дә бер кабергә генә күмеп куя, хәтта алар тулысынча күмелеп тә бетми. Шул вакытта авыл мулласы бу эшкә үзенең ризасызлыгын белдергәч, каберләрен зурайтып, җиренә җиткереп җирлиләр. Бу кабердә ятучыларны авыл халкы Комазан кешеләре кабере дип йөртә башлый.

Бу кешеләр Комазан авылыннан булмаган, дигән фикер дә бар. Мәсәлән, Хәлим Сәлахетдинов аларның Азнакай районы, Яңа Әхмәт авылы егетләре булганлыгын ачыклый алган. Әмма без хәзер бу районда андый авылны таба алмадык. Бәлки, ул авыл хәзер беткәндер инде, ә, бәлки, сүз Сарман районындагы Яңа Әхмәт авылы турында баргандыр.

Үсәли авылы зиратында фәкать бер генә борынгы таш табылды. Авыл имамы әйтүенчә, башка ташлар алай ук борынгы түгел. Табылган ташта түбәндәге сүзләр язылган:

«Һиҗриянең 1312, миладиның 1894
нче елда 15 нче декабрендә 65 йәшендә
дарел-фәнадин дарел-бәкайә күчде рәхмәтлү
Гобәйдулла Хәбибулла углы
Рәхимәһуллаһү рахмәтән васигатән»

Арткы ягы:

«Әл-хөкмү лилләһ
Әбкү, йә, хәййү галә нәфсикә каблә бүкәи
лә йүгыйдү иннә бәтъшә раббикә ләшәдид,
кил, әй, хайиф үлүреңне белгел
китәр мәнзилең истигъдадын иткел»

Ташның үлчәме: 125×38×15,5. Язмалар күпертмә язулы.

Зиратта Мамадыш төбәгенә бик үк хас булмаган кызыл кирпечтән эшләнгән чардуганнар күп очрый. Алар шундый матур, пөхтә итеп өелеп ясалганнар, кайбер кирпечләр, кирәкле форма бирү өчен, киселеп эшләнгәннәр, һава йөрсен өчен үзенә күрә тәрәзәләре дә бар. Мондый төр чардуганнар бу якларда сирәк очрый, чөнки халыкта яндырылган таш кертү ярамый, дигән ышану булган. Дин буенча да яндырылган кирпечне ләхет каплау өчен куллану тыела.

Шулай ук агачтан эшләнгән берничә чардуган да кызык эшләнгән: баганаларын тишеп, шунда араталарын тыгып ясалган. Бу инде чардуган ясаганда тимер, шул исәптән, кадаклар кертү ярамаганлыктан килә. Халык ышануы буенча, гөнаһлы булса, мәетнең җаны фәрештәләр тарафыннан төрле газапларга дучар ителә, шул исәптән, тимер белән дә. Зиратка тимер кертү газапның тагын да артуын китереп чыгармасын өчен, аны кертмәгәннәр.

Өчиледән (Үсәлидән) ерак түгел Бөрсет-Сукачы авылы янында аерым бер каберлектә таш булуы хакында Г.В. Йосыповның 1960 елда басылып чыккан «Введение в булгаро-татарскую эпиграфику» китабы аша белгән идек. Бүгенге көндә ташның сакланышы ни дәрәҗәдә икәнен күрү өчен карап кайтырга булдык. Ул инде ватылып, язмалары уалып беткәндер, дип уйлаган идек, ялгышканбыз. Чыннан да, башта аның яртысы ватылып төшкән булган, соңыннан авыл халкы ташны моннан 10–15 ел элек реставрацияләткән:

Агропромхимия оешмасының Үсәли берләшмәсе ремонт остаханәсендә ташның дүрт почмагы тимер кыса эченә урнаштырылган, ватылган урыннары цемент эремәсе белән ныгытылган, кар, яңгырлардан саклау өчен өстенә күгәрми торган калайдан түбә ясап куелган һәм таш фундаментка утыртылган.

Тимерләрен матур яшел буяуга буяп, кире каберлек өстенә урнаштырганнар, хәтта ике чардуган эченә алынган, янында зур агач үсеп чыккан. Әгәр дә шул рәвешле вакытында ташны рәтләмәгән булсалар, бүгенге көнгә хәтле андагы язмалар сакланмас иде, фәкать ике өлештән торган билгесез таш кына яткан булыр иде. Күп вакытлар үтү сәбәпле, ташның иң аскы юлындагы язулары уалып, ватылып төшкән, тимер читлек астында калган хәрефләр дә күренми.

2012 елның көзендә Р. Мәрданов һәм И. Һадиев бу ташны түбәндәгечә укыганнар:

Алгы ягында:

калә Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә көлли нәфсин заикат-
ел-мәүт калә ән-нәби галәйһиссәлам әд-дөнйа мизрагат-
ел-ахир[әт] калә ән-нәби галәйһиссәлам әд-дөнйа
сәгать фә-әҗгальһа тагать тарих тукуз йөз
кырык алтыда зөлхиҗҗә айында Карач угылы
Карачура даре фәнадин даре бәкага рихләт
... ... ...сун(?)
Арткы ягында:
бу ләүхне анасы ...әч бина ...ды

Уң ягында:

калә ән-нәби галәйһиссәлам әд-дөнйа җифат вә талябиһа к[иляб]
Сул ягында:
калә ән-нәби галәйһиссәлам...

Бу ташның биеклеге – 120, иңе – 50, калынлыгы – 18 см. Алгы якның өске өлешендә һәм кырыйлары буенча бизәкләр ясалган, язулар күпертмә рәвештә башкарылган.

Безнең укылыш та аларныкы белән тәңгәл килә, ләкин таш артында без бернинди язулар тапмадык, бәлки, уалып беткәндер, ә, бәлки, ташка сыланган цементлы эретмә астында калгандыр. Һиҗри 946 елның зөлхиҗҗә ае милади 1540 елның апреленә туры килә.

Бу кабер иясе хакында халык арасында бер риваять йөри: 1552 елга хәтле үк Казан ягыннан ике кеше килә һәм, русларның

һөҗүменнән сак булыгыз, каршы торырга әзерләнегез, дип әйтәләр. Шул кешеләрнең берсе бу җирдә үлеп кала һәм аны биредә җирләп, таш куйдырталар.

Кече Кирмәндә бер генә борынгы кабер ташы таба алдык:

«Лә иләһә иллаллаһ, Мөхәммәдөр-рәсүлуллаһ,
Чистай Мөхәммәдзакир хәзрәт
мөриде Хисаметдин Гыйсмәтулла
углы 55 йәшендә дарел-фәнаи-
дан дарел-бәкайә рихләт әйләде
румия илән 1892 нче елда 26 нчы
июньдә, һиҗрәт илән 1304 нче сәнә
маһи зөлхиҗҗәнең 13 нче йәүмендә,
Аллаһ Тәгалә рәхмәтенә гарыйк әйләсүн»

Арткы ягы:

«Көллү нәфсин заикател-мәүт,
Йә, вакыйфән, бикабри фәккир әмри
Бил-әмси күнтү мислүк түсаййиру мисли
Кирам әйләб, догаида идүңез йад
Тасдикайә калуңыз, рухы шад,
Бу кабер хәлләрүн сагышлайасыз,
Безә Коръән укуб багышлайасыз,
Безем Коръән укурга хәлемез йук,
Хәер хәсән кылурга йулымыз йук»

Гарәп телендәге җөмләләрнең тәрҗемәсе:

«Һәрбер кеше үлемне татыячак,
Әй, каберем янында басып торучы, уйлан минем хәлләрем турында,
Кичә мин синең кебек идем, тиздән син минем кебек булырсың»

Үлчәме: 149×42×13,5, күпертеп язылган.

Ташта «вакыйфән» сүзендә «н», шулай ук «нәфсин» сүзендә дә ахыргы «н» хәрефе күрсәтелмәгән. Шуңа күрә кайберәүләр аны «вакыйфа», «нәфси» дип укый. Әмма гарәп теле грамматикасы буенча ул сүзләрдә яшерен «н» хәрефе өстәлә, шул сәбәпле, биредә гарәп телендә кабул ителгәнчә яздык.

Мамадыш районына килеп тә, «Ханнар зираты»н күрмичә китү ярый торган эш булмас иде, шуңа күрә андагы кабер ташларын да карап, рәсемнәрен төшереп, үлчәмнәрен алдык. Дөресен генә

әйткәндә, без бу зиратны бик пөхтә, затлы, чистартылган дип күзаллаган идек. Ләкин ул агачлары ауган, чүп баскан, эченә көч-хәл белән керерлек хәлдә булып чыкты. Бәлки, әле чистартырга өлгермәгән булганнардыр, ишеткәнебезчә, аны ел саен тәртипкә китереп торалар икән. Ә менә ташларга килгәндә, аларның һәрберсе диярлек чардуган белән әйләндереп алынган, кабер ияләренең татарча, кириллицада язылган исемнәре язылган матур яшел калай-плакатлар эленгән. Ташлардагы язулар уалып, бетә башлаган, кайберләрендә язулары инде бөтенләй күренмәс хәлгә җиткән. Күренгәннәре дә шул уелып язылганга күрә генә һаман да сакланалар. Әгәр дә күпертеп язылган булсалар, бәлки, табигать кануннарына буйсынып, юкка да чыккан булырлар иде. Бәхеткә XX гасыр уртасында һәм ахырында безнең хөрмәтле галимнәребез Һарун Йосыпов, Фәрит Хәкимҗанов һ.б.лар ташларның текстларын укып калырга өлгергәннәр, китапларында шуларны тасвирлап, бик зур эш башкарганнар.

Түбән Тәкәнеш авылы зиратында ике генә борынгы таш табылды:

1. «Әлхәмдү лилләһ,
Мөхәммәдсадыйк Сахиб-
еддин углы вафат
1906 сәнәдә 37 нче
йәшьдә, Аллаһ рәхмәт»

Бу ташның тагын бер юлы булырга да мөмкин, чөнки җөмлә тәмамланып бетмәгән кебек тоела. Бер юлы җир астында калса да, анда, контексттан аңлашылганча, «әйләсүн» сүзе генә булырга тиеш.

Арткы ягы:

«Көллү нәфсин заикател-мәүт,
Йә, вакыйфән,
бикабри фәккир әмри бил-ә-
мси күнтү мислүк
түсаййиру мисли»

Тәрҗемәсен югарыда бер ташны тасвирлаганда биргән идек. Үлчәме: 61×42×10, күпертеп язылган, үзе áрка формасындагы бордюр белән ясалган.

2. Әлхәмдү лилләһ,
Миннекә бине Фәйзулла
еддин углы вафат

1862 нче сәнә 75 йәшьдә.
Гөлзаһирә Габделгазиз
кызы 1868 нче сәнә
Аллаһ Тәгаһү рәхмәтенә гарыйк»

Арткы ягы:

«Әл-мәүт,
Йә, вакыйфән, бикабри фәккир әмри
бил-әмси күнтү мислүк түсаййиру
мисли.
Яздырды Салахетдин
Минкә углы»

Үлчәме: 72×41×9, күпертмә язулы.

Түбән Тәкәнеш зиратында рус милләтеннән булган кешеләр дә җирләнгән икән. Халык, әлбәттә, бу эшкә каршы булса да, сугыш вакытында төрле милләт вәкилләрен күмәргә мәҗбүр булалар. Алар зиратның кырыйларында күмелгәннәр. Мәсәлән, нәкъ авыл ягы кырыенда Ленинградтан килгән дүрт бала җирләнгән. Ул каберлекләр зур чардуган белән әйләндерелеп, түбәндәге сүзләр язылган калай плакат беркетелгән: «Здесь покоятся четверо детей из школы № 322, эвакуированные из города Ленинграда в 1942 г.» Чардуганга ясалма чәчәкләр дә кыстырып куелган. Халык сөйләвенчә, авылга Ленинград балалар йортыннан 1942 елның март аенда утызга якын бала китерәләр. Аларны манарасы киселгән мәчет бинасына урнаштыралар. Балалар белән бергә Мәскәү, Смоленск шәһәрләреннән рус укытучылары да күчеп килеп, биредә рус класслары оештырыла. Аларда, әлбәттә, җирле татар балаларын да укыта башлыйлар. Күченеп килгән кайбер балалар вакытсыз вафат булалар, мәсәлән, берничәсе ач карынга күп микъдарда борчак ашап, күбенеп үлгән. Менә шулар җирләнгән дә инде авыл зиратында.

Шәмәк авылы каберстанында таштан өелгән бер борынгы чардуган игътибарны җәлеп итте, Чөнки аның бер ташында язулары да бар иде:

«Тарих мең дә йөз сиксән йитенче елның ибтидалары
Биккол бине Илмәт»

Текст уеп ясалган кыса эченә алынып, юллар арасы сызык белән аерылган. Үлчәме: 57×24×68, уеп язылган.

Моннан тыш, язулы ташлар бүтән очрамады.

Зиратның керә торган җире, ягъни капка каркасы кызыл кирпечтән өелеп ясалган, шул кирпечләр арасында, матурлык өчен булса кирәк, ике ак таш та күренеп тора. Менә шуларда гарәп цифрлары белән язылган «1911» дигән дата тора. Бу, әлбәттә, зиратка кайчан нигез салынуын түгел, ә капка эшләнү датасын чагылдыра.

Көмеш Күл авылында да берничә борынгы кабер ташы табылды:

1. «Бу кабердә Мәфтуха Югары Ушмә
мулла Нигъмәтулла Солтанбиков
кызы Минһаҗеддин мөәзин җәмәгате
дәфен иделде 1914 нче елда 6 нчы майда
42 йәшендә дөньядан үтде, Аллаһ рәхмәт кылсун,
Әй, мөселман, Аллаһның киң рәхмәте булсун сиңа,
бу кабергә утуруб кыйлсаң әгәр изгү дога»

Арткы ягында:

Әлхәмдү лилләһ,
күллү нәфсин заикатү әл-мәүт,
рәнҗеде күкрәкләрем һәм
бик зәгыйфьләнде тәнем,
сезгә дә бер көн килүр ул
... Газраил тотар,
тәфәккер кыйл бу кабер хәлене, йә, әһле гакыйл,
кил каберемә, утур укыб Коръән, дога кыйл»

Үлчәме: 101×41×10, уеп язылган. Бу таштагы язулардан шагыйрь Колмөхәммәд бине Солтанбәкнең оныкчыгы кабере икәнлеге ап-ачык күренеп тора. Мәфтуханың атасы мулла Нигъмәтулла Солтанбиков әлеге шагыйрьнең оныгы. Нәкъ менә шуның тырышлыгы белән бабасының мирасы язма истәлекләрдә сакланып калган. Әлеге авылда Нигъмәтулла мулланың кызы атасының кулъязмаларын үзендә саклаган, ул вафат булгач, туганнары, кирәксезгә чыгарып яки гарәп язуларын аңламыйча, аларны зират алачыгына илтеп куйганнар. Без, түбәндәге кабер ташларын өйрәнеп йөргәндә, анда шул китапларны да табу бәхетенә ирештек.

2. «...
шинбә көн менла Гыйз...
....йнан углы ...
...»

Таш бина начар сакланышта булганга бер өлешен укырлык түгел, чөнки кителеп төшкән.

Бер кырыендагы язуларны да укырлык түгел, ә менә икенче ягындагы язулар, ышыграк як булгангамы, яхшы күренә:

«гаҗәлү бис-саләти каблә әл-фәүт вә гаҗәлү бит-тәүбәти каблә әл-мәүт»

Үлчәме: 86×36×10, уеп язылган.

3. Кәфә бил-мәүти вагыйзан,
Румийә илә 1900 нчы елда 24 нче майда
Насыйбулла Салих углы
9 йәшендә дарел-бәкайә
Рихләт кыйлды Хак Тәгалә
Гарыйк рәхмәт әйләсүн»

Арткы ягы:

«Насыйбулла»

Уң ягы:

«Әй, угыл, гафләт ... булсын хәлең хараб»

Үлчәме: 95×42×13, уеп язылган.

Урта Шүләнгер авылы зиратында башы очланып ясалган язулы бер генә борынгы таш барлыгы ачыкланды:

1. «1802 елда
маһи сәфәрнең ... көнендә
вафат улды
Мөхәммәдгали»

Үлчәме: 50×53×11, уеп язылган.

Дулкын-дулкын итеп эшләнелгән яссы һәм турыпочмаклы формадагы бик үзенчәлекле тагын бер борынгы ташка тап булган идек, ләкин ул язуларсыз булып чыкты. Олыяз авылы кырыенда бер борынгы таш бар. Ул Һ. Йосыпов (Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1960), М. Әхмәтҗанов (XVII–XVIII гасыр татар ташбилгеләре. – Казан, 2011) кебек галимнәр тарафыннан укылган инде.

Марсель ага Әхмәтҗановка бу ташны авыл халкы укыттырган булган, аның тексты калайга матур итеп язылып, чардуганга беркетелеп куелган. Әлеге кабер ташы ике чардуган белән әйләндереп алынган: эчтәгесе элекке караватлардан калган тимерләр ярдәмендә, икенчесе агачтан өчәр рәт арата куелып эшләнгән.

2012 елда Р. Мәрданов белән И. Һадиев та бу ташны өйрәнеп кайталар. Барысы да, нигездә, бертөрлерәк укысалар да, хәрефләр язылышында кайбер кечкенә генә аермалар күренә. Ничә кеше, шул хәтле караш була дигәндәй, без дә бу таштагы язманың алар укылышыннан бераз гына аерылган вариантын бирергә булдык:

> «Һүә әл-хәййү әлләзи лә йәмүтү вә күллү хәййин сәйәмүтү калә ән-нәби галәйһи-ссәлам әд-дүнйа сәгатү фә-әҗгальһа тагать садәка калә ән-нәби галәйһи-ссәлам әд-дүнйа сиҗнүн әл-мөэмин вә җәннәт әл-кәфир калә ән-нәби галәйһи-ссәлам әд-дөнйа җифат вә таләбиһа киляб тарих мең дә йөз дә бишд дирләр ирде Бимөхәммәдкә угылы Дускә билке куйды ирәнләрдин дога өмит өчүн».

Сул ягында:

> «Дарел-фәнаэ дарел-бәкаййә рихләт кылды Ходай рәхмәт кылсун»

Ташның үлчәме: 144×56×18. Язулары күпертеп язылган. Алгы һәм арткы якларның өстендә бизәкләр уеп ясалган. Һиҗри 1105 ел милади исәп белән 1694 елга туры килә.

Кабер ташларын укучыларның күбесе җөмләдә баш килештә торган «күллү» («көлле») сүзен ни өчендер «күлли» («көлли») дип укый. Гарәп телендә бу сүз баш килештә торганда «күллү» («көлле»), иялек килешендә «күлли» («көлли») һәм төшем килешендә «күллә» («көллә») була (гарәп телендә бары тик 3 кенә килеш). Шул үзенчәлекләрне белү бик мөһим, югыйсә «Күллү нәфсин заикат әл-мәүт» җөмләсен «Көлли (көлли) нәфсин заикат әл-мәүт» дип хаталы укып куюың бар.

Әлеге мәкаләдә үзебез булган авыллар зиратларында сакланган борынгы кабер ташларының язылышын биреп бетерү мөмкин түгел. Алардан тыш әле, Түбән Шүләнгер, Дусай, Олыяз, Уразбахты, Ишки, Түбән Козгынчы, Түбән Яке, Баскан, Түбән Сон, Түбән Яке һ.б. авыллардагы зиратларның инкыйлабка хәтле булган дәвере эпитафик язмаларын да укып өйрәндек.

Экспедициядән кайткач, ярый әле нәкъ менә Мамадыш районына барганбыз икән, дип сөендек. Чөнки юлларыбыз һәрвакыт унды, яхшы каршы алдылар, ә иң мөһиме, бик күп археографик һәм эпиграфик хәзинә алып кайттык. Әле бу соңгы фәнни экспедиция түгел, бу төбәккә тагын күп тапкыр барырбыз, дип өметләнеп калабыз.

.

# ХАЛЫКНЫҢ ҮТКӘНЕ БЕЛӘН БҮГЕНГЕСЕН ТОТАШТЫРУЧЫ ЯЗМА МИРАС

*Гөлназ Нургатина*

Кайчандыр халкыбыз тарафыннан изге саналган, кадерләп сакланган гарәп яки татар телләрендәге кулъязма һәм басма китапларның бүгенге язмышы бик аяныч хәлдә. Аларның урыны иске яулыкларга төйнәлгән хәлдә сарайларда, иске йортларда яки чорма башларында. Әлеге материалларның көннән-көн юкка чыга баруын исәпкә алганда хәзергәчә сакланган һәр китап зур кыйммәткә ия. Чөнки аларда – татар халкының гасырдан-гасырга баетылып килгән рухи, мәдәни һәм фәнни күзаллаулары, тарихи үткәне.

Мамадыш төбәгенә үткәрелгән комплекслы экспедиция барышында тупланган кулъязмалар һәм китаплар Институтның язма һәм музыкаль мирас үзәгенә тапшырылды.

Җыелган материаллар күплеге буенча Кече Кирмән авылы беренче урында тора. Уннан артык чишмәле тау итәгенә урнашкан әлеге авылның халкы үзен ачык күңелле һәм мәгърифәтле итеп танытты. Иң күп китап-дәфтәрләр тапшырган һәм башка авылдашларын да Казан галимнәренә материал тупларга ярдәм итәргә өндәгән Нурзидә апа Мөхәммәдсафа кызы Гайфуллинага (1941 елда туган) зур рәхмәтләр җиткерәсе килә. Борынгы китапларның махсус шартларда сакланырга һәм череп юкка чыкканчы фәнни әйләнешкә кертелергә, моның өчен археографларга тапшырылырга тиешлеген, кызганыч ки, авыл кешеләренең барысы да аңлап бетерми.

Кече Кирмәннән барлыгы 92 документ тупланды. Алар арасында 33 кулъязма, 57 басма китап, 2 фотокопия юлы белән ясалган китап һәм татар хатын кызлары баш киеме – калфак та бар. Алар арасында зур кыйммәткә, әлбәттә, борынгы кулъязма китап фрагментлары ия. Шулай ук бу авылда табылган кулъязма дәфтәрләр дә зур игътибарга

лаек. XX гасырда, диннәр тыелу сәбәпле, гарәп графикасында булган теләсә нинди басма китаплар юкка чыгарылып килгән заманнарда да татар халкы гыйлем-мәгърифәткә мәхәббәтен җуймый. Шундый шартларда да мәгърифәтле милләттәшләребез авыл халкын дини әдәбият белән тәэмин итәргә тырыша – сакланып калган басма китапларны, дәфтәр битләренә күчереп, ислам нигезләренә төшенергә теләүче авылдашлары арасында тарата. Бу эш белән бигрәк тә хатын-кызлар шөгыльләнгән булса кирәк, чөнки безгә очраган андый язмалар барысы да диярлек хатын-кызлар тарафыннан башкарылган. Кече Кирмәндә мондый кулъязма дәфтәрләр бик күп табылды. Аларга хәдисләр, дини риваятьләр, төрле догалар, шигырьләр, мөнәҗәтләр, ислам тарихына бәйле мәгълүматлар, «Сүрәтел-әнбия» кебек әсәрләр теркәлгән. Еш кына бу дәфтәрләрдә аларның кем өчен күчерелгәне дә күрсәтелә. Кулъязмалар арасындагы аеруча игътибарга лаек материаллардан бер җаваплама һәм өч шамаилне атап була. Басма китаплар арасында, Коръән, һәфтияк тәфсирләре, төрле догалар һәм башка күпсанлы дини әдәбият белән беррәттән, татар телендәге «Йосыф китабы», «Кечкенә һөнәрләр», «Бакырган китабы», «Бәдәвам», «Алты бармак китабы» һ.б. бар.

Урта Кирмән авылыннан 69 берәмлек материал алып кайттык: 36 кулъязма, 27 басма, 1 ташбасма китап (гарәп телендә, яхшы хәлдә сакланган; Җиһаншина Нәсимә Мөхәммәджан кызыннан (1940 елгы) алынды), 4 фотокүчермә материал һәм 1 документ. Кулъязма материаллар арасында яхшы хәлдәге 3 тулы кулъязма китап һәм аерым битләре генә сакланып калган 5 кулъязма китап фрагменты теркәлде. Ике дистәгә якын кулъязма дәфтәр бар. Оригинальлеге белән кулъязма китап һәм дәфтәрләрдән калышмаучы «Килешү таныкнамәсе» дигән документка аерым тукталып үтәсе килә. Ул «1928 нче ел август аеның 24 нче көнендә» бер яктан Хәсәншин Габдерәхим, икенче яктан аның аерган җәмәгате Рәхимова Йамбига төзегән аерылышу һәм милекне бүлү турындагы килешү. Ирле-хатынлы Фаяз һәм Миңҗиһан Галимәрдәновлардан алынган әлеге документка багышлап аерым мәкалә язылды һәм «Түгәрәк уен» альманахы редакциясенә тапшырылды. Моннан тыш, Урта Кирмән авылыннан табылган кулъязма материаллар арасында бөтиләр, шамаилләр, хатлар да бар.

Шәдче авылында тупланган кулъязмаларның саны 29 берәмлекне тәшкил итә. Алар арасында кулъязма китаплар, аларның фраг-

ментлары, күп санлы китап күчермәләре, ягъни кулъязма дәфтәрләр, җавапламалар, бөтиләр һәм хатлар бар.

Басма китаплар саны 18 берәмлекне тәшкил итә, аларның күпчелеге гарәп һәм татар телендәге дини әдәбият. Мәдрәсәләрдә география белемен өйрәнү өчен дәреслек буларак кулланылган «Тәгълим җугрфия» (1910 елда Казанда «Милләт» типографиясендә чыккан), «Җуграфия» китаплары икесе дә Нуриева Зәлилә Мөхәммәдхафиз кызыннан (1939 елгы) алынды. Бүгенге көндә сирәк табылучы бу дәреслекләр татар халкының аң-белемгә омтылышын, бөтендөнья фәнни казанышларыннан хәбәрдар булганлыгын исбатлый. Моннан тыш, Шәдче авылында ташбасма китап фрагментлары, фотокүчермә китаплар, документлар һәм фотографияләр дә табылды.

Түбән Сон авылында алып барылган эзләнүләр дә яхшы нәтиҗәләр китерде. Барлыгы 49 берәмлек арасында тулы кулъязма китаплар, дәфтәрләр, китап күчермәләре һәм аерым битләрдәге төрле язмалар бар. Бер дәфтәргә теркәлгән, авторы билгесез шигырь һәм мөнәҗәтләр шәхси иҗат җимешләре булса кирәк. Аны безгә Акикова Гафия Зиннур кызы (1939 елгы) бирде. «Ялгыз каен», «Балама сагынып хат» дип аталган шигырьләрдә ялгыз ананың сагышлы хисләре чагыла:

Тирән уйга чумып карап торам.
Сылу үскән матур каенга.
Әллә яфраклары төшкәнгәме,
Ул да чумган тирән кайгыга.

* * *

Ул заманнар тарих булып калды,
Мәңге алар минем күңелдә.
Сезне сагынып җылап утырдым да,
Шигырь яздым менә бүген дә.

Хуш исән бул балам күрә алмасам,
Шигырем булыр сиңа истәлек.
Кулларыңа алып бер укырсың,
Үстергәннәремне искә алып.

Сез бит минем аткан чәчәкләрем,
Сез бит минем тормыш гөлләрем.
Чәчәкләрен койгач сабак корый,
Шулай үтә минем көннәрем.

Басмалар арасында күпчелеге Коръән һәм дини темага караган башка китаплар. Араларында «Кисекбаш китабы», «Мәликә китабы», «Бакырган китабы» кебек матур әдәбият әсәрләре. Татар телендәге мәктәп дәреслеге дә очрады. Әлеге җирлек халкына караган төрле документлар да табылды.

Өчиле (Үсәли) авылында тупланган кулъязма китап, дәфтәр, хатлар арасында Бөек Ватан сугышы елларында фронттан язылган хат аеруча кызыксыну уята. Бу өчпочмаклы хатны безгә Нуриева Фатыйма Шәмсемөхәммәд кызы (1932 елгы) тапшырды. Ул 1941 елда

Шәйдуллин Газулла тарафыннан Ленинград өлкәсеннән Шайдуллина Сүриягә җибәрелгән. Хат гарәп графикасы нигезендә татар телендә карандаш белән, адресы шәмәхә каралы ручка белән язылган.

Түбән Тәкәнеш авылы кешесе Ибраһимов Айдар Вакыйф улы (1966 елгы) әбисе – Габдуллова Сәгадәтбануның «Аракы дигән эчемлек адәм заты өчен сарыф бер агудыр» (Казан, 1888 ел, Университет типографиясе, 15 бит) дигән басма китабын тапшырган. Аның исеме үк бүгенге заман өчен дә актуаль яңгырый.

Кече Сон, Түбән Шүләнгер, Ишки, Сәртек, Олыяз, Югары Кыерлы җирлекләрендә дә уңышлы гына эш алып барылды. Яхшы хәлдәге кулъязма китаплар (аларның берсе Югары Кыерлы авылы кешесе Кадыйршин Әхмәдулла Кадыйрша улыннан (1939 елгы) алынды), хатлар, ташбасма һәм ксерокүчермә, күп санлы басма китаплар җыеп алынды.

Кызганыч кайбер авылларда безнең өчен бер генә материал да табылмады. Мондыйларга керәшен татарлары яшәгән авыллар (Уткино һ.б.) һәм XX гасырның утызынчы елларында гына нигез салынган, чагыштырмача яшь авыллар керә. Соңгыларына мисал булып Хәсәншә авылы тора. Мөбарәкшина Факиһә Сәхәбетдиновна (1930 елда туган) әйтүенчә һәм тарихтан билгеле булганча, әлеге торак урынына 1929 елда Хәсәнша исемле бабай тарафыннан нигез салына. Яшәгән урында җирләр аз булу сәбәпле, башка гаиләләр дә урман уртасына күчеп утыра, җирне агачлардан чистарта башлый. Күбесенчә төп йорттан аерылып чыккан яшь гаиләләр күченү һәм ул чорда гарәп графикасындагы дини китапларга ихтыяҗ булмау гына түгел, аларның тыелган булуы сәбәпледер, монда безнең өчен бер генә материал да табылмады. Чөнки иске китаплар еш кына төп йортта кала торган булган.

Мамадыш төбәге һәм авылларының тарихы ерак гасырларга барып тоташа. Ул галимнәр тарафыннан өйрәнелгән, китапларга язылган. Ләкин халык күңелендә тарих башка үзенчәлекле формада яши. Ул олыдан кечегә сөйләнеп килгән риваятьләргә, борынгы чишмәләрнең сихәтенә, борынгы кабер ташлары урнашкан изгеләр җиренә ышана. Нәкъ шуның белән ул матур һәм кабатланмас та. Халык тудырган әдәби әсәрләр мәңге актуаль. Татар милләтенең рухи хәзинәсен, илһам чишмәсен барлау, көннән-көн кимеп баручы борынгы язма мирасны туплау бу өлкә белән кызыксынучыларны гади халыкка тагын да якынайта, аның бүгенгесен үткәне белән чагыштырырга һәм киләчәген фаразларга ярдәм итә.

## МАМАДЫШ УЛ – АЛГАРЫШ

*Фирдәвес Гарипова*

Мамадыш районы – Татарстандагы алдынгы төбәкләрнең берсе. Район үзәге дә, авыллары да бик матур. Мамадышның иң зур байлыгы – халкы. Халык искиткеч эшчән, булган һәм уңган биредә. Төрле конфессия вәкилләре бергә берегеп, кулга-кул тотынып дустанә яши, тырышып эшли. Бу күренеш күңелне сөендерә. Төбәк халкы киң күңелле, ярдәмчел. Шуңа күрә дә алар матур яшиләр, уңыш һәм дәрәҗәләргә ирешәләр. Татар халкының «Тырышкан табар – ташка кадак кагар» дигән мәкале мамадышлыларга да бик туры килә.

Әгәр Мамадыш шәһәре янындагы Биҗан тавы өстенә менеп карасаң, искиткеч матур манзара ачыла. Шәһәргә терәлеп диярлек Нократ суы ага. Яшеллеккә күмелгән Мамадышны ак каеннар тагын да бизи.

Мамадыш Ак кирмән буларак җир йөзенә милади буенча меңенче елларда Новгород ушкуй-башкисәрләренә каршы төзелгән болгар ныгыры-кирмәне буларак барлыкка килә. Бу хакта рус елъязмалары сөйли.

1859 ел мәгълүматларын эченә алган белешмәдә күрсәтелгәнчә, Ушма һәм Нократ елгалары ярларына утырган өяз шәһәре Мамадышның 569 хуҗалыгында 1783 ир-ат һәм 1836 хатын-кыз көн иткән.

Явыз Иван Казанны басып алгач, татарларга зур елгалар тирәсендә яшәү тыелган. XVII гасырда Мамадышка руслар килеп чиркәү салганнар һәм ул Троицкое авылы дип йөртелә башлаган, ләкин Мамадыш исеме дә сакланып калган. 1711 елда, Екатерина II (Әби патша) җирләргә генераль ызанлау үткәргәндә, шәһәрнең иске исеме яңадан кайтарыла. Шул ук елны Мамадыш өяз шәһәре итеп расланган һәм аның гербы булдырылган. Ул гербның өске өлешендә

канатлы аждаһа сурәте, аскы өлешендә яшел җирлектә ике көмеш урак һәм алар уртасында алтын көлтә гәүдәләнгән. Алтын көлтә бу төбәктә арышның күп уңыш биргәнлеген аңлаткан.

Мамадыш өязенә хәзерге Саба, Кукмара, Мамадыш районнары кергән. Бу өязгә караган 16 олыста (волостьта) 2433 кеше тегүчелек белән шөгыльләнә, 12 олыста 881 кеше киез итек басучылар, киез эшләпә, тула оек басучылар була.

В.П. Семенов наширлегендә дөнья күргән бер тарихи чыганакта Мамадыш турында болай искә алына: «Татарча кульъязма китап мәгълүматларына караганда, хәзерге Мамадыш шәһәре урынына элек Мамадыш – Мөхәммәт ишан, Мәмәтин исемле татар кешесе килеп утырган. Ул монда Тамерлан (Булат Тимер?) Болгарны җимергәннән соң килеп урнашкан булса кирәк. Ә инде XVII йөзләрдә бу тирәләргә руслар килеп Троицкое дип атыйлар. Авыл Богородицкое Зөя монастыре карамагында исәпләнә. 1617 елда монастырь үз вотчинасындагы запасларын күчмә нугайлардан саклау өчен ныгытма-авыл сала. 1781 елда авыл Казан наместничествосының өяз шәһәре статусы ала».

Мамадыш өязендә чәчүлек җирләре уңдырышсыз һәм ярлы була. Анда кара туфрак сирәк очрый, күбесенчә балчыклы, комлы җирләр өстенлек итә. Шул җирләрнең 12230 дисәтинәсе 11 алпавыт кулында, ә 2382 дисәтинәсе – 1943 ярлы крестьянга туры килгән.

Ул заманнарда җирләр тигез бүленмәгән, алпавытка 1800 дисәтинә булса, крестьянга аршынлап кына бирелгән. Җир өчен өзлексез көрәш барган.

Халык ачлыктан җәфа чиккән вакытта Ямбай авылында – Гласкин, Ныртыда – Макаров, Зайцев, Карпов, Тырышкиннар, Берсут тирәсендә – Чаблин, Лубян урманнарында Лебедевлар байлык арттыралар. Ак чишмә һәм Алкин авылларында Сәетгәрәй Алкин, Икшермәдә Юнысовлар батракларны тамак хакына гына эшләтеп кесә калынайталар.

1774 елның июлендә Мамадыш крестьяннары Емельян Пугачевны алкышлап каршы алалар. Пычак авылы кешесе Мәсәгут Гомәров өяздән 2000 нән артык гаскәр җыеп, Пугачев гаскәрләре сафына кушыла.

Өяздә берничә сәнәгать предприятиесе дә булган. 1883 елда Мамадышта Щербаков фамилияле сәүдәгәр спирт заводына нигез сала. Гражданнар сугышы башлангач, ул Парижга качып китә һәм шунда яши. Бу вакытта спирт заводы туктап тора. Моңа кадәр спирт ясау

өчен җирмәннәрдән (крестьяннардан) олау-олау бәрәңге ала торган булганнар. 1931 елда спирт заводы яңадан эшли башлый. Ул елларда Кукмарада Комаров һәм Вавиловларның киез итек фабрикалары да була.

1897 елда җан исәбе алганда Мамадышта 4200 кеше яшәве теркәлгән, анда ике чиркәү, өч башлангыч училище, шәһәр җәмәгатьчелеге китапханәсе, суднолар хәрәкәте конторасы һәм шәхси типография булган. 1900 елда шәһәр хуҗалыгының кереме 12 мең сум тәшкил иткән. Щербаковның аракы заводы 50 эшче тотып, ел саен 130 мең сумлык спирт җитештергән.

Мамадыш өязендә элек берничә урында (Нырты, Иске Оча, Кукмара авылларында) бакыр эретү заводы булган. Анда бары тик читтән китерелгән кешеләр генә эшләгән. Ләкин ул заводлар руда кытлыгы аркасында ябылганнар.

Мамадыштан дүрт чакрым читтә Изге чокыр дип аталган урын бар. Анда май аеның икенче яртысында Мамадыш һәм Алабуга өязләрендә яшәүче кешеләр гыйбадәткә килгәннәр.

XIX гасыр ахырында Мамадыш тирәләрендә бөтен Россияне тетрәткән бер авыр вакыйга була. Нократ елгасының аръягында рус һәм удмурт авыллары арасындагы сукмакта Мамадыш өязеннән килгән бер хәер эстәүченең мәетенә юлыкканнар. Шуннан соң, ул мескенне Вятка губернасының Малмыж өязендәге Иске Мултан авылы удмуртлары үтергәннәр, дигән хәбәр таралган. 1894 елның кышында шул эш буенча ун кеше хөкемгә тартылган. Нәтиҗәдә шуларның җидесе, рус кешесен корбан сыйфатында үтерүдә гаепләнеп, каторгага хөкем ителгән, өчесе акланган.

Гаепләнүчеләрне яклаган адвокат кассация шикаяте язгач, сенат, суд карарын юкка чыгарып, эшне башка составта һәм башка урында – Алабуга шәһәрендә карарга боерган. 1895 елның 1 октябрендә эш яңадан каралган, әмма антлы утырышчылар, яклаучы шаһитларны чакырудан баш тартып, гаепләнүче удмуртларны гаепләүне көчәйтә төшеп хөкем чыгарганнар һәм 7 удмурт, бөтен хокукларыннан, мөлкәтләреннән мәхрүм ителеп, сөргенгә озатылган.

Нәкъ шул чакта Алабугага гуманист язучы В.Г. Короленко килгән. Аның бу шәһәргә килүе «Мултан корбаны»на турыдан-туры бәйләнгән булган. В.Г. Короленко, мәрхүмнең «корбан» сыйфатында үтерелүенә ышанмыйча, суд процессында катнашкан. В.Г. Короленко судта газета хәбәрчеләре А.Н. Барасов һәм В.И. Суходеев

белән, крестьяннарның гаепсезлегенә инанып, суд башбаштаклыгына каршы торган. Ул Иске Мултанга барып, андагы кешеләрдән хәлнең ничек булганлыгын, гаепләнүчеләрдән һәм шаһитлардан сорау алуларның ничек эшләнгәнлеген белешкән. В.Г. Короленко удмуртларга каршы Мамадышта оештырылган өченче суд процессында мултанлыларның барысын да тулысынча аклауга ирешкән.

Заманасында өяздә башка күренекле кешеләр дә булып киткәннәр. 1855 елда Мамадышка Салтыков-Щедрин килеп чыга. Ул вакытта өяз исправнигы Иванов дигән кеше була. Аңа комсызлыгы өчен «тереләй ашаучы» дигән кушамат биргән булалар. Салтыков-Щедрин үзенең «Губерна очерклары» исемле әсәрендә прототип итеп шушы чиновникны ала. Себергә сөргенгә барышлый баржалар кәрванында язучы А.Н. Радищев уза. Ул үзенең көндәлегенә табигатьнең матурлыгын мактап яза. Бөркетләр тавын (Сокольи Горы) искә ала. Келәүш урманчылыгында Вера Фигнер балачагын уздыра. Аның әтисе урманчы булган. 1900 елда әнисе һәм өлкән апасы белән пароходта узып барышлый Омар һәм Соколка пристаньнарында В.И. Ульянов-Ленин да булган. 1919 елның җәендә Надежда Константиновна Крупская утырган «Красная звезда» агитпароходы Соколка пристанена туктый. Омар авылыннан яшь коммунист А. Булашова Н.К. Крупская белән сөйләшә. Крупская аңа китаплар һәм бер төргәк кәгазь биреп калдыра.

Мамадышлылар арасында батырлыклары белән дан алган шәхесләр байтак.

Кышкы сарайны штурмлый башларга сигнал биргән легендар «Аврора» крейсеры матросларының өчесе Нократ (Вятка) буе егетләре. Андрей Ведерников, Александр Бичурин – Отарка авылыннан, Иван Александров – Пойкинодан. Албай егете С. Домалазов Гражданнар сугышы тарихына «Албай Чапае» дигән исем белән кереп кала.

1918 елның 20 мартында Мамадыш өязе Советы башкарма комитеты каршында мөселман комиссариаты төзелә. Башта Гаяз Байкиев, аннары Басыйр Таҗетдинов комиссар булып эшлиләр. Өяз тарихында беренче тапкыр татар телендә «Мамадыш тавышы» исемле газета чыгарыла башлый.

Мамадышлылар Ватан сугышында да зур батырлыклар күрсәтәләр. Ватан сугышына Мамадыш районыннан барысы 13 мең кеше киткән. 7 меңе орден-медаль белән бүләкләнгән. Районда туып-үскән 4 геройның рәсеме район үзәгенең Мактау тактасына куелган: Албай авылыннан – И.Г. Максимов белән М.Н. Москвин; Хасан күлендә су-

гышкан, Берлинга барып җиткән Г.Н. Нигъмәтуллин; дүртенчесе – М.А. Просвирин. Алар дүртесе дә Алтын Йолдыз ияләре.

Мамадышның Биҗан (Пузан) тавы башындагы һәйкәл Совет власте урнаштыручылар истәлегенә булса, шәһәрнең үзәгендәге һәйкәл Ватан сугышыннан әйләнеп кайтмаган мамадышлылар хөрмәтенә күтәрелгән.

1919 елның апреленә өяздәге һәр авылда мәктәпләр ачыла. Татар авылларында мәктәпләр саны 215 кә җитә. Укытучылар әзерләү өчен махсус курслар ачыла. Мирза Фазлыйәхмәтов, Мөҗип Искәндәрев, Салих Билалов, Латыйп Гомәров, Иван Домолазов, хатын-кызлардан Галия Фазлуллина, Әминә Таҗетдинова, Зәйтүнә Гайнетдинова, Сара Касыймова кебек күренекле укытучылар калкып чыга.

Мамадыш районыннан түбәндәге күренекле шәхесләр чыккан: язучылар Шәйхи Маннур, Әхмәт Гадел, Зиннур Мансуров, Ринат Мөхәммәдиев, Басыйр Рәфыйков, Рафаэль Газизов, Нәзифә Кәримова, Шаһинур Мостафин, Марат Закир, композиторлар Фәрит, Заһидулла һәм Мирсәет Яруллиннар, җырчылар Мәрьям Рахманкулова, Миңгол Галиев, Георгий Ибушев, Гөлнәзирә Талипова, драма артистлары Хәлил Мәхмүтов, Дусил Касыймов һ.б.

Мамадыш шәһәре Казаннан 172 чакрымда урнашкан. Мамадышта мамык-җеп тукымалар комбинаты һәм «Спартак» аяк киемнәре берләшмәсе филиалы, спирт, сыр ясау заводлары бар, чүпрә заводы эшли.

Хәзер Мамадышта 15 меңгә якын кеше яши. Шәһәрдә өч урта мәктәп, мәдәният сарайлары, клублар, китапханәләр, кинотеатрлар бар.

**Алгай авылы** район үзәге Мамадыш шәһәреннән 42 чакрым ераклыкта, җирле үзидарә үзәге Көмешкүл авылыннан – 2, тимер юл станциясе Кукмарадан – 46, Гурьевка пристаненнан 20 чакрым ераклыкта урнашкан.

Алгай авылын Урта Өске, Алгай төрдәшләре белән И.А. Износков (1884) искә ала. Өскебаш суы ярына утырган авылда 169 ир-ат һәм 195 хатын-кыз көн иткән.

Диалектолог Нәҗия апа Борһанова мәгълүматларына караганда, Алгай авылы халкы күршедәге Югары Тәкәнеш, Түбән Тәкәнеш, Урта Тәкәнеш, Югары Козгынчы, Түбән Козгынчы, Кыраул, Түбән Дусай, Олыяз, Иске Чәбья, Яңа Чәбья, Шәмәк, Көмешкүл, Өске, Аксыбы, Казаклар, Түбән Өскебаш авыллары белән бергә июнь аеның икенче декадасында Тукташ җыены үткәргәннәр.

Өлкәннәрдән Әхмәтҗанов Әхмәтгариф сөйләвенә караганда, элек бу урыннар калын кара урман белән капланып алынган булган. Борынгы чорларда (кайчан килгәннәре бик билгеле түгел, кайбер кешеләр 880 нче ел дип тә әйтәләр) монда килеп урнашкан кешеләр агачларны кисәләр һәм шушында өйләр салып яшәп калалар. Ләкин зур корылык булган елны авыл халкы хәзерге Оренбург якларына китеп утыра. 1110 еллардан соң авылда яшәүче булмый. 1115 елларда гына авыл урынына чирмешләр килеп утырган имеш. Алар йортлар салып, җирне эшкәртеп авыл корып яши башлаган. 1415 елларда татарлар яңадан килеп урнаша һәм чирмешләрне урман эче буйлап куалар. Авылда Чирмешләр качкан сукмак дип йөртелә торган сукмак та бар. Килгән татарлар монда игенчелек белән шөгыльләнә башлыйлар. Авылны бу вакытта халык Урта Өске дип йөртә.

XV гасырлар да Урта Өске авылыннан ике кеше ат белән хәзерге Оренбург шәһәре тирәләренә баралар. Шунда алар Күк Тәкә исемле бер авылга кереп куналар. Алар кунган йортның хуҗасы ап-ак сакаллы бер карт була. Бу ачык йөзле матур карт алар белән бик яхшы итеп сөйләшә, кайсы яклардан килүләрен сораштыра. Юлчылар үзләренең Казан губернасы, Мамадыш өязе, Урта Өске авылыннан булуларын әйтәләр. Бу сүзләрне ишеткән йорт хуҗасы түбәндәгеләрне сөйли: «Сез әйткән авыл миңа бабай сөйләвеннән таныш. Минем бабалар хәзер сез яши торган Урта Өске авылында гомер иткәннәр. Ул авыл янында Өске елгасы ага торган булган. Ләкин алар бу авылда озак яши алмаганнар. Бик нык корылык булу сәбәпле, ачлыктан котылу өчен, күчеп китәргә мәҗбүр булганнар. Шушында күчкәч, иң беренче көнне күк тәкә суйганнар һәм үзләре яшәячак авылны Күк Тәкә дип атаганнар. Бабайлар шушы урында төпләнеп калганнар. Алар күчеп киткән авыл Алгай исемендә булган». Урта Өске кешеләре кире әйләнеп кайткач, халык белән киңәшәләр дә авыл исемен Алгай дип үзгәрткәннәр. Шул вакыттан бирле авыл Алгай исемен йөртә».

1930 елларда Алгай авылында колхоз төзелә. Колхозга «Трактор» исеме бирәләр. Аның беренче рәисе булып Шаһимәрдәнев Мөбарәкша эшли. Ул 1936 елга кадәр рәислек итә. Аннан соң рәис итеп Билалов Гомәр исемле кешене куялар. 1940 елда аны, халыкка проценттан тыш икмәк өләшкән өчен, хөкемгә тартып, төрмәгә утырталар. Шул китүдән соң ул кайтмый, эзсез-хәбәрсез югала. Аннан соң колхоз рәисе итеп Насыйбуллин Фәләхине сайлый-

лар. Ул 1944 елның көзенә кадәр эшли. Аны эшеннән чыгарганнан соң, Өшен башы дигән авылдан Мөхәммәдиев Низам дигән кешене рәис итеп куялар. Ул 1945 елның көзенә кадәр эшли. Шул рәвешле 1952 елга кадәр колхоз рәисләре гел алмашынып торалар. 1952 елда «Трактор»га рәис итеп Гатин Әхәт исемле кешене билгелиләр. 1954 елның 4 февралендә «Трактор» колхозы Көмеш күл авылында оештырылган колхоз белән берләшә. Ул «Искра» колхозы дип йөртелә һәм ул Көмешкүл, Алгай, Зур Өске авылларын берләштерә. Колхозлар таркала башлагач, «Искра» колхозы да бүлгәләнеп бетә.

Авыл матур җирдә, ямьле тау итәгенә утырган. Тирә-ягында нарат, каен урманнары, кырлар, болыннар. Якында гына Караңгы тау дип аталган урман бар. Авыл янәшәсеннән Өске суы ага. Өске суы Түбәнбай үзәнендәге чишмәдән башлана. Түбәнбай үзәне күршедәге Югары Өскебаш урманы уртасында.

Авылдан Ватан сугышына 98 ир-егет китә, ләкин күбесе кире әйләнеп кайта алмый.

Хәзер авылда 105 хуҗалык бар. Элек авыл зуррак булган, хуҗалыклар саны да 200 гә җитә язган.

Биредәге халык киң күңелле һәм кунакчыл. Өйләренә килеп керсәң, хуҗабикә сине кайнар чәй, хәзинәдә булган сые белән чәйләтмичә чыгармас. Һәммәсе эш белән мәшгуль, ләкин күңел ачуны да онытмыйлар.

Авылда йортларны матур итеп төзи беләләр. Аларга газ кергән, юлларга асфальт түшәлгән. Авылда башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, кибет эшли.

Әби-баба ята торган зират каралган, күмү әсбаплары тәртиптә. Зират тирә-юне тотып алынган, каберләр тазартылган, ташлар төз килеш утыралар.

Ялгыз яшәүче өлкәннәргә һәрдаим ярдәм итеп торалар. Күршекүлән аларны пешкән ризыктан һәм яккан мунчадан калдырмый, җирле үзидарә матди булышлык күрсәтә.

**Бөрсет (Бүрсет) авыллары.** Мәгълүм ки, Урта Идел буйларында катлаулы этногенетик процесслар булып узган, төрле төрки һәм төрки булмаган халыклар үзара тарихи, лингвистик бәйләнешкә кергәннәр. Бу бәйләнешләрнең тамырлары ерак гасырларга барып тоташа. Мондый бәйләнешләр авыл атамаларында бик ачык чагыла. Мамадыш районында Югары Бөрсет, Бөрсет-Сукачы, Бөрсет авыллары һәм Сухой Бурсет исемле бистә атамасы билгеле. Әлеге

авыллар Бөрсет/Бүрсет суы буена урнашканнар. Авыл атамалары һәм Бөрсет гидронимы билгеле бер тарихи чорда барлыкка килгән һәм, тарихи шартларга бәйле рәвештә, формасы һәм эчтәлеге ягыннан төрле үзгәрешләргә дучар булган.

Бөрсет-Сукачы авылында эпиграфист Һарун Йосыпов тарафыннан XVI йөзгә мөнәсәбәтле кабер ташы язмалары табылган. Бу таш археологлар тарафыннан да билгеләнгән. Бөрсет авылы Казан ханлыгы чоры документларында да искә алына. XVIII йөзнең икенче яртысында Бөрсеттә бакыр кою заводы эшләгән. Чималга кытлык булу аркасында завод һәм анда торган крепостной эшчеләр Златоуст заводы хуҗаларына сатыла. Бу вакытта (XIX йөздә) авылда 1000 гә якын кеше яши, мәктәп һәм мәчет була.

Бөрсет/Бүрсет атамасы «Казан губернасы авыл атамаларын исәпкә алу исемлекләре»ндә һ. б. тарихи чыганакларда теркәлгән.

А. Артемьев китабында күрсәтелгәнчә (1866), Кече Бөрсет (Владимир) авылындагы 75 хуҗалыкта 247 ир-ат һәм 304 хатын-кыз көн иткән. Югары Бөрсет (Кыерлы) авылындагы 91 хуҗалыкта 304 ир-ат һәм 299 хатын-кыз исәпләнгән. Троицкое (Урманчы, Бөрсет, Көек) авылында 98 хуҗалык булып, анда 299 ир-ат һәм 356 хатын-кыз гомер иткән. Кече Бөрсет авылындагы 15 хуҗалыкта 49 ир-ат һәм 55 хатын-кыз, ә Бөрсет-Елга (Бөрсет) авылындагы 36 хуҗалыкта 107 ир-ат һәм 102 хатын-кыз яшәгән. А. Износков хезмәтендә (1884) Югары Бөрсетнең Бөрсет һәм Кыерлы төрдәшләре күрсәтелгән. Авыл Югары Бөрсет инеше ярына утырган. Анда ислам динендәге 403 ир-ат һәм 361 хатын-кыз исәпләнгән. Д.А. Корсаков мәгълүматларына караганда (1908) Югары Бөрсет, Кыерлыда – 98 йомышлы татар, Кече Бөрсеттә – 63 керәшен, Бөрсеттә – 75 ясаклы татар, Бөрсет бакыр эретү заводында 23 оста (мастер) һәм эшче яшәгән.

Владимир (Кече Бөрсет) авылында 293 ир-ат һәм 338 хатын-кыз (иске керәшеннәр) яшәгән.

Бакыр заводы авылында рус милләтеннән булган 81 ир-ат һәм 88 хатын-кыз исәпкә алына. XVIII йөз башында Маленьков фамилияле кеше Бөрсет суы ярында бакыр таба, аны эшкәртү өчен завод сала һәм әлеге авылны нигезли.

Урманчы, Троицкое, Көек, Бөрсет, Кыерлы, Түбән авыл исемнәрен алган авылны И.А. Износков (1884) болай сурәтли: Авылда рус милләтеннән 160 ир-ат, 170 хатын-кыз һәм иске керәшеннәрдән

170 ир-ат, 195 хатын-кыз көн иткән. Авылны башта татарлар куе урман арасына нигезләгәннәр. Шуңа авылга Урманчы исеме бирелгән. Татарлар белән авыл янындагы йортын тау башына салган ниндидер кенәз идарә иткән. Ул тауны әле дә Кенәз тавы дип атыйлар. Руслар бу авылга XIX йөз башында (1884) Көек авылыннан күчеп килгәннәр. 1898 елдагы мәгълүматларга караганда, Кече Бөрсет пүчинкәсендә – руслар, Бөрсеттә (Урманчы) – руслар һәм керәшен татарлары, Кече Бөрсеттә (Владимир) – керәшен татарлары, Югары Бөрсеттә (Югары Кыерлы), Югары Сукачыда (Бөрсет-Сукачы), Түбән Сукачыда (Бөрсет-Сукачы) татарлар яшәгән. К.П. Берстель китабында Югары Бөрсет (Югары Кыерлы) авылында 1008, Бөрсет-Сукачы (Бөрсет) авылында 582 татар кешесе, Кече Бөрсет пүчинкәсендә (Бакыр заводы) 223 рус кешесе яшәгәнлеге әйтелә.

Нажия апа Борһанова мәгълүматларына караганда, Бөрсет-Сукачы, Югары Бөрсет (Кыерлы), Ташлык, Катмыш, Үсәли (Өчиле), Югары Сон, Яңа Сон, Түбән Сон авыллары халкы июнь ае ахырында Үсәли (Өчиле) җыены үткәргәннәр. Бу җыен башкача Кыерлы яисә Төенчек дип тә атала.

Бөрсет/Бүрсет атамасы берсел этнонимына күплек кушымчасы -т ялганып ясалган. «Берсула исемен мин Чистай шәһәреннән бераз югарырак урында Камага уң яктан килеп кушыла торган Берсула суы атамасы белән тәңгәлләштерәм», – дип яза Н.И. Ашмарин (1902).

Берсула (бәрсул) – урта гасыр гарәп чыганакларында телгә алына торган этноним. Болгарларның бер кабиләсе булган берселләр (берсетләр) Бөрсет суы бассейнына килеп утырганнар һәм су чыганагын үз исемнәре белән атаганнар. Якындагы авыл һәм бистә атамалары да елга исеменә мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килгән.

Тарихчы Р.Г. Фәхретдинов фикеренә караганда, Кама суының хәзерге Алабуга шәһәренә кадәр булган уңъяк яры җирләре, монгол яулары килгәнгә кадәр үк, болгарлар тарафыннан үзләштерелгән булган. Бәрсул этнонимының гидроним атамасы буларак ныгып калуы халыкның Кама аръягыннан күчеп килүе нәтиҗәсендә дә булырга мөмкин. Урта Идел буйларында Идел–Кама болгарлары дәүләте оешканга кадәрге чорларда әле бәрсуллар барсил исеме белән билгеле булганнар. Барсиллар – хәзәр дип аталган төрки халыклар тарихында эз калдырган Төньяк Кавказ һәм Каспий буе болгар-төрки кабиләләре булган.

Барсил-барсул һәм бәрсула (берсула) этнонимы төрдәшләренең бер нигезгә кайтып калуы шөбһә тудырмый. *А–ә* авазларының

чиратлашуы татар һәм башка төрки (уйгыр, төрекмән) телләр өчен дә хас. Бөрсет, Берсуат топонимы – берсел-барсул һәм барсил этнонимы фонетик төрдәшләренең күплек формасы. Бәрсут → Бүрсәт → Бөрсет атамасының фонетик яктан эволюциясе тәтүл → түтәл, тәгүл → түгел (Р. Әхмәтьянов) аналогиясе буенча бара. Болгар дәүләтендәге Биләр шәһәрендә барс сынының күпләп җитештерелүе дә гаҗәп түгел. Барс – Алтай, Көньяк Себер һәм Урта Азия тауларының көнчыгыш өлешендә яши һәм мәчеләр гаиләсенә керә торган ерткыч. Күрәсең, барс Төньяк Кавказ һәм Идел буе тирәләрендә яшәгән күп санлы болгар кабиләләре барсилларның табыну хайваны булып хезмәт иткән. Бу этноним ерткыч җанвар – унике еллык хайван календареның бер символы булган барс һәм кабиләләр, халык һәм дәүләт төшенчәләрен белдерә торган ил (ел) дигән ике борынгы төрки сүз кушылып ясалган. Шулай итеп, барсил сүзе кабилә, кабиләләр берлеге яисә барс халкы дигән мәгънәгә ия (А.Х. Халиков).

Билгеле булганча, барсиллар яисә көмеш болгарлар Идел һәм Кама буйларында төзелгән Болгар дәүләте халкының төп өлешен тәшкил иткәннәр. Үзләрен болгар һәм барсиллар патшасы дип атаган болгар патшалары да шулар арасыннан сайланган. Татар тарихчысы Шиһабетдин Мәрҗани фикеренә караганда, барс – болгар патшаларының тамгасы булып саналган. Барс культы бик борынгы чорга китә һәм скиф-сак заманалары культурасында чагылыш таба. Барс сурәте скиф-сак чоры сәнгате әсәрләрендә даими күзәтелә. Безнең эраның беренче меңьеллыгы ахырларында мөгезле барс төрки дөнья (болгар-бәҗәнәкләр) белән бәйләнешле кайбер тарихи шәхесләрнең символы булып хезмәт иткән. Болгар патшалыгында 852–898 елларда идарә иткән Барис ханның исеме дә барс сүзеннән килеп чыккан дип фараз ителә. Болгарларның дәвамы булган Идел буе татарларында барс байлык, дәрәҗә һәм уңдырышлылык билгесе булган. Татар халык иҗатында «Барс елы – байлык елы», «Барс елында бөтен әйбер әйбәт үсә», «Барс елында бөтен әйберне чәч» дигән мәкальләр сакланып калган. Аларның татар мәкальләрендә табылуы борынгы тарихыбыз белән бәйләнешле. Идел болгарларында барс сурәте югары катламга, кенәз һәм патшалар токымына керү билгесе булган (А.Х. Халиков).

**Бөрсет-Сукачы** авылы Мамадыш шәһәреннән 44 чакрымда, җирле үзидарә үзәге Өчиле (Үсәли) авылыннан – 2, Бөрсет пристаненнән 23 чакрым ераклыкта урнашкан.

Авыл матур җиргә утырган. Бер ягында урман үсә, икенче ягыннан Бөрсет суы сузылып ага.

Олылар сөйләве буенча, авыл Явыз Иван Казан ханлыгын еккан вакытларда барлыкка килгән. Казан ханлыгы тез чүктерелгәч, ханлыктагы халыкны чукындыру сәясәте башлана. Шундый чукындыручыларның бер төркеме хәзерге Владимир авылына якынлашып килгән көннәрдә, шул авылның өч кешесе үзләренең гаиләләре белән авылдан качып чыгып киткәннәр. Алар Бөрсет елгасының уңъяк ярына барып урнашканнар, ә бу вакытларда Бөрсет елгасы буйлары куе әрәмәлек булган. Качаклар көннәр җылы вакытта шалашларда яшәгәннәр, сөкә салып көн күргәннәр. Көннәр суыта башлагач, агач кисеп, йорт салып кергәннәр. Еллар үткән. Бөрсет елгасының уңъяк ярындагы йортлар саны ишәя барган. Шушы тирәләрдән үтеп баручы кешеләр болардан: «Сез кемнәр», – дип сорагач, «Без сөкәчеләр», – дип җавап биргәннәр. Шуннан соң бу авылның исеме Бөрсет-Сөкәче булып киткән имеш. Вакытлар үтү белән ул Бөрсет-Сукачы (Берсут-Сукачи) булып үзгәргән.

Урман буеннан башлап авылга төшкәнче дистәләрчә чишмәгә тап буласың: Мөтлек чишмәсе, Төн чишмәсе, Лаеш чишмәсе, Бабайлар чишмәсе, Кәмәй чишмәсе һ.б.

Елгалардан түбәндәгеләрне санарга мөмкин: Таш елгасы, Нарат елгасы, Мөтлек елгасы, Коры елга, Муллый елгасы һ.б.

Күлләр: Мунчала күле, Гали күле (соңгысының, әбиләр сөйләве буенча, урыны һәм исеме генә булган, ә суы булмаган).

Калкулыклар: Таллык тавы, Ферма тавы һ.б.

Авыл янындагы урман кырыеннан Тимер юл, Казан юлы, Мәшлек юлы һ.б. үтә.

Чабындык җирләрнең түбәндәге исемнәре бар: Мөхәммәтҗан планы, Гариф планы, Кыерлы кыры, Олы тау һ. б. Бер урынны Билле дип атыйлар.

Күперләр: Кәмәй күпере, Таллык тавы күпере һ. б.

Авыл янындарак кына Бөрсет елгасының сул ягында Алып баба чабатасын каккан урын бар. Хәзерге көндә ул урын Олы куаклык дип йөртелә.

Авылның мәчет манарасын XX гасырның 40 нчы елларында кискәннәр. Олылар сөйләвенә караганда, киселгән манара җиргә килеп төшү белән очындагы ае чәчрәп юкка чыккан. Күпме генә эзләсәләр дә, аны таба алмаганнар, ди.

Хәзерге вакытта авылда башлангыч мәктәп, клуб, медпункт бар.

Авыл кырыеннан асфальт юл үтә. Халык үзәкләштерелгән газ яга. Авылда мәчет ачылган.

Ялгыз әби-бабайларга күршеләре һәрчак ярдәм итеп торалар.

Бөрсет халкы зиратны карап, тәртиптә тота.

Шунысы куанычлы: соңгы елларда яшьләр күбрәк авылда төпләнә башлаган. Бу күңелдә зур өметләр уята. Димәк, авыл яшәячәк.

**Яке.** Атамаларында «җәке» (яке) берәмлеге булган авыллар Мамадыш районында урнашкан.Түбән Яке авылы район үзәге Мамадыш шәһәреннән 26 чакрымда, Югары Яке авылы җирле үзидарә үзәге Түбән Якедән 6 чакрымда, район үзәге Мамадыштан – 29 чакрым ераклыкта урнашкан.

Түбән Яке авылы зиратында соңгы Болгар – Алтын Урда чорына мөнәсәбәтле кабер ташлары һәм Түбән Яке зиратының көнчыгыш өлешендә, Омар суының уң ярында шул ук чорга нисбәтле авыл хәрабәсе билгеләнгән.

Югары Яке һәм Түбән Яке авыллары тарихи чыганакларда шактый еш телгә алына.

1859 ел мәгълүматларын туплаган тарихи белешмә буенча, Түбән Якенең 68 хуҗалыгында 289 ир-ат һәм 387 хатын-кыз гомер кичергән, мәчет эшләгән. Югары Яке авылының 48 йортында ислам динен тотучы 190 ир-ат һәм 203 хатын-кыз яшәгән, мәчет эшләгән. Түбән Яке авылы «Аграрный вопрос и крестьянское движение в Татарии XIX века» (М.-Л., 1936, с. 318–319) дип аталган тарихи чыганакта да телгә алына. Андагы халык мәдрәсәдә рус теле укытуга бердәм рәвештә каршы чыккан.

И.А. Износков белешмәсендә (1884) күрсәтелгәнчә Югары Якедә 221 ир-ат һәм 231 хатын-кыз, Түбән Якедә 322 ир-ат һәм 308 хатын-кыз яшәгән. Д.А. Корсаков белешмәсендә (1908) Югары Яке, Түбән Яке авыллары билгеләнгән. Югары Якедә – 63, Түбән Якедә 65 ясаклы татар яшәгән. К.П. Берстель белешмәсендә (1908) күрсәтелгәнчә, Түбән Яке авылында – 1020, Югары Якедә 792 татар кешесе яшәгән.

Н.Б. Борһанова мәгълүматларына караганда, Югары Яке авылы халкы күршедәге Урта Кирмән, Кече Кирмән (Кирмәнбаш), Арташ, Норма, Алан авыллары белән бергәләшеп Кирмән җыены үткәргән. Аны июнь уртасында бәйрәм иткәннәр. Түбән Яке авылы халкы Уразбахты авылы белән бергә берләшеп июнь ахырында Имән базары исемендәге җыен үткәргәннәр.

Хәзерге Мамадыш районындагы Түбән Яке һәм Югары Яке авыллары революциягә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязенә кергән. Авыллар яныннан Омар елгасы агып үтә.

Түбән Яке авылы биек җирдән караганда аеруча ямьле булып күренә. Көмештәй чиста сулы Көрәнче елгасы Инешкә кушыла. Авыл читендә ак таштан салынган фермалар тезелеп киткән. Арырак, басулар артында, офыкка сузылган урман. Кая карама, берсенән-берсе тәмле сулы чишмәләр чыга. Аларның исемнәре генә дә ни тора: Куен, Кызыл яр, Кушай, Серьги (тегермәнче рус кешесе Сергей хөрмәтенә шулай аталган), Мәүлет, Ташкисәр, Тау арты, Айман, Кама башы, Сулы-сусыз чишмә һ.б. Изгеләр чишмәсе дип йөртелгән чишмә авылда икәү. Берсенең суы салкынча, икенчесенеке – җылымса. Шул чишмәләрнең берсе баш һәм күз авыруларына файдалы, икенчесе йөрәк авыруларын сихәтләндерә, диләр. Шуңа күрә җәйнең матур көннәрендә чишмәләр буенда аларның шифалы суларын эчеп, юынып, тазарырга өмет баглап килүчеләрне еш күрергә мөмкин. Көмештәй саф сулы бу чишмә-кизләүләрне карап, чистартып торалар.Изгеләр чишмәләреннән өстәрәк кечкенәрәк зират та бар. Ул да изгеләр зираты дип атала.

Түбән Яке авылын табигать бик юмарт бүләкләгән. Елга-чокыр, тау битләре, урманнары төрле-төрле җиләкләргә, агач җимешләренә бик бай. Авыл уңайлы урынга утырган. Барасы килгән җиргә халык бик җиңел барып кайта ала, чөнки бакча башыннан гына Чаллы–Казан трассасы сузылган.

Олылар сөйләвенә караганда, элек авыл урынында мәһабәт һәм төп-төз нарат урманнары булган. Урын үзенең матурлыгы һәм тынычлыгы белән кызыктырган. Дәүләтшин Мөхәммәтхан һәм Вәлиев Гали абыйлар сөйләвенә караганда, авылга иң элек килеп урнашкан кешеләр тау куышлыкларында яшәгән булсалар кирәк. Тау битләренә урнашкан 5–6 куыш була. Һәр куышның авызын каплый торган капчыкларына кадәр сакланган вакытларны да хәтерли Мөхәммәтхан абый. Вакытлар узу белән ул куышлар җимерелеп бетә.

Куышта торучыларны халык төрлечә фаразлый. Явыз Иван патшалык иткән вакытта чукындырудан качып килгән татарлар булмагандыр алар, дип тә уйлыйлар.

Түбән Яке авылы ничек барлыкка килгән?

Мөхәммәтхан, Гали абыйлар, укытучы Хисмәтуллин Нурулла, Гафифә апа һәм башкалар авыл оешуны болайрак сөйләгәннәр иде.

Югары Яке һәм Түбән Яке авыллары башыннан Лашман юлы узган. Петр I заманнарында бу юлдан күп сандагы атлар белән имән һәм нарат агачларын бөтен буе белән Казандагы Адмиралтейство бистәсенә тарттыра торган булганнар. Ул агачлар кораблар ясау өчен киткән.

Түбән Яке белән Югары Яке авыллары арасында «Злом» борыны дигән урында агач тарттыручы атлы колонна туктап хәл ала торган була. Анда атларны ашату-эчертү һәм ял иттерү өчен абзарлар, лапаслар төзелә.

Казаннан 40 чакрым ераклыкта, Яшел Үзән районында Олы Җәке дигән татар авылы бар. Агач тарттыруда шул авыл кешеләре дә катнашкан була. Туктап ял иткән вакытта алар әйләнә-тирәгә күз салалар, тикшерәләр һәм бу урын яшәү өчен әйбәт җир булырга ошый дигән нәтиҗәгә киләләр. Урманга бай, чишмә-сулары күп, табигать җимешләре һәм нигъмәтләре дә чамасыз уңган урын кемне кызыктырмас?

Авылларына кайтып сөйләшәләр, киңәшәләр һәм хәзерге авыл урынына күчеп тә киләләр. Лашман юлының югары ягына утырганнары авылны Югары Яке, ә түбән ягына утырганнары Түбән Яке дип атаганнар. Димәк, Яшел Үзән районындагы Олы Җәке авылы белән Мамадыш районындагы Югары Яке һәм Түбән Яке авыллары тугандаш авыллар.

**Кирмән** авыллары бай тарихлары, данлы үткәннәре белән аерылып торалар. Урта Кирмән Мамадыштан 20 чакрымда, Кече Кирмән – 25, Рус Кирмәне – 18 чакрым ераклыкта. Бу авыллар Кирмән суы тирәсенә сырышып утырганнар.

Кирмән атамасы тарихи хезмәтләрдә, халык авыз иҗаты әсәрләрендә һәм башка чыганакларда еш искә алына.

Кирмән суы буенда заманасында Идел-Кама болгарлары – көмеш болгарлар билегенең баш шәһәре – Кирмәнчек хәрабәләре сакланган. С.М. Шпилевский бу шәһәрне Кирмәнчек дип, А.П. Смирнов Кернек рәвешендә теркәгәннәр. Кирмән шәһәре хәрабәләре янында Ханнар зираты дип аталган зиратта 1336, 1337, 1351, 1352 елларда куелган 14 кабер ташы табылган.

Кирмән авылы янында археологлар тарафыннан болгар чорына караган ике зират һәм авыл хәрабәләре билгеләнгән. Кирмән аланы яисә Кирмән бушлыгы («пустошь» – тарихи сәбәпләр аркасында буш калган җир) Казан өязенең теркәү кенәгәләрендә еш телгә алына.

Д.А. Корсаков җыентыгында (XVIII йөз) күрсәтелгәнчә, Урта Кирмән авылында 107 ясаклы татар, Кече Кирмәндә 127 йомышлы татар, ә Рус Кирмәнендә 151 икътисади крестьян һәм 32 керәшен татары яшәгән. А.А. Артемьев китабында Урта Кирмән (Татар Кирмәне) авылындагы 90 хуҗалыкта 278 ир-ат һәм 297 хатын-кыз яшәгәнлеге әйтелә. Анда мәчет эшләгән. Кече Кирмән (Кирмәнбаш) авылындагы 110 хуҗалыкта 586 ир-ат һәм 558 хатын-кыз көн иткән, авылда бер мәчет булган. Рус Кирмәне авылындагы 195 хуҗалыкта 581 ир-ат һәм 660 хатын-кыз исәпләнгән, авылда бер чиркәү булган. Казан өязенең Шура суы буенда А. Артемьев Кирмән пүчинкәсен билгеләгән. Андагы 25 хуҗалыкта 95 ир-ат һәм 111 хатын-кыз көн иткән.

Исемнәренә Кирмән сүзе кергән авыллар И.А. Износков (1884) игътибарын да җәлеп иткәннәр. Кече Кирмән яисә Кирмәнбаш авылында ислам динендәге 700 ир-ат һәм 800 хатын-кыз яшәгән. Авылны нигезләүче кеше Казан өязенең Күшәр авылыннан булган. Урта Кирмән яисә Татар Кирмәне авылында (ул – Кирмән ярына утырган) ислам динендәге 320 ир-ат һәм 330 хатын-кыз яшәгән. Бу авыл янында «шәһәр зираты» дип йөртелгән борынгы зират күрсәтелә. Авыл утырган урынны Хан-Кирмән дип йөртәләр.

К.П. Берстель хезмәтендә күрсәтелгәнчә, Кече Кирмәндә – 2206, Урта Кирмәндә (Татар Кирмәне) 1199 татар кешесе, ә Рус Кирмәнендә 1593 рус кешесе яшәгән.

Н.Б. Борһанова мәгълүматларына караганда, Урта Кирмән, Кече Кирмән, Кирмәнбаш, Арташ, Югары Яке, Алан авыллары халкы июнь ае уртасында (арыш чәчәк атканда) Кирмән җыены үткәргән.

Урта Кирмән олылары сөйләвенә караганда, авыл бик борынгы. Башта монда 4 кеше килеп утырган: Габделкәрим, Сәйфулла, Әпсәләм һәм Муса. Монда әле чирмешләр, чувашлар һәм арлар яшәгәннәр. Атау урамында чирмешләр, Җәке урамында чувашлар көн күргән. Алар ислам динен кабул иткәннәр.

Урта Кирмән авылында мин үзем Имән күпер, Татлы су, Коры, Тәкәрле, Шуайт, Сакаллы, Алтыбаш, Кызыл Яр, Тәкат сулары, Арташ суы, Сулы Тәкәрле, Ташлы су чокыры, Әрәмә чишмәсе, Бәди чишмәсе, Бәди күле, Иске Йорт, Татлы су чишмәләре, Изгеләр зираты, Кала, Карга таулары, Әрәмә коесы һәм башка топонимнарны язып алган идем.

Кече Кирмән авылын икенче төрле Кирмәнбаш дип тә йөртәләр, чөнки ул Кирмән суы башланган урында утырган. Авылда

чишмәләр шактый күп. Исемнәре түбәндәгечә: Әхмәт чишмәсе, Чегән чишмәсе, Бакырчы чишмәсе, Алмагач чишмәсе, Трайт чишмәсе, Бурсык чишмәсе һәм башкалар. Авыл халкының иң кадерләнә торган чишмәсе – Бакырчы чишмәсе. Аның тирәсендә, элекке Болгар ныгытмасы кебек итеп, дивар торгызылган һәм ике ягында калкан һәм сөңге тоткан болгар сугышчылары сыны тора. Чишмәгә керү урыны бик яхшы итеп эшләнгән.

Авыл халкы урам исемнәрен җанга якын исем-атамалар белән атап йөртә: Югары оч, Җәке урамы (күрше авылга бара торган юл), Урта урам, Байлар урамы, Түбән оч, Аскы урам яки Сукыр урам (анда өйләр бер яклы гына), Айрак (бу урам Кирмән суының икенче ягында урнашкан).

Авылда урта мәктәп, мәдәният йорты, балалар бакчасы, медпункт, мәчет, ике китапханә (берсе мәктәптә, икенчесе мәдәният йортында), элемтә үзәге бар. Авыл халкының тормышы нык, каралты-куралары әйбәт. Халык киләчәккә ышаныч белән карый.

Кече Кирмән авылында язучы Ринат Мөхәммәдиев, шагыйрь һәм педагог Рафаил Газизов туган.

Лаеш районында да Ташкирмән исемле авыл бар. Бу авыл Казан ханлыгы чорында да булган.

Яшел Үзән районы Тау иле авылы яныннан Әрә кушылдыгы Кирмәнле суы агып үтә. Аның буенда Иске Кирмәнле һәм Яңа Кирмәнле авыллары очрый. Яннарында С.М. Шпилевский шәһәр хәрабәләре билгеләгән. Бу авыллар исеме һәм елга атамасы Зөя өязенең теркәү кенәгәсендә дә (1565–1567 елларны эченә ала) күрсәтелә.

Галимнәр фикеренә караганда, *кирмән/кермән* сүзе болгар-хәзәр чорларында ук шәһәр мәгънәсендә кулланыла башлаган.

Кирмән сүзе кергән географик атамалар төрки халыклар кайчандыр яшәгән һәм хәзер яши торган урыннарда очрый. Мәсәлән, Мамадыш шәһәренең халыкта йөргән тарихи исеме Ак Кирмән яисә Мәмәтиш Кирмәне. Башкортстанның Ярмәк районында Кирмән тавы бар. Касыйм шәһәренең икенче исеме Ханкирмән. Аккирмән – Оренбург өлкәсендәге шәһәр тибындагы бистә. Ука суы бассейнында Кирмән чокыры бар. Марилар Укирмән дип Түбән Новгородны, Чәтән Кирмән дип хәзерге Йошкар-Ола шәһәрен атаганнар. Терек-Сулак елгалары арасында Хәзәр каганлыгының Германчик дип аталган ныгытмасы булган. Аккирмән (Аккерман) – Одесса өлкәсендәге Белград-Днестр шәһәренең элекке исеме, Сары Кир-

мән дип элек Севастополь шәһәре аталган. Бейкерман – Симферополь округындагы авыл. Ул Инкерман (Өнкирмән) – шәһәреннән көньяк-көнчыгышка таба алты чакрым еракльгкта урнашкан. Кирмәнчек – Кырым өлкәсенең Бакчасарай районындагы елгачык, Кермен – Кырымдагы туристлар базасы. Янә бер Кирмәнчек – Кирмән-Баир (бәер – калкулык) исемле тау итәгендәге авыл Кача кирмән, Өн кирмән. Керменчецкий исемендәге чокыр Кырым өлкәсе, Бакчасарай районында. Урта гасыр чыганакларында Киев шәһәре Ман Кирмән (Зур Кальга), бүгенге Каменец-Подольск – элек Таш Кирмән дип аталган. Иранның угыз телле халыклар яши торган төньяк өлешендә Керман исемле чүл һәм шәһәр бар. Галимнәр Болгар дәүләтенең сасанилар Ираны белән бәйләнеше шактый нык булуын әйтәләр. Һарун Йосыпов болгар гамәли сәнгатенең шушы Ирандагы сасанилар дәүләте мәдәнияте белән охшаш берәмлекләре булуына игътибар итә.

Каюм Насыйриның «Әбугалисина» исемле маҗаралы хикәятендә Кирман патшалыгының телгә алынуы да очраклы хәл түгел.

**Тулбай авылы** район үзәге Мамадыш шәһәреннән 35 чакрымда урнашкан. Авыл тарихи чыганакларда, халык авыз иҗаты әсәрләрендә чагылыш таба. Д.А. Корсаков җыентыгында Тулбай авылында 80 ясаклы татар яшәгәнлеге күрсәтелә. Ышия (Чия) суы янына утырган Тулбай авылын А. Артемьев болай сурәтли: «Авылдагы 78 хуҗалыкта 222 ир-ат һәм 224 хатын-кыз көн иткән. Авылда мәчет булган». И.А. Износков хезмәтендә дә Тулбай искә алына. Анда 1884 елда ислам дине тотучы 274 ир-ат һәм 263 хатын-кыз көн күргән. 1898 елгы китапта Тулбай авылында татарлар яшәгәнлеге искәртелә. К.П. Берстель белешмәсендә (1908): «Тулбайда барлыгы 734 татар кешесе көн иткән», – дип әйтелә.

Тулбай авылы халкы күршедәге Югары Тәкәнеш, Түбән Тәкәнеш, Урта Тәкәнеш, Югары Козгынчы, Түбән Козгынчы, Түбән Дусай, Олыяз, Иске Чәбья, Яңа Чәбья, Шәмәк, Көмешкүл, Алтай, Өске, Аксыбы, Югары Өскебаш, Түбән Өскебаш авыллары белән июнь аенда Тукташ җыенын бәйрәм иткән. Бу җыен-бәйрәм шушы тирәдәге 18 авылны берләштергән (Н.Б. Борһанова).

Авылны нигезләгән халык, аз-азлап, урман ачкан, басу-кырлар ясаган. Ышна басулары, аерым алганда Әрәкәй ышнасы, Җамбик ышнасы, Гыйззәт ышнасы, Гали әрчүе, Янык үре, Наратлык һ.б. атамалар монда элек калын урманнар булуы турында сөйли.

Тулбай авылы Ышия суы буена утырган. Ышия суын Тулбай халкы Инеш дип тә атый. Инешкә коя торган су чыганаклары байтак. Кирәмәт елгасы суын Ышлаңгыр инешенә коя, Ышлаңгыр суларын Ышиягә илтә. Бәкәш, Үзән асты, Гобәй үзәне, Бокырлы, Кызлар, Мусалау, Бака тармагы, Сазтамак, Шаңгыр, Акма, Тәртә, Бүре, Кабык күпер, Ташлы елга-инешләре суларын Ышия елгасына коялар. Шаңгыр елгасында Гөбердәвек исемле шарлавыкның тавышы ерактан ук ишетелеп тора. Йөзмән, Аю, Зәйкә күлләре Ышия суы бассейнында урнашканнар. Тулбайда Кара чишмә, Аргы, Бирге, Бокырлы һәм Салкын чишмәләр бар. Кара чишмәнең суы үзалдына кара-кучкылланып тора. Авылда Салкын кое, Бәкәш коелары бар.

Җамбак, Түбәнге Әрәкәй, Югары Әрәкәй кебек аерым урын исемнәре игътибарны җәлеп итә. Авыл янында үзәннәр дә байтак икән (Җәгъфәр, Караңгы, Марҗа, Гобәй, Ниги үзәннәре). Авыл тирә-юнендәге калкулык-таулардан Кәҗә тавы һәм Иске тауны күрсәтергә мөмкин. Иске тауны тулбайлылар заманында Дусай авылы халкы белән даулашып үзләренә алганнар.

Тулбайда хуҗалыклар саны 200 дән артык. Авылда мәчет эшли. Халык әби-баба күмелгән зиратны карап, чистартып тора.

Тулбай авылында язучы Шәйхи Маннур (Шәйхелислам Фәрхулла улы Маннуров, 1905–1980) туган. Авылда аның мемориаль музее эшли. Татарстан Язучылар берлеге һәм Мамадыш районы хакимияте Шәйхи Маннур исемендәге әдәби бүләк булдырган.

Минзәлә районында да Тулбай авылы бар. Ул район үзәге Минзәлә шәһәреннән 24 чакрымда урнашкан.

**Югары Сон, Кече Сон, Урта Сон, Түбән Сон** исемен йөртүче татар авыллары Мамадыш районында, чал Камага уң яктан килеп кушыла торган борынгы Бөрсет (Бүрсет) суының сул кушылдыгы Сон суы буена урнашканнар. Яңа Сон дип аталган авыл хәзер беткән. Халык сөйләве буенча, бу авыллар арасында борынгырагы – Урта Сон. Кама аръягындагы Биләр тирәсеннән бу якларга өч улы белән бер карчык килеп урнашкан. Бер улы – Түбән Сонны, икенчесе – Кече Сонны, өченчесе Югары Сонны нигезләгән. Болар килгәндә Урта Сон авылы булган инде. Авылларның тирә-юнендә борынгы чорлар белән бәйләнешле истәлекләр шактый сакланган.

Кече Сон аксакаллары сөйләвенә караганда, авыл бу урынга 350 еллар элек күчкән. Аңа кадәр авыл Сон елгасы буйлап чакрым ярым тирәсе өстәрәк урнашкан була. Яңа урынга беренче булып

Солтан исемле кеше бик матур чишмә буена килеп утырган. Шуңа күрә авыл уртасындагы искиткеч тәмле сулы көчле чишмә Солтан чишмәсе дип атала.

Сон авыллары барысы да, нигездә, бер чорларда, XVII йөздә барлыкка килгәннәр. Авыл халкыннан язып алынган географик атамалар, шәҗәрәләрдәге исемнәр, Сон атамасының тарихи-статистик, тарихи-географик чыганакларда исәпкә алына башлавы шушы чорга карый.

Д.А. Корсаков чыгарган «Сборник материалов по истории Казанского края в XVIII в.» (Казан, 1908) дигән җыентыкта Кече Сон, Урта Сон, Югары Сон авылларының Сон суы буенда тезелешеп утырулары күрсәтелгән. Бу авылларда ясаклы татарлар яшәгән. Аерым алганда Түбән Сон авылында – 123, Урта Сонда – 101, Кече Сон (Байгилде пүчинкәсе) авылында – 103, Югары Сонда 91 ясаклы татар көн иткән. А. Артемьев китабында Сон авылларына түбәндәге сыйфатлама бирелә: «Бөрсет (Бүрсет) суы янына утырган Югары Сон авылындагы 155 хуҗалыкта 451 ир-ат һәм 496 хатын-кыз яшәгән, авылда бер мәчет булган. Кече Сонда (Байгилде пүчинкәсе) 134 хуҗалык булып, 421 ир-ат һәм 433 хатын-кыз исәпләнгән, авылда бер мәчет эшләгән. Урта Сон авылындагы 91 хуҗалыкта 285 ир-ат һәм 216 хатын-кыз гомер кичергән, мәчет булган, ә Түбән Сондагы 156 йортта 508 ир-ат һәм 581 хатын-кыз гомер иткән, авылда мәчет эшләгән». «Аграрный вопрос и крестьянское движение 50–70-х годов XIX в.» дип аталган китапта 1871 елның 12 август датасы белән Түбән Сон һәм Урта Сон авыллары искә алына. Бу китапта урнаштырылган бер документта әлеге авыллар халкының җир өчен даулашуы турында сүз бара.

Чыганакларда Кече Сонның атама төрдәше – Байгилде пүчинкәсе – Чүчебаш чишмәсе янына утырган авыл дип күрсәтелгән. Ул Сон суы буена утырган, анда ислам динендәге 522 ир-ат һәм 481 хатын-кыз яшәгән. Авыл кайчандыр мөстәкыйль яшәгән Байгилде һәм Чүчебаш пүчинкәләреннән оешкан.

Югары Сон авылында ислам динендәге 454 ир-ат һәм 570 хатын-кыз көн иткән. Түбән Сон, Урта Сон авылларында ислам динендәге 337 ир-ат һәм 330 хатын-кыз яшәгән.

Югары Сондагы мәчет берничә тапкыр яңадан төзелә. 1897 елның сентябрь аенда Казан губерна идарәсе дин тотучыларга 1877 елда янган мәчет урынына яңасын төзергә рөхсәт бирә.

Мәчет төзелә һәм ул ун ел хезмәт иткәннән соң, губерна идарәсе 1906 елның 7 июлендә яңа мәчет салырга ризалык бирә, 1907 елга мәчет төзелеп бетә. Мәхәллә зур була, 321 хуҗалыкка 719 ир-ат туры килә.

Бу яктагы авыл һәм су атамасын соңгы елларда Сөн дип йөртү гадәткә кереп китте. Эш барышында мин бу авылларда булып, бу хакта аксакаллар белән сөйләшкән идем. Җирле халык авыл исемнәрен һәм суны Сон дип сөйли. Экспедиция вакытында мин беркемнән дә Сөн атамасы куллануны ишетмәдем. Борынгы тарихи чыганакларда да су һәм авылларның исеме Сон дип языла. Сон атамасын Сөнгә үзгәрткән өчен халык үпкәли. Татарча басылган тарихи хезмәтләрдә Сон, рус телендә язылганнарында исә ул Сун, Сунь дип, Сон атамасына туры китереп язылган. Сөн суы да бар. Ул җөмһүриятебезнең көньяк-көнчыгыш төбәгендә ага һәм Агыйделгә сул яктан килеп кушыла. Сөн атамасы да – билгеле тарихи атама. Ләкин, Сон һәм Сөн атамалары бер тамырга кайтып калсалар да, икесе ике атама. Икесе ике урында урнашкан, төрлечә – Сон һәм Сөн әйтелешендә кулланыла. Аларның әйтелешен берләштерергә һич кирәкми һәм ярамый. Бу ояга тагын шулай ук Ык суының уң кушылдыгы Өсән (Башкортстан) гидронимын да кертәбез.

Хәзер Түбән Сон һәм Югары Сон авылларының географик атамаларына тукталыйк.

Түбән Сон халкы хәтерендә географик атамалар шактый күп сакланган. Бөгелдә елгасы, Айкичү елгасы, Ачы суы, Әйләнә елгасы, Караңгы елга, Шәпи елгасы, Майлы елга, Тоснакай елга, Козгын елгасы, Җәйге елга, Темкә елгасы, Алачын елгасы; Сай кичү чишмәсе, Теләүле чишмә, Рәхмәт чишмәсе, Ак чишмә, Урта Сон чишмәсе; Күл кое, Түбән кое, Югары кое; Катмыш күпере болыны, Җитәкән асты болыны, Чат куагы болыны, Бозау киртәсе болыны; Искәндәр аланы, Зәйни аланы, Рәхмәтулла аланы. Урам исемнәре дә үзенчәлекле: Кирәмәт урамы, Тәкәрлек урамы, Күл урамы, Урта урам, Кече урам, Бөгелде урамы, Шалкан урамы, Колышчы урамы, Арт урам.

Югары Сон авылы янында да географик берәмлекләр шактый, атамалары үзенчәлекле: Дәйнәш, Зирекле (Җирекле), Күмәкәй, Бурсык, Чүкәр, Чурна, Кирәмәт, Типкән, Корсада, Әптеш, Илебез, Аракы, Төлке, Усаклы, Җизи йөрәге, Әҗмәк тау асты, Аргы Кормаш, Бирге Кормаш, Кәбир елгалары; Мәрҗекә, Күмәкәй, Оркын, Кормаш, Типкән, Әҗмәк тавы, Акый, Бокыр, Зират чишмәләре; Казак

атавы, Мәчкә, Галәви, Оркын таулары; Диңгез аланы, Үтәш юлы, Сукыр урам.

Кече Сон авылы бай табигатьле, ямьле урынга урнашкан. Авылның тирә-юнендә географик берәмлекләр байтак, атамалары элекке вакыйгаларның шаһитлары буларак бирелгән. Тирән елга, Беләртә елгасы, Кирәмәт елгасы, Печәнлек елгасы, Өчиле елгасы, Ышна тавы елгасы, Миннәчә елгасы, Чучи елгасы; Зират асты чишмәсе, Кирәмәт чишмәсе, Чучи яки Изгеләр чишмәсе, Солтан чишмәсе, Олы кое яки Шәкертләр чишмәсе; Мәсәлим аланы, Дияр аланы, Мәрхүбә аланы, Габдул чүнниге, Хәзрәт чүнниге аланы; Беләртә юлы, Иске авыл юлы, Өчиле юлы, Яке юлы, Кирмәнбаш юлы, Урта Сон юлы, Владимир юлы. Авыл урамнарын халык үзенчә, күңеленә хуш килердәй итеп һәм географик мохиткә карап кушкан: Түбән оч, Өчиле урамы, Саз урамы, Тау башы урамы, Югары Сон урамы.

Кече Сон авылында композитор Заһидулла Яруллин (1888–1964), аның уллары – композиторлар Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Фәрит Яруллин (1914–1943), Татарстанның һәм Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе Мирсәет Яруллин (1938) туып үскәннәр.

**Өчиле (Үсәли) авылы** район үзәге Мамадыш шәһәреннән 42 чакрым ераклыкта урнашкан. А. Артемъев (1866) авыл турында түбәндәге мәгълүматларны бирә. Бөрсет суы янына утырган Өчиледә 64 хуҗалык булып, анда 256 ир-ат һәм 260 хатын-кыз көн иткән. Авылда бер мәчет эшләгән. Өчиле авылын И.А. Износков (1884) та игътибарга ала. Бөрсет буена утырган бу авылда ислам динендәге 330 ир-ат һәм 340 хатын-кыз яшәгән. Анда шулай ук христиан диненә көчләп чыгарылган 10 ир-ат һәм 12 хатын-кыз көн иткән. Иске керәшеннәр (3 гаилә) бу авылга 1840 елда күрше авыллардан күчеп килгәннәр. 1898 елгы китапта бирелгән мәгълүматларга караганда, Өчиле авылында татарлар тормыш иткән. К.П. Берстель (1908) җыентыгында әйтелгәнчә, Өчиле авылында 964 татар кешесе яшәгән. Д.А. Корсаков белешмәсендә (XVIII гасыр, 1908 ел) күрсәтелгәнчә, авылда 81 йомышлы татар көн иткән.

Нажия апа Борһанова мәгълүматларына караганда, Өчиле, Катмыш, Бөрсет-Сукачы, Югары Бүрсет (Кыерлы), Ташлык, Югары Сон, Яңа Сон, Түбән Сон авыллары халкы июнь ахырында Өчиле җыены үткәргән. Бу җыен башкача Кыерлы яисә Төенчек дип аталган.

Авыл аксакаллары сөйләве буенча, авылга 1552 елда нигез салынган. Анда беренче булып Йонсай, Тукый һәм Бигеш (Биги) исемле агайлар килеп утырганнар. Аларны Чаллы ханлыгыннан чыккан кешеләр дип әйтәләр.

**Өчиле** (Үсәли) исеменең килеп чыгышын төрлечә аңлаталар.

Диалектолог Леонид Арсланов, И.А. Износков мәгълүматларына таянып, Усалине мари телендәге *у* («яңа»), *сола~сала* («авылы») сүзләреннән ясалган, ди. Хәзерге вакытта, күпләгән яңа мәгълүматлар җыелган заманда, И.А Износков чабуына бернинди тәнкыйди карашсыз ябышу гаҗәпләндерә. Г.Ф. Саттаров Усали атамасын удмуртларның *воршуд* (ыру) исеме *уса~уча* («сандугач») сүзенә кайтарып калдырырга тырыша.

Үсәли авылында туып үскән, авыллар тарихы белән кызыксынучы Мансур Фазылов[1] авыл исеменең *өч өйле* сүзеннән килеп чыгуын, вакытлар үтү белән аның *Усюли ~ Усалигә* әйләнеп китүен күрсәтә. Кайбер документларда авылны Сули дип тә язганнар.

1860 елдан башлап 1875 елга кадәр Казан губернасын гына түгел, бөтен Рәсәйне дер селкеткән халык күтәрелешләре булып узган. Шул вакытларда киң халык массаларын әйдәп баручы сәләтле җитәкчеләр чыккан. Алар арасында Бәхтияр Канкаев аеруча игътибарга лаек. Ул гаскәре белән Мамадыш якларында да булган, 1774 елның июнь башында Е. Пугачевның Казанга һөҗүме башланыр алдыннан Мамадыш ягындагы авыл халкын көрәшкә өндәргә килгән. Бу як авыллары халкы Пугачев гаскәрләре сафына кушылган. 1774 елның 10 июлендә Үсәлидән Балтай Сәфәров, Кормангали Унгаров, Тимербай Ишбулдин, Дәмин Зәитов үз теләкләре белән Бәхтияр Канкаев гаскәренә кушылганнар. Документлардан күренгәнчә, Канкаев гаскәренә болардан башка Югары Кыерлы авылыннан 7 кеше, Күк Чишмәдән – 2, Урманчыдан – 5, Түбән Якедән 8 һәм бүтән авыллардан да төрле сандагы кешеләр кушылган. Тирә-як авыл халкы телендә сакланган Бәхтияр юлы, Бәхтияр күпере дип йөртелгән атамалар Бәхтияр Канкаевка нисбәтле.

Билгеле булганча, 1718 елда Казанда Адмиралтейство корылып, Петр I җитәкчелегендә патша флоты өчен кораблар ясау башлана. Моның өчен бик күп имән агачы кирәк була. Бөрсет суы буенда-

---

[1] Өчиле авылы тарихын язганда Мансур Фазыловның да мәгълүматлары файдаланылды.

гы имәннәр аеруча кулай булып чыккан һәм шуңа күрә урманнарны хөкүмәт аерым исәптә тоткан. Бөрсет имәннәрен егу һәм аларны Кама елгасы ярларына тарттыру Үсәли һәм башка авылларның ир-егетләре җилкәсенә төшкән һәм алар лашманчылык белән шөгыльләнгәннәр. Бу бик авыр хезмәт булган.

1897 елда Россиядә җан исәбе алу башлана. Казан губернасында яшәүче халыклар патша хөкүмәтенең бу эшен көчләп христиан диненә күчерү өчен башкарыла дип кабул итәләр һәм төрле юллар белән аңа каршылык күрсәтәләр. Авылларга җәза отрядлары килеп, крестьяннарны камчылыйлар, мал-мөлкәтләрен талыйлар, хатын-кызларны мәсхәрәлиләр. Бу фаҗигале вакыйгага багышлап халык бәетләр чыгарган. «Перепись бәете», «Бакырчы бәете» әнә шул каһәрләнгән еллар турында сөйли.

Ул елларда Түбән Сон волосте идарәсе Үсәли авылына күчерелгән була. Волость конторасы вакытлыча хәзерге Нурулла Гариповлар ихатасындагы агач йортка урнаша.

Көннәрдән бер көнне җан исәбен алу өчен волость конторасына бик күп кәгазьләр кайтаралар. Тирә-як татар авылларында, кәгазьләр мөселманнарны чукындырыр өчен кайтарылган икән, дигән хәбәр тарала. Бу хәбәр халыкның тынычлыгын боза. Янгын сараенда җыелып утырганда да, Үсәлигә базарга сату-алу белән киткәндә дә сүз гел шул хакта бара. Унике авыл җыелып сөйләшеп, киңәшәләр дә, властьларга каршы чыгарга, волость идарәсен туздырырга, кәгазьләрне яндырырга дигән карарга киләләр. Бу эшне 31 декабрьгә, базар көнгә билгелиләр, властьлардан үч алуны базарга җыелган халык көче белән башкарып чыгарга уйлыйлар.

1897 елның 31 декабрендә Үсәли авылы уртасындагы мәйданга зур базар җыелган көнне халык арасында чуалыш чыга. Ярсыган халык төркеме волость идарәсенә килеп керә.

– Кәгазьләрне безнең күз алдында яндырыгыз, сез безнең башка яңа бәлаләр әзерлисез, – дип кычкыралар. Писер баш тарта. Халык аны һәм стражникны кыйнап ташлый, контораны туздыра, тәрәзәләрне вата. Бәһман старостаны, Түбән Сон тегермәнчесе рус кешесен, Владимир чиркәвенең дьячогын каты кыйныйлар. Халык төркеме югары очка юнәлә, текә яр читендә яртылаш төзелгән волость идарәсе бинасын ватып-җимереп бетерә. Авыл кичкә кадәр корт оясыдай гөжләп тора.

Бу вакыйгадан соң ике көн үтә. Халык шомланып көтә... 1898 елның салкын гыйнвар иртәсендә Үсәлигә кораллы казаклар төркеме килеп керә. Авыл тирәли сак куела, беркемне дә авылдан чыгармыйлар. Фетнәчел авылны «акылга утырту» башлана. Һәр йортка өчәр казак урнаштыралар. Йөзләп казакны, аларның атларын ашату, туендыру халык иңенә төшә. Һәр көнне казаклар өчен авыл халкының бер сыерын суялар. 1891 елгы ачлыктан соң тернәкләнеп килүче Үсәли крестьяннарын бу афәт яңадан аяктан ега.

Хәлләрнең тагын да яманрагы Түбән оч күпере янындагы мәйданда була. Ул елларда Закир Мисбахов өе каршында каравылчы йорты торган. Шушы урынга тирә-як авыллардан фетнәдә катнашучыларны җыялар. Олаулап китерелгән тал чыбыклары олы казанда пешеп тора. Фетнәчеләрне озын эскәмияләргә салып суктыру башлана. Һәр кешегә йөзәр чыбык сугалар, аркаларыннан каннар чәчрәп чыга. Үлем хәленә килеп аңсызлангач, аларны каравылчы йортына кертеп ташлыйлар. Бернинди гаебе булмаган кешеләрне дә чыбык белән суктыралар. Фетнәне башлап йөрүчеләрдән 29 кеше кулга алына. Судка кадәр аларны 5 ай буе сак астында тоталар. Май аенда суд була. Суд крестьяннарны башбаштаклыкта, писерне кыйнауда, хезмәт урыннарындагы кешеләрне вазифаларын үтәгән вакытта мәсхәрә итүдә гаепли. Егерме җиде кешене 2,5–3 елга кадәр срок белән хөкем итеп, богаулар кидереп, Саратов төрмәсенә озаталар. Мәхбүсләр арасында Үсәлидән Гыйззәтулла Ибраев, Мөхәммәтҗан мөәзин, Әхмәтҗан Мөхәммәтҗанов, Сәйфетдин Шәймиев, Миңлевәли Хафизуллин, Әхмәт Дикәев була.

Үсәли авылы үзенең дәрәҗәле базары белән дан тоткан. Бөрсет буенда элек-электән һөнәрле халык яши. Бу табигый хәл. Кайда җир аз, туфрак ярлы, шунда кәсеп-һөнәр үскән. Тау буйларындагы көлсу туфраклы, кечкенә генә басулар авыл халкын үзенең уңышы белән бер дә куандырмаган. Шуның өстенә бу төбәктә халык тыгыз утырган. Бер-ике чакрым китәргә өлгермисең, авылга килеп төртеләсең: Ташлык, Кече Бөрсет, Югары Бөрсет, Үсәли, Бөрсет-Сукачы, Баскан, Катмыш...

Җир-су кытлыгы крестьянны икенче кәсеп эзләргә мәҗбүр иткән, шуның нәтиҗәсендә Бөрсет буе авылларында һөнәр осталары барлыкка килгән. Бер авылда арба-чана ясасалар, икенчесендә бау ишү, чыпта, кап сугу, чыбыктан үреп төрле әйберләр ясау белән шөгыльләнгәннәр, өченчеләре кирпеч суккан, агач яндырып күмер

әзерләгән. Хәтта авыл атамалары да халыкның кәсеп-шөгыле турында сөйли. Сукачыда (Бөрсет-Сукачы) сөкә салып балык тотканнар. Колышчыда киндер сугу станогына кылыч ясаганнар. Урманчыда урман эше зур урын тоткан. Һөнәрче товарын төяп Чистай, Теләче, Арча базарларына, төрле ярминкәләргә чапкан, хәтта башкорт җирләренә кадәр барып җиткәннәр. Крестьяннарның әле сатлык терлеге, терлекчелек продуктлары һ.б. була. Сату-алу белән гел ерак базарга йөри алмаганнар. Базар ясау өчен иң кулай урын итеп Бөрсет елгасының урта бер җирендә урнашкан Үсәли авылын сайлаганнар. Тарихи чыганакларга игътибар итсәк, базар ачылу вакыты үткән гасырның икенче яртысына туры килә. Туксанынчы еллар ахырында Үсәлидә инде зур базар җыелган. Ул елларда авылда кирпеч сугу эше киң җәелеп киткән. Авыл осталары бер яисә ике катлы таш пулатлар, кибетләр салганнар. Авыл үсә, зурая барган. 1908 елда Үсәли 213 хуҗалыклы, ике мәчетле, волость идарәле, унөч кибетле, тимерче алачыклы, тегермәнле авыл була. Калач, клиндер пешерә торган дистәдән артык ипиханә эшләп тора, аларга бодай онын йөге-йөге белән Чистайдан кайтарганнар. Авылда сәүдәгәрләр күбәя. Үзәк урамда Равил, Гариф, Хуҗа байларның таш йортлары, кибетләре тезелеп киткән. Алар сату-алу белән Казанга, Чистайга, хәтта Самара шәһәренә кадәр йөргәннәр.

Базар һәр атнаның сишәмбе көнендә авыл уртасындагы мәйданга җыелган. Көзге базарлар үзләренең байлыгы һәм муллыгы белән аерылып торганнар. Беренче чана юлы төшү белән тирә-як авыллардан халык базарга җыелган. Тәкәнеш, Саба, Теләче якларыннан, күрше өязләрдән килүчеләр дә күп булган. Кайберләре кичтән килеп таныш-белешләрендә тукталган. Кешеләр, атлы олаулар мәйданга сыеша алмыйча, Үзәк һәм Зират урамнарына таралган. Тирә-як сатып алучылар тавышыннан гөж килеп торган. Үзәк урам буйлап тезелеп киткән кибетләрдә халык күп булган. Базарга килүче агай кызыл товар сайлаган, калач, бавы белән клиндер, чәй-шикәр, хәлвә алган. Сату-алу базар мәйданындагы сәүдә рәтләрендә аеруча кызу барган. Биредә терлек, ит, он, ашлык, бал, балавыз, тула, суккан сөлгеләр, паласлар, агачтан һәм тимердән һөнәрчелек эшләнмәләре сатканнар. Читтәрәк ат белән сату иткәннәр. Авыл агае атның төсе, кыяфәте ошаганын сатып алган, ат белән авыл читеннән бер урап килгән. Атның йөреше, үзүзен тотышы, холкы-фигыле ошаса, бәясен сөйләшергә тотынган.

Сатып алуда, билгеле инде, маклерлар да катнашкан. Халык базарга сату-алу өчен генә килмәгән. Авыл агае биредә таныш-белешләрен очратып бер гәпләшеп алган, терлек, ашлык бәяләрен белеп, дөнья хәлләреннән хәбәрдар булып, авыллардагы, өяздәге яңалыкларны ишетеп кайткан. Кыз күрү, малай өйләндерү кебек эшләр дә кайвакытларда базардан башланган. Көн үтеп, кичкә авышкач кына халык базардан тарала башлый. Алыш-биреш итеп арыган рус агае «знаком»га, татар, керәшен агайлары «белеш»кә кереп тамак ялгый, чәй эчеп ала. Эңгер-меңгер төшә башлагач, базар мәйданы, урамнар бөтенләй бушап калган.

Сугыштан соңгы елларда да Үсәлидә зур базар җыелган. Халык һәр базарны зур бәйрәм итеп көтеп алган. Якшәмбе җиттеме (ул елларда базар якшәмбе көнне үткәрелгән), атлылар, җәяүлеләр базарга агылган, һәрберсе киенгән, ясанган. Урамнарда, базар мәйданында хәйран тамаша, кайсы ала, кайсы сата... Тамагыннан өзеп, салым түләргә акча эзләп килгән халык базарга.

Өчиле (Үсәли) – урманлы як. Шуңа күрә җәй-көз айларында базарда урман хәзинәсе – каен җиләге, җир җиләге, кура җиләге, шомырт, балан, чикләвек өзелеп тормаган. Умар, Тау иле руслары әрҗә-әрҗә алмалар, Басканнан Сәхипзадә бабай кыяр, шалкан, шалкан печинкәсе (пешкән шалкан) алып килеп сатканнар. Кече Бөрсет, Колышчыдан Бәчкә, Чтапан дәдәйләр сатарга тәпән-тәпән бал алып килгәннәр.

Базарның иң җанлы урыны – һөнәрчелек әйберләре сата торган рәт. Агачтан эшләнгән нинди генә әйберләр сатылмаган монда! Басканнан Гыймаз абзый ясаган бизәкле сандыклар, Катмыштан Муллахмәт абзыйның эреле-ваклы чаналары, Вәли абзыйның бизәкле көянтәләре, Югары Бөрсеттән Хәби абзыйның чаңгылары, Нурмөхәммәт абыйның арба тәгәрмәчләре, Үсәлидән Сибгатулла һәм Миңнегали бабайларның көрәк, тырма, уклау, чалгы һәм балта саплары, Бөрсет-Сукачыдан Ибраһим абыйның тәпән, ипи күәсләре... Эшләнмәләрнең барысы да данлыклы Бөрсет урманнары агачыннан ясалган. Чабата, чыпта, аркан белән сату итүчеләр Югары Сон, Урта Сон, Түбән Сон, Югары Бөрсет авылларыннан күп булган. Түбән Сонның Әхмәтҗан бабай һәр базарга егермешәр пар чабата алып килеп саткан. Кызлар, яшь киленнәр өчен Әхмәтҗан бабай чабатаны матур итеп, мөгезләр чыгарып үргән. Балык Бистәсе районы, Тәберде Чаллысы авылы остасы Мөнир абый (композитор Фәтхерахман Әхмәдиевнең абыйсы) җиз комганнар алып

килеп саткан. Олы Кибәчедән Һади абзый вак-төяк товарлар белән сату иткән. Хатын-кызлар өчен йөзек-балдаклар, беләзекләр, муенсалар, энәләр, булавкалар... Бик озак еллар халыкны туендырып, киендереп, бер-берсе белән очраштырып һәм дуслаштырып торган атаклы Үсәли базарын алтмышынчы еллар ахырында ни сәбәптәндер бетереп куялар.

Элек авылда мәчет икәү булган. 1930 елларда аларның манарасы киселгән, үзләре ябылган.

Хәзер авылда мәчет эшли. Теләгән кеше дин тота, гыйбадәт кыла. Мәчеткә, олылар гына түгел, яшьләр дә йөри.

Өчиле авылында халык «Латыйф мулла йорты» дип йөргән йорт бар. Мөхәммәтлатыйф Камалетдинов (1870 елның 20 декабрендә туган) чыгышы буенча Мамадыш кешесе. 1906 елның 22 февралендә икенче мәчетнең имамы булып билгеләнә. 1903 елның мартыннан ул элекке Мамадыш өязенең (хәзер Теләче районы) Җәнәй (Сосновый Мыс) авылында имам-хатыйб булып эшләгән.

Өчиле авылында икенче мәчет 1891 елда төзелә. Аның планын 1890 елның 13 сентябрендә Казан губерна идарәсе раслый. Мөхәммәтлатыйф Камалетдиновка кадәр мәчетнең имам-хатыйбы булып Мөхәммәткашаф Әхмәтвәлиев эшләгән. Ул Мөслим районының Олы Чәкмәк авылына күчкәннән соң, 1901 елның 22 декабрендә Өчилегә имам итеп Мамадыш районының Түбән Яке авылыннан Фазлыәхмәт Мөхәммәткәрим улы Нуришев билгеләнә. XX йөз башында мәхәллә мәктәбендә 106 ир бала укый.

«Авылда беренче мәхәллә 1815 елда төзелә. 1878 елда салынган иске агач мәчет 1905 елның 13 маенда яна. Дүрт елдан соң гына, 1909 елның 24 августында, Казан губерна идарәсе яңа кирпеч мәчет төзергә рөхсәт бирә», – дип язалар Р. Салихов белән Р. Хәйретдинов.

Авыл халкы Зелпәрия (Делпәрия) исемле хатын-кызны еш искә ала. Аның исеме белән Зелпәр ~ Делпәр чишмәсе дә бар. Авылда һәм аның тирә-юнендә чишмәләр аз түгел, ләкин күбесе исемсез. Әлбәттә, халык куйган аһәңле, матур исемгә ия булганнары да бар: Шаулы чишмә, Салкын чишмә, Керәшен очы чишмәсе, Зират чишмәсе, Шарлама чишмәсе, Изгеләр чишмәсе һ.б.

Авыл янында агым сулар да байтак. Күлләр исә авыл табигатен тагы да ямьләп тора. Исемлеләреннән түбәндәге су-инешләрне әйтеп китәргә мөмкин: Әрчеш елгасы, Умарта елгасы, Туры чыккан

елга, Мазар ~ Мадар елгасы, Бөрсет/Бүрсет елгасы, Билле елгасы, Аргы Билле елгасы һ.б.

Авыл тирәсендә Кызыл Яр, Биек Тау исемле калкулык-таулар бар. Бөрсет/Бүрсет елгасы ярлары Бәләкәй куак, Олы куак дигән исем алган. Куаклыклар өстендә Сугышкан җир исемле урын да бар. Элек анда Түбән Сон белән Өчиле авылы халкы җир өчен даулашканнар, хәтта үзара сугышканнар да икән.

Максатчан эшләгән, районны гөл итеп тота алган халык матур итеп ял да итә белә. Мамадыш районында инде дистә елдан артык Питрау бәйрәме үткәрелә. Халык бу бәйрәм вакытында ихлас күңелдән бәйрәм итә һәм ял рәхәтен тоеп, дуслары, тугантумачалары белән очрашып күңелләрен булдыра. Бу бәйрәм районда, Татарстанда гына түгел, бөтен Россия күләмендә дә билгеле зур бәйрәмгә әверелде. Хәтта ул инде ерак һәм якын чит илләрдә дә билгеле.

Мамадыш халкы җыр-музыка, спорт һ. б. төр ярышларда катнашырга ярата. Бәйрәмдә сулы чиләкләрне көянтә белән күтәреп йөгерүләр, гер күтәрү, көрәш, җыр-биюләр дә оештырыла. Питрауда һәркем үз һөнәрен күрсәтә.

Мамадышта яшеллек күп, табигать матур. Табигать зур тәрбияче ул. Шуңа күрә дә анда халык бәхетле, үз нигезләрендә шатланып, бер-берсенең шатлыгына куанып, кеше башына төшкән проблемага кайгырып, яшиләр һәм тырышып эшлиләр. Кунакларны да үз нигезләрендә матур кабул итәләр.

Билгеле инде мамадышлыларның болай матур яшәүләрен хакимият ярдәменнән башка күз алдына да китереп булмый. Бердәм тырышлык кына шундый уңышларга алып килә. Гел шулай йолдыз кебек җемелдәп һәм балкып яшә, Мамадыш!

Язмамны Ринат Мөслимовның «Кайтам әле Ылыяга» дигән шигырь (аңа З. Хәйретдинов көй язган) юлларыннан бер куплет белән тәмамлыйм:

Тәмле ризык, кайнар чәйләр,
Әткәй төзегән йортта.
Читтә бәхет эзләп йөрмик,
Гомер үткәреп юкка.

# ТУГАН ЯГЫМ, ТУГАН СӨЙЛӘШЕМ

*Дария Рамазанова*

Мин Саба якларында туып үстем. Безнең якларда урманнар да, чәчәкле ямьле болыннар да, гомер буе бертуктаусыз җырлап-челтерәп торган чишмәләр дә – кыскасы табигатебезнең барлык матурлыклары да бар. Чикләвекле урманнарыбыз үзенә бер җан рәхәте.

Минем туган төбәгем мамадыш сөйләше таралган җирләргә карый. Безнең сөйләш шактый зур территорияне алып тора. Ул хәзерге Саба, өлешчә Кукмара, Мамадыш, Алабуга, Зәй районнарын эченә ала, шуннан Әлмәт районына да тарала, Оренбург якларына барып җитә.

Архив документларыннан күренгәнчә, Оренбург далаларына Казан ягы татарларының күчеше нәкъ шушы юллардан, нәкъ шушы юнәлештә барган да инде. Күренекле галим Л. Җәләй Татарстандагы сөйләшләрнең таралышын ачыклау өчен, анкеталар таратып, шуларга алынган җавапларны картага төшерә. Аның докторлык диссертациясенә теркәп калдырган карталарында мамадыш сөйләшенең таралыш чикләре шул рәвешле тасвирланган да.

Минем үземә дә көнбатыш һәм көньяк Урал якларына Идел буеннан татарларның күчү тарихын өйрәнү өчен Мәскәүдәге борынгы актлар тупланган архивта күп кенә документларны актарырга туры килде. Чыннан да, Россия дәүләтенең яулап алуларыннан соң, авыр салымнар, җир эзлегән, көчләп чукындыру сәясәтен күтәрә алмыйча, үзәк губерналардан татарларның XVI йөзләрдә әлеге көнчыгыш якларга массакүләм күчеше башланган һәм ул XIX гасырга хәтле дәвам иткән. Шушы тарихи вакыйгаларны чагылдырган язма документлардан аңлашылганча, иң беренчеләрдән булып, XVI гасырның икенче яртысында һәм XVII гасырның беренче яртысында

Мамадыш төбәгеннән күчеп китүләр башланган. Алар документларда «ясаклы чювашлар» дип аталганнар. Ык елгасының көнчыгыш бассейнындагы татар авылларының бер өлешенә менә шушы күчеп китүчеләр нигез салган. Бу турыда минем «Татары Восточного Закамья: их распространение, формирование говоров» (Казан: «Мәгариф» нәшрияты, 2000) дигән хезмәтемнең 3–100 битләреннән тулырак мәгълүматлар табарга мөмкин.

Мамадыш өязе Казан губернасының башка өязләре арасында борынгырак чорда формалашкан үзәк территорияне тәшкил иткән. Хәзерге чорда Тау ягында Мари Элдә, Удмуртиядә, Пермь якларында таралган татар сөйләшләре вәкилләре үзләренең чыгышларын хәзерге Мамадыш һәм Арча районнары белән бәйлиләр. Тау ягы Норлат төбәгендәге татар авылларының бер өлеше Мамадыш төбәге татар авылларының исемен йөртә. Мари Эл, Бәрәңге районы татарларының (алар турында «Милли-мәдәни мирасыбыз: Бәрәңге» (2012) дигән китаптан укырга мөмкин) сөйләшендә дә безнең яклардагы *-дагын*/*-дәген* формасы белән очрашабыз. Тик анда әлеге күренеш берникадәр үзенчәлекле күчеш кичергән һәм *-дагысыннан*/*-дәгесеннән* рәвешле яңгырый.

Пермь сөйләшенең дә сөлил (сылва) дип атала торган бер урынчылыгында *-дагын*/*-дәген* дип сөйлиләр: *Шоморыт өчөн бардым дағын, сусап қайттым.*

Тик шунысы әһәмиятле факт, әлеге күренеш, башка төрки телләрдә сирәк күзәтелә. Ул тагын алтай, шор телләрендә генә очрый.

## Фонетик үзенчәлекләр

Мамадыш сөйләшенең сузыклар өлкәсенә караган үзенчәлекләре күп түгел. Анда аерым сүзләрдә генә күзәтелә торган аваз күчешләре дә аз: *ире* – әд. эре, *инә* – энә, *бәк* – бик, *сике* – сәке, *пирәмәч* – пәрәмәч, *чикчәғи* – чәкчәк, *шылай* – шулай, *былған* – булган, *үмә* – өмә, *үнәр* – һөнәр, *бийау* – буяу һ.б.

Үзенчәлекле күренешләрнең берсе – *а* авазын көчле иренләштереп әйтү. Ул бигрәк тә беренче иҗектә күзәтелә: *ба°ла*/*бола* – бала, *Ромазан* – Рамазан, *қа°лақ*/*қолак* – калак.

Тартыклар өлкәсендә әлеге сөйләшкә хас йөртелә торган түбәндәге бер үзенчәлекне билгеләп үтми булмый. Ике сузык арасындагы *д* авазының шартлау элементы йомшарып *з* булып әйтелүе мамадыш сөйләшендә аеруча тотрыклы һәм системалы: *қазақ* – ка-

дак, *изән* – идән һ.б. Бу үзенчәлек антропонимнарда, ономастикада, алынмаларда да таралган. *Пәризә* – Фәридә, *Бәзерттин* – Бәдерт-дин, *Изел* – Идел, *мизал* – медаль һ.б.

Күрше минзәлә сөйләшенең төп билгеләреннән санала торган сакау *з* (*d*) авазы мамадыш сөйләшендә дә шактый еш очрый: *dаман* –заман, *Дәйнәп* – Зәйнәп, *барысыd* – барырсыз һ.б. Алай гына да түгел, соңгы еллардагы тикшеренүләр *d* авазының таралыш территориясе Тау ягындагы урта диалект сөйләшләреннән үк башлануын күрсәтте: *хәdрәт* – хәзрәт, *хәdер* – хәзер, *җиләd* – җиләз һ.б.

Мамадыш сөйләшендә *җ* авазын тулысынча *җ* дип әйтеп сөйлиләр: *җирем-суым, җырлау, Җәмниха, җитен, җиләк, җилем, җамансу (*ямансу) һ.б. Ягъни әлеге сөйләш *җ*-ләштерә торган сөйләшләребезнең берсе.

Шулай да *җ*-ләштерүнең, позицион һәм башка төрле фонетик закончалыклар белән бәйле рәвештә, төрлечә активлык күрсәтүенә басым ясап үтәргә кирәк.

1) Әдәби телдә *й* белән башлана торган сүзләр мамадыш сөйләшендә *й* белән дә, *җ* белән дә әйтелә: *йабыҡ* // *җабыҡ, йәшләр* // *җәшләр, йаwым* // *җаwым, йалҡау* // *җалҡау, йөгөр* // *җөгөр* һ.б.

2) Әдәби телдә *җ* белән башлана торган сүзләр сөйләштә дә әдәби әйтелешне саклый: *җил, җәй, җиләк, җимешләр, морҗа, Җамалый, Гөлҗамал* һ.б.

3) Кайчак сүз башындагы *җ* авазы урынына *з* әйтү күзәтелә: *зил* – җил, *зыйылыш* – җыелыш, *зиләк* – җиләк, *зеп* – җеп.

Әлеге күренеш, *җ*-лаштыру аша, әдәби *й* сонанты урынында да очрый: *засый* // *җасый* < ясый, *зыраҡ* // *җыраҡ* < ерак, *зөри* // *җөри* < йөри, *зазып* // *җазып* < язып һ.б.

4) Кайбер сүзләрдә *җ* авазы *й* сонанты белән алмашынырга мөмкин: *йор – җор, бойра – бож́ра, йурна* (< рус. зерно > жирно) һ.б.

*Җ >й, җ > з* күренешләре мамадыш сөйләше белән аралаш (казан арты керәшеннәре) яки янәшә (минзәлә, лаеш) таралган сөйләшләрдә дә күзәтелә.

Шактый зур күләмле материалда чагыла торган аваз тәңгәллекләреннән тагын әдәби телдәге *ч* авазы урынына *с* авазын әйтүне күрсәтергә кирәк: *ҡалас* – калач, *күмәс* – күмәч, *чапҡас* – чапкач, *ҡайтҡас* – кайткач, *күргәс* – күргәч һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, әлеге үзенчәлек сүз азагында теркәлгән алынмаларга: *сабагаш* –

чабагач һ.б. хас. Шулай ук пермь сөйләше белән уртаклык күзгә чалына (*қайтқас, күркәс* һ.б.).

Бу күренешнең киресенчә (ягъни *с* > *ч*) тәңгәллеге татар сөйләшләрендәге алынмаларда киң таралган: *чичтыра* – сестра, *чичла* – число, *чичнай* < честный – яхшы.

Кире якка охшашлану: *чийырчық* – сыерчык, *чөйөнче/чийенче* – сөенче (бу сүз борынгы болгар телендә үк булган һәм хөкүмәтләрилләр арасындагы аралашуларда сәяси атама буларак кулланылган. Гомумән, кыз ягы һәм егет ягы дигәндә, борынгы чорда кабиләләр арасында була торган сәяси мөнәсәбәтләр күзаллана): *бачқыч* – баскыч, *қычқыч* – кыскыч, *чөчқоч* – соскыч һ.б.

Кайбер сүзләрдә берничә фонетик күренеш чагылырга мөмкин: *чиләшү/шиләшү* – сөйләшү, *шийыршық/чийыршық* – сыерчык, *чәбершек/шәбершек* – аш шулпасы өстендә күбек, элпә һ.б.

Охшашсызлану күренеше алынма сүзләрнең үзләштерелүе үзенчәлекләрен чагылдыра: *пирмән* – пилмән, *сиклатар* – секретарь, *пыркарул* – прокурор һ.б.

*Тушы* (әд. шушы), *тишмә* (чишмә) сүзләрендә дә охшашсызландыру күренеше күзәтелә.

Казан арты сөйләшләре төркемендә, шул исәптән мамадыш сөйләшендә дә, охшашлануның тагын мондый очраклары бар: *ыршы* – чыршы, *шабағаш* – чабагач, *шуғыш* – сугыш, *шиләшү* – сөйләшү сүзләрендә билгеләнгән.

Мамадыш сөйләшендә бер яисә бер-ике сүздә генә күзәтелә торган, әмма төрки телләр үсеше тарихын өйрәнү өчен әһәмиятле булган тәңгәллекләр шактый табыла: *уләм* – үлән, *барнак* – бармак; *исне* – исле, *төснәү* – төсләү, *күлүк* – күрек, *босо* – монысы, *биләш – миләш, апый – абый, чиртмә* – сиртмә, *чийурт/чуйурт* – шуйыт (әнис), *кискәр(е)* – тискәре, *кәләпүч* – кәләпүш һ.б.

Мамадыш сөйләше әһәмиятле борынгы күренешләрне әле дә саклап килә.

Билгеле булганча, төрки телләргә, шул исәптән татар теленә дә *ф, х* авазлары ят аваз булганнар, татар теленә алар күбесенчә чит (гарәп-фарсы, рус) телләр аша кергән. Халык телендә әлеге авазлар ясалыш урыны ягыннан аларга якын булган үз авазлары белән алыштырыла. Бу җәһәттән караганда, *ф* > *п* күчешенең асылында ике үзенчәлек чагыла.

1. Билгеле бер төркем сүзләрдә борынгы *п/б* авазы сакланып килә: *җапрақ* – яфрак, *тупрак* – туфрак, *керпек* – керфек, *җепәк* – ефәк һ.б. Чагыштыр: борынгы төрки телдә *йалбыргак, тобрак, кербек, җеп* һ.б.

2. Икенче очракта алынма сүзләр белән кергән ят авазларны үзләштерү алымын күрәбез.: *ф > п*: *нәпес* – нәфес, *Кашап* – Кашаф, *Нәписә* – Нәфисә, *панар* – фонарь, *билтә < пилтә* – филтә, *шарып* – шарф.

х > қ күренеше белән дә шундый хәл 1) *қәрдәш – хәрендәш* яки *карандаш*, *йақшы – яхшы* һ.б.

2) *х> қ* алынмаларда да күзәтелә: *Қәнипә* – Хәнифә, *Қәдичә* – Хәдичә (бу күренеш, нигездә, кеше исемнәре белән чикләнә).

Авазлар төшү күренешенең үзенчәлекле мисаллары мамадыш сөйләшенең яңгырашына аерымлык өстиләр, телнең үсеш-үзгәреш тарихына материаллар бирәләр.

Татар теле өчен чит булган *һ* авазы еш кына төшә: *үнәр* – һөнәр, *Майнур* – Маһинур.

Ике сузык арасында *һ* авазы төшә һәм янәшә ике сузык, бертөсле булсалар, кушылып, озын яисә гадәти сузык барлыкка килә: *Waап* – Ваһап, *шәәр* – шәһәр, *зәәр* – зәһәр, *җәәннәм, җәннәм* – җәһәннәм һ.б.

Янәшә барлыкка килгән ике сузыкның күтәрелешләре төрле булса, ике арада *й* сонанты барлыкка килә: *зийен* – зиһен, *Гөлҗийан* – Гөлҗиһан, *Шәйәкбәр* – Шаһиәкбәр, *Җийанша* – Җиһанша һ.б.

Татар теленең күпчелек сөйләшләренә хас булганча, мамадыш сөйләшендә дә *қ/к, ғ/г* тартыклары ике сузык арасындагы позициядә редукцияләнәләр: *теэ* – теге, *апчыып* – апчыгып, *җерләү* – җегерләү һ.б.

Төрле позициядә аерым авазлар төшә: *алҗақыч* – алъяпкыч, *белә* – белән, *сеңем* – сең(е)лем, *әтмә* – җәтмә, *шау* – тышау һ.б. Сүзтезмәдән барлыкка килгән кушма сүзләрдә аерым иҗек яки башка өлешләр дә төшәргә мөмкин: *җалында* – өй алдында, *айса* – алайса, *андары* – аннан ары, *апкил* – алып кил, *аппара* – алып бара һ.б.

Авазлар өстәлү төрле закончалыклы күренешләргә кайтып кала. Мәсәлән, сүз азагында *қ/к* өстәлүчән: *тулық* – тулы, *тиклек* –

тикле һ.б.; *т, ж* авазлары алдында *р* соноры өстәлә: *қортлау* – котлау, *шаржин* – сажень, ике сүз арасында *ң* авазыннан соң *г* барлыкка килә: *иңгелек* – иң элек.

Кайбер алынма сүзләрне үзләштерү. мамадыш сөйләшендә шулай чагыла: *тәникә* – тарелка, *лачинка* – носилка, *йәнеwәлит* – инвалид, *гыржыwа* – кружево, *кендерик* – крендель, *кәнсә(ләр)* – канцелярия һ.б.

## Грамматик үзенчәлекләр

Мамадыш сөйләше әдәби телгә бик якын сөйләшләрнең берсе. Шулай да бу сөйләшкә генә хас үзенчәлекләр дә бар.

I һәм II зат тартымлы исемнәрнең төшем килеше -*ы*/-*е* кушымчасы белән ясала: *қулымы* – әд. кулымны, *қулыңы* – кулыңны; *сүземе* – сүземне, *сүзеңе* – сүзеңне, *эшләреме* – эшләремне, *эшләреңе* – эшләреңне.

Мамадыш сөйләшенең үзенчәлекле күренешләреннән берсе – -*лый*/-*лий* кушымчасы белән вакыт рәвешләре ясалу: *җәйлий* – җәй буйы, *қышлый* – кыш буе, *йазлый* – яз буе һ.б. Күргәнебезчә, мондый рәвешләр ел вакытын белдерә торган сүзләрдән ясала. Икенчедән, басым тамыр иҗеккә төшә: *кө́злий, қы́шлый, җә́йлий* һ.б.

Бу үзенчәлек күрше минзәлә һәм тагын пермь сөйләшләрендә билгеле. Шулай итеп, чагыштырмача сирәк очрый торган әлеге үзенчәлек мамадыш һәм пермь сөйләшләрен берләштерә.

Татар теленең урта диалект сөйләшләренә хас дәвамлы үткән заман формасы мамадыш сөйләшендә активрак кулланыла: *Үзе сөйләр ийе, үзе йылар ийе шул сеңнесен сағынып. Әйтер ийе дә көләр ийе, әйтер ийе дә көләр ийе безнең әнкәй, бигрәк күңелле кеше ийе. И, җийынға төшәрләр ийе тырантаслар белән парлап-парлап утырышып, болонноққа. Печмән өч атна булыр ыйы, үләннәрнең җәшәреп, һәйбәт булып үсеп киткән чағында булыр ыйы, җәшләр күңел ачып җөрөрләр ийе.*

Тамырлары *р* авазына беткән фигыльләргә -*ыр*/-*ер* кушымчасы ялганып килгәндә, ике *р* авазының берсе кыскара. Бу күренеш, мамадыш сөйләшеннән тыш, Урал төбәге сөйләшләрендә дә күзәтелә. Мисаллар: *күрегә* – күрергә, *йөрөгә* – йөрергә, *барыға* – барырга; *барым* – барырмын, *көрәрем* – көрәрмен, *бетерем* – *бетеререм* – бетерермен, *бирем* – *биререм* – бирермен, *утырым* – утырырмын һ.б.

Мамадыш сөйләшендә инфинитивның борынгы *-мага/-мәгә* формасы, казан арты сөйләшләрендәге кебек, аерым фигыльләрдә генә сакланып калган: *утырмаға бару* – йола исеме: кыр эшләре тәмамлангач, кул эше алып, бер-ике атнага күрше авылдагы туганнарга кунакка бару, *алмага* (алырга) *килү*, *асрамага бала алу* – тәрбиягә бала алу.

Билгеле булганча, *-мага/-мәгә* формасы Татарстаннан читтәрәк яши торган татарлар сөйләшендә (касыйм, бастан, бәрәңге, нократ, пермь, красноуфим һ.б.) хәзер дә актив:

Казан арты сөйләшләре төркемендә, шул исәптән мамадыш сөйләшендә дә, инфинитив, *-ырга/-ергә* кушымчасыннан тыш, *-асы/-әсе* формасы белән дә ясала. Мәсәлән: *Димче килер ийе, элек күреп сөйләшәсе түгел* (сөйләшергә ярамый) *ийе, бирәләр дә, барсаң да барасың, бармасаң да барасың. Ололар җанында бала-чаға таwышланасы түгел. Мәһәр җазыладыр ыйы, қыз белән җегет айырылса, җегет җағы түләсе.*

Инфинитив функциясендә башка формалар да кулланылырга мөмкин: *Әле син тора* (торырга) *килдеңмени. Анаң қуна* (кунарга) *киттеме, әллә бүген кайтамы? Җегетләрнең қайсы-берсе сыный* (сынарга) *килә аулағыйға.*

Билгеле төзелмә (сорау алмашлыгы + *кирәк* модаль сүзе) составында *-мақ/-мәк* формасы да күзәтелә: *Ни эшләмәк* (эшләргә) *кирәк, печән әзерләсе булғач.*

Сыйфат фигыльләрнең, әдәби телгә хас *-учы/-үче* (*килүче кеше бармы?*), *-а торған/-ә торған* (*укый торган қызым кийәүгә чыға*), *-ған/-гән* (*қайнаған су*), *-ар/-әр/-ыр/-ер* (*барыр җулың җырақ түгел икән*) формаларыннан тыш, мамадыш сөйләшендә *-ышлы/-ешле* формасы да еш күзәтелә: *Элек кич чығып җөрөшле булмаган. Өч литыр сыйышлы шешәләр булыр ийе кәрәчин җөртөргә. Айаққа кийешле* (кия торган) *итек бирделәр.*

Күрше минзәлә сөйләшенә хас *-малы/-мәле* диалекталь формасы да мамадыш сөйләшендә очрый: *Ике йақтан да ләктермәле* (эләктерә торган). *Бигрәк тар инде муйыны, кимәле дә түгел, салмалы да түгел* (киярлек түгел, салырлык түгел) һ.б.

Мамадыш сөйләшендә *-гач/-гәч* кушымчалы хәл фигыльнең *-гачыннан, -гачтыннан, -гачын* тибындагы синонимик формалары актив кулланыла. Мәсәлән: *Барам дигәченнән* (дигәч) *көттермә инде. Күргәчтеннән дә таныдым. Әти-әни үлгәчтеннән* (үлгәч)

*әнинең энесе мине бирде бер җегеткә. Қызы эшкә кергәчен* (кергәч), *әнкәсе пушты* (хат ташучы) *булып җөридер ийе. Чәчү беткәченнән* (беткәч) *җийыннар булыр ыйы.*

Китерелгән вариантлар тагын лаеш, минзәлә, бәрәңге, балтач һ.б. сөйләшләрдә дә очрый.

Мамадыш сөйләшендә *-мастан/-мәстән* кушымчалы хәл фигыльләр әдәби телдәге *-ганчы/-гәнче* формасы белән бер үк функциядә кулланыла: *Қызыл Байракка* (авыл ис.) *җитмәстән* (җиткәнче) *Ташофка* (авыл ис.), *шунда алпут җиләге* (гөлҗимеш) *җыйганым бар. Шул тықырықны үтмәстән* (үткәнче) *кирпеч өй тора.*

*-ып/-еп* кушымчалы хәл фигыльнең юклыгы, нигездә әдәби телдәгечә, *-мый/-ми, -мыйча/-мичә* кушымчалары белән ясала. Шул ук вакытта, *-мыйынчы/-мийенче* диалекталь вариантлары да күзәтелә: *Аны җырламыйынчы да апкайтып була. Ашамыйынчы-эчмийенче җәшәп булмый.*

Лаеш сөйләше белән чиктәш авылларда исә, әдәби телдән аермалы буларак, *-а/-ә/-ый* кушымчалы хәл фигыльләр хәрәкәт белдерә торган фигыльләрдән аңлатылган эшнең максатын ачыклый һәм әдәби телдәге инфинитив функциясен үти: *Бабай печән чаба китте җыраққа. Шунда барыр ыйым утын сата, печән сата* (утын сатарга, печән сатарга) һ.б.

Мамадыш сөйләшенең характерлы үзенчәлекләреннән берсе *дағын/дәген, тагын/тәген* теркәгечен яки кисәкчәсен куллану. Мәсәлән: *Соңға қалып киттек тәген* (киттек тә), *кич қойаш байғач кына қайттық Мин дәген* (мин дә) *күрми қалдым аны, бәк күрсәм килгән ийе. Барасы йы дағын* (барасы иде дә), *машина ԝатық бит әле. Ат белә килә дәген* (килә дә) *төйәп китә. Қычқырып җырлый дағын* (җырлый да), *баласы уйанып китә.*

Югарыда әйтеп үтелгәнчә, бу үзенчәлек татар телендә генә түгел, гомумтөрки масштабта да бик сирәк очрый.

Лаеш сөйләше белән чиктәш авылларда гаҗәпләнү катыш аптырап сорауны белдерә торган *чы* ымлыгы күзәтелә: *чы, нишлисең?!*

Бу күренеш лаеш сөйләшендә активрак кулланыла, минзәлә сөйләшенең әгерҗе урынчылыгына карый торган кайбер авылларда да чагыла. Шулай да әлеге аерымлык сөйләшләрдә бик сирәк очрый.

Мамадыш сөйләшендә кайбер синтаксик үзенчәлек дә күзәтелә.

Компонентлары үзара нисбәтлек мәгънәсе белән бәйләнгән исем-исем сүзтезмәләрнең тартым кушымчасы булмаган төре дә очрый: *Икенче көнне мунча қоймаққа баралар* (мунча коймагына; зөфаф кичәсеннән соң яшьләрнең мунчадан кайтуына әзерләнгән мәҗлес). *Сабан туйға* (сабан туена) *китәр ийек, җаңа чабаталар кийеп, атларға ике җақлап теделешеп утырып. Қаз чәйләр* (үлән исеме: каз чәе) *җийа торған ыйық арыш арасында.*

Исем-фигыль сүзтезмәләрдә кайбер фигыльләрнең башка килешне башкару очраклары күзәтелә. Мәсәлән: *Әби айақлары белән суқрана быйыл* (аякларына сукрана). *Мин бераwықтан ашарым, миңа көтөп* (мине көтөп) *утырмағыз.*

**Лексик үзенчәлекләр**

Мамадыш сөйләшенең лексик-семантик системасы әдәби телнекеннән аз аерыла. Шулай да аерымлыклар да табыла.

Кан-кардәшлекне белдерә торган атамалар өлкәсендәге үзенчәлекләр аеруча игътибарга лаек: *нәнә* – ана, *нәнәм* – әни кешегә эндәшү формасы. *Абый* атамасы саңгырау вариантта күзәтелә: *апый,* аңа эндәшү сүзе *-ч* иркәләү кушымчасы белән ясала: *апыч*. Шундый ук форма нократ сөйләшендә дә бар. Мамадыш сөйләшендә *апа* / *апый* бабайлар буынына керә торган ир туганнарны да белдерә: *апа* – бабайның бертуган энесе яки абыйсы; *дәү апый* – әни яки әтинең бертуган абыйсы яки энесе.

*Апый* атамасы нигезендә синтаксик ысул белән *бәләкәпый < бәләкәй апай* – бертуган абыйларның иң кечесе, *олапый < олы апый* – абыйларның иң олысы һ.б. ясала. Бертуган апаларны аера торган атамалар да шундый ук калыпларда ясала: *кечкенәттә < кечкенә тәтә* – бертуган апаларның иң кечесе, *зур тәтә* – иң олысы һ.б.

Туганлык атамалары өлкәсендә тагын бер үзенчәлек игътибарга лаек: *кәкәм* – эне тиешле ир туганга иркәләп эндәшү сүзе. Башка төрки телләрдә *кәкә* – абый мәгънәсендә, әстерхан татарлары сөйләшендә *какам* (абыем) шушы ук тамырдан булса кирәк. Билгеле булганча, үзеңнән кече яшьтәге туганнарга иркәләп эндәшү өчен олы туганнарны белдерә торган атамалар да кулланыла. Бу турыда минем «Термины родства и свойства в татарском языке» (Казан, 1991) дигән хезмәтемнән укырга мөмкин.

Халык арасында сакланып килә торган гореф-гадәт һәм йола исемнәре дә сөйләш вәкилләренең мәдәни мирасын өйрәнү өчен әһәмиятле. Мәсәлән, мамадыш сөйләшендә шундыйлардан *қолақ чөйөнчесе* тәгъбирен күрсәтергә кирәк, ул кызны килешкәч, ризалык билгесе итеп егет ягына бирелә торган бүләкне (сөлге, кульъяулык һәм намазлык яки бияләй) белдерә. Гомумән, кыз бирү – килен алу барышы белән бәйле атамаларның күбесе бик борынгы чорларга карый. Мәсәлән, болгар чорында ук *суйунче, саум* сүзләре сәяси багланышлар белән бәйле рәвештә кулланылган.

*Саwым* – төп кодалар тарафыннан билгеле күләмдә әзерләнеп, туйга күчтәнәч итеп алып килгән ризыклар (Татар теленең зур диалектологик сүзлеге. – Казан, 2009. – 553–554 битләр). Болгар чорында ук билгеле бер үлчәмдә коелган көмешне белдергән, хәзерге татар, үзбәк һәм башка кайбер төрки телләрдә кулланылган *сум* сүзе дә шуннан ясалып, акча санау берәмлеген аңлата, тубыл-иртеш диалектында исә *сум* – калып (чагыштыр: болгарлардагы *саум* сүзе дә коелманы (слиток) белдергән).

*Дәрә*. Бу сүз белән татар халкының күпчелек төркемнәрендә җәй башында башкарыла торган йола исемнәренә бәйле тәгъбирләр ясала: *дәрә иту, дәрә боткасы*. Бу йола буенча яз башында, кар бетәр-бетмәстә, халыктан ярма, сөт, май, йомырка, мөмкин булса ит җыеп, аларны әрәмәлектә, су буенда пешереп ашау (уйнау, күңел ачу да булырга мөмкин) оештырылган, *дәрә йоласы* иртәгә сабан туе дигән көнне уздырыла торган булган. «*Дәр-дәр дәрәгә, Иртән торып боткага, Берсекөнгә сабанга*» дигән такмак халык телендә хәзер дә саклана. Авыл янындагы калкулык яки тауларның берәрсе хәзергә кадәр *зәрә тавы, дәрә тавы* дип атала. Сабан туе алдыннан әйбер җыю йоласы мамадыш сөйләшендә *чирмә* дип әйтелә, әйбер җыючыларның үзләрен *чирмәчеләр* диләр. Бу сүзләр шундый ук мәгънәдә күрше минзәлә сөйләшендә дә күзәтелә. Ул түбән кама һәм тау ягы керәшеннәре сөйләшләрендәге *чермә/чертмә/черемә күкәе* (ашлык чәчәр алдыннан, игеннәр уңсын өчен дип, җиргә чәчеп җибәрә торган пешкән йомыркалар) дигән сүзләр дә шушы ук йола белән бәйле булса кирәк.

*Чүмәчлеки/чөмәлчек* – яңгыр теләү йоласы, *исәкәй* – каз өмәләре вакытында егетләр һәм кызларның кием алыштыру йоласы һ.б.лар мамадыш сөйләшенә хас үзенчәлекле йолалардан санала.

Шулай итеп, мамадыш сөйләше тел күренешләре белән генә түгел, йолаларның эчтәлеге, исемнәре белән дә үзенчәлекле.

Мамадыш сөйләшенә хас диалекталь сүзләрнең бер өлеше – кеше белән бәйле лексикага карый: *титақлап* – аксаклап, *биречләнү* – бирчәю, *иңке-тиңке* – ава-түнә, *тәләкә* – тәбәнәк (буйлы), *әйтүле* – атаклы, *чучақ* – сабырсыз, тынгысыз һ.б.

Йорт-җир, хуҗалык эшләре һ.б. белән бәйле сүзләрнең кайберләрен карап үтик: *сућыр пич* – мичнең астында ясалган куыш урын, *қычыйақ* / *кечейақ* – өйнең кухня өлеше; *дәстүк* – тимер көрәк, *саршин* – тома балавыз, *алтын-балтын* – таган, атынчык, *тәңкәчийыршык салу* – йөзек салу, *бәбкәйак* – көлтә чүмәләсенең бер төре, *ташыйак* – касә, *йөзлек* – битлек, *чәки* – чирек литрлы шешә, *җеборған* – юрган һ.б.

Аш-су белән бәйле сүзләр: *чупай* – имезлек, *чырымталы* – җепселле (ит турында), *чебрик* – пәрәмәч, *чабырма*/*чабыршы* – итле ашның өстенә чыга торган күбек һ.б.

Терек һәм терек булмаган табигать атамалары: *марҗа алкасы* – бүре җиләге, *ташборчак* – пешмәгән җиләк, *тукмак баш* – бака баласы, *иңкеш* – түбән җир һ.б.

Мәгълүм булганча, мамадыш сөйләше, әдәби телгә бик якын торса да, аеруча үзенчәлекле булган күренешләрне үзендә саклап килә. Биредә мамадыш сөйләшенең аерылгысыз булган Саба төбәгеннән язып алынган берничә үрнәк тәкъдим ителә.

**Авыл тарихы.** Олойаз аwылы шул исемнән килгән, мисал өчөн бик күп йыллар элек Олойаз дигән аwыл урнына Илйас[1] исемне кеше килеп урнашқан. Ул қайандыр инде Бийектаw (*авыл исеме*) йағыннан килгән булса кирәк ул кеше. Ул килеп урнашқан урманның бер аланына. Ул алан бик матур алан булған, аны иске зират уйдығы дип йөртәләр. Безнең Олойаз аwылы шунда булған. Шул Олойаз аwылы шунда булып, шунда байтақ қына ғөмөр иткәннәр. Ну анда бик қуйы ағачлық, бик қуйы урманнар, бүреләр, айулар һәм жыланнар бик күп булғаннар. Андары кешеләр ул нидән, ул урыннан менә шушы әле торған урыңға күчәргә мәжбүр булғаннар. Иң зур сәбәбе шул: жыланнардан, жыртқычлардан туйғаннар, чөнки жыланнар дажы балаларның бишегенә дә кереп йатқаннар.

[1] Олыяз сүзен Ильяс сүзе белән бәйләп аңлату халык этимологиясе булып тора. Чынлыкта исә авыл исеменең өлеше алан мәгънәсендәге яз сүзенә кайтып кала.

Бишегендә дә булғаннар. Шулардан қачып инде бу тирәгә килеп урнашқаннар. Бөтөн җир қара урман булған. Шул элекеге Иске зират таw йанындағы аwылда wахытта, ташу аққан wахытларда андағы кешеләрнең йуwынған йомочқалары ташу белә ағып барып Тимершық дигән аwылға барып чыққан, су белән ағып. Тимершықлар ай-һай ла бу суның йуғары башында ахырысы тормош бар дип Тимшық кешеләре эзләп килеп, Олойазны тапқаннар шунда. Шуннан соң Тимшықлар килеп тә Олойазға берничә хуҗалық урнашқаннар. Шуннан инде алар анда килеп Әсфәндийар бабайлар, Мадийар бабайлар ғөмөр иткәннәр. Җылғаның бу йағында бийек таw һәм тирән җылға бар, ансын Зәбиға җылғасы дип йөртәләр. Бу Зәбиға йылғасы килеп чыға шуннан, анда Зәбиға исемне бер қызны үтерәләр һәм шунда күмәләр. Шуннан соң шуны Зәбиға йылғасы дип йөртәләр. Тора бара ул җир сөрелә, ул төшләр әрчелә, шуннан, әрчелгәннең соңонда, анда иң беренче, таw башында инде Ғаптулла таwы дип исем бирәләр. Ғаптулла абзый аны сөрөп, үзе шунда иген чәчкән була, Гаптулла таwының бу йағына икенче бер кеше җир ача, Ғаффар исемне. Аны Апар җылғасы дип йөртәләр. Шул йылғага исем бирелә Апар йылғага дип, һәм ул йылға буйлап аны Ғафар абзый буйдан-буйға чәчкән була. Шул Ғафар абзыйның тормошы шуннан бирегә күчеп қайта. Пүкәл (авыл исеме) белә ик(е) арадағы бийек таw өстөнә җир сөрәләр һәм җирне ачалар[1], шуннан соң анда әйбәт тәмне шишмәләр аға. Бу шишмәләрне атап қуйалар инде Мадийар шишмәсе дип. Бу Мадийар шишмәсеннән бик күп кешеләр файдалана. Мадийар шишмәсе данлықлы була. Аның суwына төрлө җирләрдән килеп, нәззәтле су эчәбез дип қайталар. Бу болонның йылғалары бик күп. Ул җылғаларның бу йағында, Апар җылғасының бу йағында, тағын бер җылға бар кечерәк кенә, ансын Ахун җылғасы дип йөртәләр. Ахун ағай шунда ике йақлап җир сөргән, иген чәчкән һәм шул җылға буйларында печәнне үзенә чаwып файдаланған. Аның бу йақларындағы болон дуғайларының һәм қырыйларның өстө йағын арғы җиләк йаз дип җөртәләр. Анда, Арғы җиләк йазда, бик күп кенә қура җиләге, бөрлөгән һәм шундый җиләкләр тәмне, нәззәтле үскән. Аннан бире(е) таба килгәченнән инде Бирге җиләк йаз диләр. Бу Бирге җиләк йазға тужы, қуйы чыр-

---

[1] Җир ачу – урманны яндырып, йә агачын кисеп, төбен чыгарып яңа җир ясау.

шылык, наратлар һәм анда бик күңелле, җир җиләге, қура җиләге булыр иде. Һәм анда урнашқан иде зур ғына бер умартачылық. Аны Ибраһим қортлоғы дип җөрөттеләр. Ул Ибраһим абзый җегерме биш йыл хезмәт иткән кеше булған бороңғы салдатта. Аның бу йағында килгәченнән Тирән җылға дип җөртәләр, зур җылға. Бу Тирән җылғаның исеме шуннан аталған, ул ғәҗәп тирән булған, электеннән аны арқылы чыға алмағаннар. Шуңа күрә аңа Тирән җылға дигән исемне биргәннәр. Аның бу йағына килгәченнән Сай җылға күп тә килмәс борон. Ул Сай җылға, үзе сай булса дағын, уйдық қына җылға, бик озонға сузылған, бик матур печәннек. Шуңа күрә анда күңелле иттереп печән чабалар иде. Аннан төбән төшкәченнән инде Чибәр болон дип җөртөр идек. Ул Чибәр болон бик матур сузылған, аwыл чыққачтыннан бер киламитырға қадәр бара. Ул чибәр болонда сайранныққа[1] чығар ийе йәшләр, қызлар һәм анда бик күңел(ле) иттереп рәттән пакуслап кереп, чаwып чөмәләләп өләшер идек печәнне. Ул Сай җылғада зиреклек булды, зиреклек арасында билдән һәм дажы қултық астыннан, шундый әйбәт қуйы печәнлекләр иде. Анда қарлығанлықлар һәм башқа җимешләр үсә иде. Хәзер таwның бу йағына килгәннең соңонда умарталықлар тезелеп киткән иде. Шул җылға буйлап барғанда ум-бер умартачылығ ийе. Алар бар да байларнықыйы. Без алар тирәсендә малай wахытта йөгөргәләп йөри ийек. Рәхимлеләре бал суwырткан wахытта безгә бал да биргәлиләр ийе ипигә йағып. Гаптулла таwының өстөнә менгәч, аның Кукмыр (авыл исеме) йағындағы қырыйда жуғары, алпаwыт җире ийе. Алпаwыт җирендә игенне алпаwытлар чәчәйде. Ул алпаwытлар без җәш wахытта бик күп җирне биләгәннәр иде. Ул алпаwытның үзенең аwыллары барыйы, Йабылаштаw, Мишәбаш, Шекше аwыллары алпаwытның қол аwыллары ийе. Алар (алпавытлар) қул астында қол булып йәшәделәр. Алпаwытның оло тегермәне бар ийе. Шушы Алан җылға дигән, Шекше дигән аwылның суwына урнашқан ийе. Бөтөн бу тирә аwыл халықлары шул тегермәнгә тартырға барырлар иде. Алпаwыт үзенең иминийесен бик күп җирләрдән биләгән ийе. Аның афчарқы этләре, аның атлы қазақлары йарты сәғәттән сәғәткә кырогом әйләнеп торорлар ийе басуны. Әгәр дәген килеп чыга йкән бер

[1] Сайранныққа – күңел ачарга.

керистийәннең бер сыйыры, аны тотоп җаба, сарық чыға икән, аны тотоп җаба. Шуларны җапқан өчөн алпаwытқа биш шаҗин җир урып бирәс(е) ийе сийырны түләп алу өчөн. Безнең җирләребез бик қысынқы булды. Җирләр ир малай булған, ир булған кешегә генә бирелде ул wахытта. Ә хәзер шул җирләрдә инде күркәм басуларыбыз, күркәм камбайыннарыбыз, тырактырларыбыз сөрә, игенне мул алабыз.

*Сөйләүче: Гайнетдинов*
*Гыйльман (1901 елгы).*
*Олыяз авылы*

Безнең Олойазға Тимершықтан да килгәннәр бер ничәдер хуҗалық, дип әйтәдер ийе безнең бабай. Тимершық дип тә әйтәбез, Тимшық дип тә йөрибез. Берсендә тимшықларға туйға барғач, өстәлнең бер җағына тимершықлар утырған. Тимершық Тимершәйех дигән сүздән ул. Икенче йақта олойазлар икән.

Хуҗалар и қыстый, и қыстый, олойазлар һаман ашамый утыра икән. Утыра торғач, арада қыйурағы: «Жарар, ашасыннар әле тимшықлар, бушасыннар әле қашыклар», – дип әйтеп салған.

Суның тийағында бер суқыр бабай бар ыйы. Ул: «Алай түгел, менә болай ул», – дип бора торған ыйы: «Әле тимшықлар туйсыннар, қашықларын қуйсыннар». Халық мәзәк булған инде.

*Сөйләүче: Гайнетдинов*
*Гыйльман (1901 елгы).*
*Олыяз авылы*

**Сабан туе.** Сабан туйы менә сабанға төшкәнче булды. Сабанға төшкәнче йасадығ ансын. Қар беткәченнән, (җир) кибеп бетмәс ийе инде. Пирwай ни җийарлар ийе. Балалар чығып, қычқырып зәрә[1] җийып кешедән, баларақ қешеләр өй борона. Қайсы йарма бирер ийе, қайсы күкәй бирер ийе, қайсы ақча бирер ийе. Җийылып ул ботқаны бер җирдә шул зәрә ботқасы дип пешерәләр ийе инде. Бөртөрлесе шунда утырыб ашар ийе, бертөрлөсе апқайтып китәр

[1] З ә р ә (< ?) – иртәгә сабан туе дигән көнне бала-чаганың ярма һәм башкаларны җыеп авыл янында, бигрәк тә тау башында, җыелып, ботка пешереп ашау йоласы. Зәрә 2 көнгә дә сузылырга мөмкин. Беренче көн ялганчы зәрә дип атала. Балалар: «Зәрәгә, зәрәгә!» дип кычкырышып йөриләр. Икенче көн чын зәрә була.

ийе инде аны, зәрә ботқасы дийерләр ийе. Икенче көннө менә иртә белән балалар инде сабан туйы көннө күкәй җийарлар ийе, һәрбер өй борона кереп. Қайсы төш бирер ийе, қайсы камфит бирә, ағайнесенә күкәй бирә. Бер атнаға йақын сабан туйы итәр ийек тә, аннары суқаларны қыңғырайтып басуға чығып китә йек.

*Сөйләүче: Хәлиуллина*
*Зария (1884 елгы).*
*Иске Шекше авылы*

Менә иңгелек Җаңыйл җийыны дийерләр ийе. Безнең аwыл шушы Қалатаwдан алдан ғына йы, нәсә диб әйтә торғаннар ийе инде шунда. Шекше, Җаңыйл җийыны диб әйтерләр ийе. Инде менә ул жаққа барадырыйық без нигә, Йәдегәргә. Ул жақта қәрдәшләребез бар ий(е), әнә шул җийынға барыр ыйық. Ә инде менә безнең шекше җийыны дип әйтерләр ийе безнекен, безгә килерләр ийе алар. Аннан суң инде менә Қалатаw җийыны дип, қәрдәш-ыруwы булса, анда төштөләр инде. Аннан инде иң азақтан менә Қамышлы җийыны дийерләр ийе, Қамышлы ул жаққа менә, Бусермәгә барадырыйық. Җийынға инде, Бадрәш җийыны бар. Бадрәш җийыны менә шушы ни жақ булырға кирәк, Теләчә йағы. Җийын өч көнгә бара, менә атна кич килерләр ийе қунақлар, ийеме, атна кич килгән жыйыны булыр ийе инде, килем жыйыны. Аннан инде жомға көн җийын булыр ийе, шимбә көн азақы җийын инде, таралу җийыны. Ә икенче йәкшәмбегә тағы икенче җийынға барырлар ийе инде. Печмән менә шушы сабанға төшкәч, хәдер бит менә сабан чәчтек бит инде, менә сабан туйы йасадық та сабанға төштөк, сабан чәчтег инде, иген иктек. Аннан суң инде менә хәдер қарабодай чәчәдер ийек, қарабодай чәчәр wахытның алдыннан үләннәр бик йақшы ғына матурланғач, шул wахытта печмән булыр ий(е) ул. Өч мәртәбә, өч атна, элек бәләкәй печмән дийерләр ийе, бер бәләкәй печмән, ансы шул қалған инде, ансында барып нитеп йөрмәсләр ийе инде, бәләкәй печмән дийәрләр ийе. Аннар(ы) инде икенче печмән. Икенче печмәндә, урта печмәндә, болонға китәрләр ийе. Анда саwда белә килерләр ийе, анда шунда симечкеләр, камфитлар, перәнникләр апкилерләр ийе, сатарлар ийе шунда инде йә сөлгөләр. Әнә шул шунда барып бер гуләйт (и)теп кайтыр ийег инде. Өчөнче печмәндә инде барса – барды, бармаса – йуғ инде. Өчөнче печмәндә инде шул қарабодай чәчәргә чығалар, қарабодай чәчәдер ийек ул

wахытта, ана хәдерге Азин (*авыл исеме*) дигән җиргә җийылып, анда печмән йасарлар ийе алар берҗулы. Менә шул печмән инде. Йәшләр баралар ийе, иртә белә тороп чығып китәләр гүләйт итеп, гармуннар белә болонға. Хәдерге шикелле, кичкә тикле гуләйт итеп йөриләр инде. Көннең озон wахыты, үләннең әйбәт wахыты, йәшләр, қызлар уйныйлар инде, берсен берсе танышалар, канфитын алып, қырыйға утырып, бик күңелле буладыр ийе инде, гел әйләнеп уйныйлар инде. Менә хәдерге шикелле.

*Сөйләүче: Әхмәтшин*
*Гыйльманша (1901 елгы).*
*Иске Шекше авылы.*

**Туйлар, туйлар.** Йаучы килә инде. Йаучы белә килешәме, йуқмы, килешсә қолақ сөйөнчөсө алып китә. Қолақ сөйөнчөсөнә нийен, эшләгән чолғаwын бирә, тағы иренә йабарға алҗапкыч бирә әйбәтләп. Пылатнадан тегәме, киндердән тегәме име. Айақ чолғаwы. Ололарына намазлықлар. Шундый нәрсәләр әзерләп бирә йенде. Шуның белә wәғдәләшеп китәләр. Аннары инде бик килешсәләр, туй wәғәдәсе қуйа тағы икенчесе килеп име. Туйға тағы мәһәр сорый. Мәһәргә тағы ничә йөз тәңкә ақча буламы, бер сандық, бер қомған, бер эләгән. Аннары аш саwытына күпме нәрсәләр тағы. Ничә қаз, ничә паштет, тутырыб апкитәләр инде, туйға барғанда. Ничә пар килә, қода килә, қодачалар килә име. Ничә көн, инде ике кич җоқлағач. Аннары ике кич йоқлап қайтқаннан соң, қайткач, туй ике көн, өч көн була бит әле, бик зурлаб анары кийәү алмаға киләләр. Икешәр пар атлар җигеп, қыңғыраулар тағып. Ишегалларында инде бай кешенең төрлө утлар йана име, шәп кыңғыраулар, кулыкуллармы (*колокол*), нәрсәләр шунда, шундый хикмәтләр белә киләләр инде, йақшы чаналар. Аннары кийәү қайта инде ике кич җоқлағач. Дүртне дә қуна әле қайсы берсе. Байлығына қарый инде. Парлы булса инде. Аннары кийәү қайтқачыннан тағы җырағырақ җирме, ниме, атна сайын бара, қыз җанына атна кич кенә бара, анда тағы ике кич йоқлап қайта. Аннары бер ай җөргәченнән, бер ай, бер җыл җөрдөләр инде әwәле алып қайтмыйчы, төшөрмиче име. Аннары килен төшөрәләр бер җыл торғачыннан. Қайсы балалы да булып килә аның күтәренеп. Ник ансына тағы шушы хәзерге замандағы шикелле кешеләр чақыралар инде, қунақлар

була инде. Тормошона ҡарата инде, тормошона. Байларныҡы байларча була инде, йарлыныҡы йарлыча була. Ҡайсыбер кеше мамыҡ мендәргә бастыра инде. Ҡайсы кеше тағы шунда атлар белән килеп кергәченнән, уң йаҡтан ир керсен, сул йаҡтан хатын-ҡыз керсен дип, шулай итеп тә йөргән кешеләр була атларын борғалаб ишегалдында.

*Сөйләүче: Ханнанова*
*Мөнәвәрә (1901 елгы),*
*Пүкәл авылы.*

Тегеннән, әллә ҡайлардан димчеләр килеп, ҡызны димләп шулай иттереп туйға ҡызны ыризалаштылар. Шуннан соң андары ҡолаҡ чийенчесенә ике сөлгөмө, өч сөлгөмө төйнәп, ашаулыҡ төйнәп ҡыз җағыннан кийәүгә апҡайтып бирделәр. Менә инде ҡолаҡ чийенчесе шул, ҡызға андары ике күлмәклек бирделәр бийаталар. Элекке заманда кесәбикә йе инде. Күрсәтсәм дә була инде сиңа. Йалында ғына. Андары читек-кәwеш, ҡомған, сондок. Элекке wаҡытта туйға алып киләләр шуны бийем, бийата. Шуннан соң ике көн туй итсә инде, ике көн туйдан суң, икенче көнне кийәүне пар атлар җигеп, ҡыңғыраулар белә кийәүне әпкиләләр. Тағы ике кич ҡунып китә кийәү. Ҡыз инде үз йортонда ҡалып (тора) бер ай буламы, бер җыл буламы. Кийәү килеп китеп-җөри дә андары йәш килен итеб алып төшәләр. Төшөргәндә ҡайсыбер кеше күпчеккә бастыра, ҡайсыбер кеше шул кийе генә алып керә. Туйда эризыҡ була. Менә җорттан, кийәү җағыннан дүрт күмәч алып баралар, бер ҡаз, андары ите дә була. Инде элеке заманда, саwым дип әйтәләр ийе, бал йасап аппаралар ийе. Зуррак кешеләр, байыраҡ кешеләр. Аны саwым диделәр элек. Ҡодаларның саwымы бармы, диделәр. Менә элеке заманда, бездән олараҡларда җуwача диләр. Ансы күзикмәк күк безнеңчә, җуwача диләр аны. Күкәйгә генә, майға ғына. Җуҡа, менә шушы таба зурлығы була. Хәзер күзикмәк дип әйтәбез инде. Җуwача, чәй туҡмачлары күк йуҡа була. Элеке безнең заманда җуwача диделәр. Без үскәндә күзикмәк диделәр, менә хәзер дә күзикмәк инде ул.

Ҡиндер орлоғоннан ҡатлама пешерә торғаныйыҡ, ҡыстыбый пешерә торғаныйыҡ майын чығарып, бик һәйбәтләп, бик тәмне ризыҡ була торған ыйы. Ҡамырны басасың да, җәйәсең дә, җәйгәннән суң орлоҡны ҡысып саласың да. Ҡамырны җәйеп саласың дағын йағып, тағы ҡамырны бүкләп ҡуйасың. Шул ҡыстыбый була торған

ыйы. Җылғырны аны шул орлоғон эченә тығасың дағын, майын чығарып, йылғырны шул қазанға салып пешереб ала торғаныйық. Қамыр эченә, пилмән күк.

*Сөйләүче: Сәмигуллина*
*Шәмси (1900 елгы).*
*Сәрдә авылы*

**Изгеләр чишмәсе** диб әйтәбез, шул чишмә буйында қаз сақлаған идек. Чиләкләрне атарлық булып чыға суwы, балаганы (*каралты*) өстенә җимерелеп төшкән. Аның элеккеге исеме Қадыйр чишмәсе йе. Бу җимерек чишмәсе дип қызық күрсәтер ийем. Тағы Гәрәй җылғасы, Дәрә таwы бар, қыйблаға қарап тора. Ар таwы бар, элек анда аwыл утырған булған. Ақай чишмәсе бар, ул бик бийек таудан чыға, шуннан да тәмне су җуқ. Бәдиғыттин чишмәсе бар, ул элек булмаған җирдән чықты. Без дә Талип урманы бар, шуннан өрәк чыға. Чутаwат белән күрше икесе ақча итәргә барғаннар, шунда берсе үтергән икенчесен, шуның өрәге йөри, күрәләр аны, күргән кешеләр бар дип сөйлиләр.

*Сөйләүче: Газизова*
*Бибифәрваз (1930 елгы).*
*Мичәнбаш авылы*

**Кием-салым турында.** Әнинең қалфағы бар ийе. Аның қырыйларын һәртөрлө уқа белә чиккән ийе. Бер өлөше қызыл, бер өлөше сары, бер өлөше зәңгәр, бер өлөше йәшел бик матур итеп чиккәннәр ийе, аның қырыйларын инде. Бу энҗеле түгел инде. Минем үземнеке бар ийе, баш түбәсендә генә торадырыйы, бик бәләқәй генә ийе, энҗелийе инде, өйөб – өйөб энҗе чиккән бик матур қалфағ ийе минеке. Сәйлән энҗе инде. Тағы хәситә бар ийе инде. Хәситәгә ахақ тегәләр инде матур итеп, уртасы ахақ, қырыйы челтәрле көмөш буламы анда. Ахақ араларына бер рәт тәңкә тезеп чығалар. Матуррақ фурмынный сәдәпләр дә тезеп қуйалар инде һәртөрлөсеннән. Хәситәне қырыйына бер рәт тәңкә тезәләр, ире тәңкә, аннары wақ тәңкә тезәләр. Аннары сәзәпләр тезәләр матурматур. Қыйғачқа менә шушылайға кийәләр аны. Чулпы ул, иң башта зур чулпы тағылған була. Аның очонда тәңкәсе булмый, аның очона китереп бәләкәйерәк чулпы тағалар. Ул пар-пар була инде, гөрәңкәле чулпы диләр аны. Чәч тезмәсе була йассы ғына, аны иң

төпкә тағалар инд(е) анысын. Ике пар чулпы була ул, аның бәләкәйе очондарақ тора, зурырағы йуғарырақ тора йнде. Шул чулпы, оло чулпы өстөннән тезеп китәләр инде бөтөн тәңкә, иллелек тәңкә, йегерем бишлек, йегермелек, умбишлек, уннық тәңкәләр тезеп китәләр инде. Ул чәч тезмәсе була.

*Сөйләүче: Бәдертдинова*
*Мәликә (1909 елгы).*
*Пүкәл авылы*

Кемгә куша, шул килә инде йаwчы булып. Бер, ике килгәч атанасы риза була инде. Аннар[ы] ақлашырға (*килешергә*) килә, ақлашқанда йегеткә сөлгө, айак сөрткеч, қулҗаwлығы бирә, булса ашаwлық бирә инде кыd ақлашқанда қыжҗағыннан бирелә торған әйберләр қолақ сөйөнчөсө була. Қалым, тарту турында сөйләшәләр. Калым малы, диләр, қызға күлмәк, читек кәwеш, қалын шәл, киҗе мамығы кебег әйберләрне. Ничә тәңкә ақча бире[р]гә сөйләшәләр, ул тарту була. Қыз инде бирн[ә] алып килә, йегеткә, бийем, бийатаға күлмәк, элү (*бүләккә элеп куелган сөлге*) элеп керәсең инде кергәндә төшкән жиреңә. Йәш килен сабан туйына да бирнә бирә. Қалым малы қар суwы тиd бетә ич, шуның күк қалым малы да тиd бетә имеш. Йабышып чыққан кыdға қалын да тарту дағын булмаған инде «Ки камdулың – туңасың, йабышып чықсаң – уңасың. Йабышып чыққан кичләреңдә, бер көн эрэҳәт қунасын», дип жырлыйлар ыйы.

*Татар Икшермәсе авылы*

## Мәзәкләр

Бер бик уңған килен булған. Моның пешергән ипиен барысы да мақтый икән. Қайынанасының киленен мақтатасы килмәгән.

– Күәсем әйбәт минем, күәсем, – ди икән.

* * *

Ире урманға утынға бара икән: «Мин қайтқанчы қапқа төбен ат белә керерлек итеп көрәп куй» дигән хатынына.

Қайтқач, хатыны «Қәжи, мин қар көри алмадым, син йаратқан қабақ мәлеше пешердем», – ди икән.

*Сөйләүче: Рамазанова*
*Мәрьям (1939 елгы).*
*Пүкәл авылы*

* * *

Бу тирәдә мал бырачы булғандыр бәлкем, без ул қәдәресен белә алмыйбыз. Ну безнең ат асырап торған ҳуҗалықларыбызда ат чирләw булғалый торғаныйы. Аны сиҳәтләндерү өчөн шундый бер урwныбыз бар ийе. Аны кирәмәт, чирмеш зираты диб әйтеп менә шунынан қайыннардан чирләгән (атны) әйләндереп җөрү ғәдәте бар ийе. Шылай[и]йтеп җөргәнем дә бар. Туйда ни пешерәләр ийе. Чәкчәги дийерләр ийе аны, төш. Баллап, аны өстөнә төрлө камфитлар тезеп қуйарлар ыйы да, аштан суң шуны чығарып, андары суң аңар бирерләр ийе бүләк, апкилгән кеше. Анда арышынны табармы җә башқа ақчаданмы. Шулай итеп бүләкләрләр ийе. Аны өч таба әзерләрләр ийе. Өч патмус берсен кийәwгә кире җибәрергә. Кийәw барып қунып қайтқанның соңонда, үзенең иленә қайтып, үзенең йәш иптәшләрен чақырып, шунда тағы шушы төслө үг иттереп бүләкләр салып, ашыйлар. Шуны төслө итеп уздырып җибәрдек без йәшлек заманын.

*Сөйләүче: Вәлиев*
*Арслан (1892 елгы).*
*Сәрдә авылы.*

# ГАСЫРЛАРНЫ КИЧКӘН ЙОЛАЛАР
## (Җирле сөйләш текстлары яссылыгында)

*Флера Баязитова*

2013 елның җәендә Мамадыш районына оештырылган комплекслы экспедиция барлыгы 20 авылда эшләде, авыллардагы укытучылар, өлкән буын вәкилләре, мәдәният йорты һәм клуб хезмәткәрләре ярдәмендә магнитофон тасмасына яздырып бик күп мәгълүматлар туплады. Мин үзем, мәсәлән, халык йолалары һәм йола терминнарын язып алдым.

Билгеле булганча, халык йолаларының күбесе бүгенге көнгә инде югалып өлгергән яки югалып бетү алдында торалар. Ләкин әле өлкән буын кешеләренең телендә, хәтерендә шактый гына борынгы йолалар һәм йола сүзләре саклана. Алар буыннан-буынга тапшырылып килгәннәр. Менә шул рухи байлыкны халыкның үзеннән сөйләтеп, мөмкин кадәр тулырак итеп җыйнап алу бик зур бурыч булып кала килә.

Мамадыш районында яшәүче татарларның сөйләше җирле үзенчәлекләре белән урта диалектның казан арты сөйләшләре төркеменә керә. Мамадыш районында керәшеннәр, ягъни христиан динендәге татарлар да бар. Керәшен авылларының сөйләше шулай ук урта диалектның казан арты сөйләшенә карый, әдәби телдән аермалар күп түгел. Экспедиция вакытында һәр ике төркемгә караган татарларның сөйләше, традицион йолалары, этнолингвистикада кабул ителгәнчә, җирле сөйләш яссылыгында, ягъни телне үзгәртмичә, ничек сөйлиләр шулай итеп язып алынды. Йола терминологиясен, йола сүзләрен контекстта, текстлар эчендә, ягъни иллюстратив материаллар белән ачыклап, ныгытып баруга игътибар ителде.

## Туй йолалары

**Димче. –** Әwәлерәк булған ул димчеләр. Ике арада йөреп, сөйләшеп-киңәшеп табыштырғаннар.

«Ачып керергә – қапқасы бар,

Ишек алдында – танасы бар», – дип мақтағаннар җегет җағын (*Түбән Сон*).

**Килен, килен төшкән йорт. –** Бай киленнәр бик сирәк булды ул.

«Чиләгенә күрә – қапқачы,

Қапқачына күрә – тақтасы», – дигән кебек, килгән килен дә, килен төшкән йорт хуҗалары да бер төслерәк булды безнең заманда. Алай күп бүләкләр бирешү булмады ул чағында аwылда.

«Тиң – тиңе белән,

Иске чикмән – җиңе белән», – дигәннәр.

Менә «усал» дип даны чыққан нәселләр дә бар.

«Усал атым – үз атым,

Чықмасын җаман атың», – дигәннәр.

Усал булсақ та киленле-бийемле бик тату тордық (*Урта Кирмән*).

**Өшәнчек әйберләре** – кызның кияү өйенә алып бару өчен әзерләгән элү әйберләре, сөлге-тастымаллар.

– Қыз йағы никахқа хәтле килеп, кийәү өйендә өшәнчек әйберләрен элеп китә торған ыйы: қызыл башлы сөлгеләр, матча кашағалары, чыбылдықлар, парчалы чаршаулар, тәрәзә элеңгеләрен элеп қуйарлар ыйы.

– Элек чаршау түгел, чыбылдық ыйы.

– Тәрәзәгә элеңгеләрне үзебез тектек. Ақ бәзне телле-телле итеп тегеп, элеп қуйар ыйық (*Сәртек*).

– Кашағалар әләр ийек: матча қашағасы, түр қашағасы, ишек қашағасы булды.

Матча қашағасы анысы тарырақ була, түргә элә торғаны киңрәк була (*Түбән Яке*).

Челтәр: тәрәзә челтәре,
карawат челтәре.

– Өшәнчек дип сөйләшерләр ийе инде. Тәрәзә челтәрләрне үзем бәйләп алып килдем.

Карawат итәгенә челтәр бәйләдем (*Түбән Яке*).

**Сөлге-тастымаллар. –** Қызыл башлы сөлгеләр, тастымаллар элеп қуйарлар ыйы бүлмә тақтасына.

– **Қижеле тастымаллар** да булды, элек қулдан суққаннар, оста булғаннар.

– **Алтастымаллар** әзерләгәннәр, ашқа килгән кунақларның алдына сузып салырға.

– **Бикжаулыгы** – сөлге. Бикжаулыгы да булды тәрәзә арасына қуйарға.

– **Йәш килен сөлгесе** – башы қызыл сөлге булды, пачутлы булыр ийы ул.

– **Килен жаулыгы, чөй жаулыгы** – дип әйтерләр ийе. Ул тәрәзә башта эленеп торыр ыйы. Суққан чөй жаулыгы була ул, эстинәгә элеп қуйыла, чөйгә. Ағач чөйгә эләләр, тимер чөй йарамый. Өйне матурларға эләләр (*Кече Кирмән*).

**Күпчек** – мендәр.

– Ике пар күпчегем бар ыйы минем. Күпчек аwызын мәк чәчәкләре төшереп, чигеп қуйған ыйым.

**Сандық, чумадан, төйөнчек. –** Өшәнчек әйберләрен, сөлге-қашағаларны сандыққа тутырып алып килде килен, сандығы булса инде. Сандық өстенә пар күпчеген қуйа.

– Чумаданны кеше чумадан белән алып килер ийе. Қайсыбер кешеләр төйөнчек белән дә алып килер ийе (*Олыяз*).

**Бирнә** – килен бүләге: күлмәк-ыштан, айақ чолғаwы һ.б.

– Бирнә дип **күлмәк** белән **ыштанны** кийәүгә алып бара, биатаға ақ ыштан алып бара.

– Биатаға да, кийәүгә дә **айақ чолғаwы** алып килсә, ул дәрәҗәле килен булды инде.

– Биатаға алып килде айақ чолғаwы, түбәтәй. Чолғау алып килерләр ийе күбесенчә. Айаққа чорнап қуйарлар ыйы.

– Мин чики (*чикләwек*) саттым да, әнкәй булған кешегә күлмәк алып килдем, мәрхүмгә, йәшел күлмәк.

– Бианаға намаз уқырға намазлық, айақ сөрткеч алып киләләр ийе (*Шәдче*).

## Урам әйләнү

**Тимерхут арба – тырантас. –** Кийәү белән кәләш **тимерхут** арбаға утырып қына аwылны әйләнәләр ийе. Қыш көне кашаwайға

утыралар. Урам әйләнеп йөриләр ийе. Қарарға чыға торғаныйық бөтен урам халқы beлән. Ул хөрмәтләү, игътибар күрсәтү, аларны үз итеп йарату булды инде. Тимерхутларға утырып йөрдек туйларда.

Бергә-бергә утырғанда
Уйнашу да көлешү.
Бер айрылғач, булыр микән
Сезнең белән күрешү?

Шулай тимерхутларға утырып урам әйләнәләр җегет белән қыз. Җазылышырға килгәндә дә урам әйләнеп йөри торғаннар ийы. Қыш көне кашаwай диләр, җәй көне тимерхут (*Түбән Сон*).

**Қода кертү, қода чақыру. –** Қода кертүләр, қода чақырулар да булды элек. Башта туй булған йортта қода күрергә чақыралар. Қода белән бер табында утырғач, аның күчтәнәчен ашағач, әбизәтелни қода төшерү тийеш була. Башқа аwылдан булса да, үз аwылыңнан булса да, қодаларны чиратлап-чиратлап ашқа ала торғаннарыйы.

Қоданы ашқа чақырмаған кешеләр бик сирәк қаладырыйы. Көндез мәҗлес, кич мунча, қодалар қәдерле, сыйлы булды. Шулай тийеш булған ул (*Түбән Тәкәнеш*).

## Сабан туе

Бөтен йәнәшә-тирә аwыллар киләләр ийе Олыйаз сабан туйына.

Тушы Олыйазда матур қулҗаулықлары чигеп атларны бизиләр ийе. Әле генә сөлге җыйдылар қолғаға бәйләп, чиләк белән күкәй җыйа торғаннар ыйы.

Элек ишшу да матур булған ул **җаулық җыйу**. Қолғаға бәйләп җыйалар әйберләрне. Атларны бизәп, атларға утырып та җөриләр.

Әйбер бирәбез инде, сөлге, җә җаулық.

«Умартағыз бишкә айырсын», – ди-ди теләк теләп китәләр әйбер биргәч. Тегендә, су буйында буладырыйы сабантуйы. Ат чабышлары буладырыйы.

**Сабан туйы түгәрәгенә** – кичке уйыннарга төшәдерийек җаулық җыйған көннән башлап. Ағалҗапқычларны чигеп бәйләдек, чүни галуш кидек, чабата-итең кийеп чығучылар да булырыйы.

Чүни галуш – ул эчсез эрзиңкә-галуш.

Әни хәзер ақ бәзне шулай төйнәде, қараға манды да, ақ алҗапқыч белән кидем. Ул бик матур булды инде үзенә күрә. Шулай иттереп күлмәк җасадық сабан туйына.

Сабан туйына бәлеш пешерәбез, өчпочмак, төш, чәчәкләр. Хәзер ирерәк төш пешерәбез, туралы май қуйабыз, тоқмачлы аш.

Малы-туwары булған кеше, башқа аwылдан килсә дә, қайтып китә, йәшләр қунып қалалар, кичке уйынға чығалар (*Түбән Яке*).

**Печән өсте**

– Эңгер жақты булуға печән чабарға төшеп китәрләр ийе. Мин дә печән чабарға чықтым. Үчәли жақлары, Кече Кирмән белән жәнәшә чабар ыйық болында.

Ул печәнне тезелеп чабалар да, ул кибә шунда урында. Аннары тырма белән жыйабыз, сәнәк белән чүмәләгә салабыз, сәнәклекләрне сәнәк белән күтәреп. Чүмәләләрне ат белән тарттыралар ыйы.

Умбиш көн буйы жатыр ыйық болында. Болында бичыр уйнадық, гармуннар апчығарлар ыйы.

– Йаңғыр килә башладисә, чалашлар жасарлар ыйы чыбықлар белән, печәнне өстән қатлап қуйарлар ыйы. Йаңғыр үтми.

Печән **питыраудан** соң қалынайа ул, питыраудан соң төшәләр печәнгә.

Чалғы белән чабабыз. Тырма белән пакусқа жыйабыз. Кибән өйгәндә бер кеше өстә тора, астағылар сәнәк белән алып биреп торалар.

**Әwенне кибән** қуйалар печән жүwеш булғанда. Кибән төбенә ағачлар қуйып өйгән була.

– **Чалғы жанаwычы** бар ыйы печән чапқанда. Берәү жанап торучы булыр ыйы.

Чабалар, печән кибә.Күбә йасап жыйабыз тырма белән. Чүмәлә қуйабыз тәгәрәтә-тәгәрәтә.Кибәне шунда болында булыр ыйы, очлап қуйарлар ыйы. Жаз житә башласа, түбәгә алып қайтып қуйарлар ыйы.

Болында печән чапқанда бабайлар:

«Чалғыңны китер, үзем жаныйм», – дип әйтеп торалар ыйы.

Хәзер чалғы жаный белмиләр дә инде. Үзебез жаныйбыз, хатын-кызлар булсақ та.

Печән өстендә атларны бизиләр ийе, жырлап төшәдерийек, жырлап қайтадырыйық болоннан.

– Тал чыбығын бөгеп, өстенә печән өйеп **қуш** йасыйлар ыйы. Жаңғыр жауса, шунда кереп утыралар (*Түбән Яке*).

– Печәнчеләргә **солы йармасы** белән аш булыр ыйы, **болын йафрақлары** салған чәй булыр ыйы, бик тәмләп эчәр ийек қызуда.

Җафрақ чәйе эчә торған ыйық болында. Бик тәмле чәй булыр ыйы ул. Җир җиләкләре, қайын җиләкләре күп булыр ыйы.

– Печән өстендә болында чәй қайнатабыз. Берсеңәр су алып килергә қушалар. Қайда қайнаwық бар йылғада, шул төштән генә су алып килеп эчә торғаныйық.

Қайнаwықлы урын ул билгеле була, су қайнап чығып тора. Шул төштә генә чиста су була дип, су алып килеп, чәй қайната торғаныйык.

Қайнаwық ул басуда да була, өсте қаплап қуйылмаған, улақ қуйылмаған була, үзе чығып тора, аңға кеше қулы тимәгән була.

**Аулағилар.** Аулағилар булды ул. Әниләр башқа аwылға китә. Без, қызлар, хуҗа булып қалабыз. Җыйылабыз, җырлашабыз. Аулағилар ул гармунсыз булмыйдырыйы.

Аулағида **дәwешләмә** пешерәбез. Дәwешләмә ул табада пешә. Астына қамыр салмыйсың. Бәрәңгене, җарманы сала, булса ит тә, май да сала. Өстән қамыр қаплый.

Әле малайлар керәләр дә ул дәwешләмәне урлыйлар. Без дәwешләмәсез дә қалабыз. Тегеләр шайарып урлый инде. Усаллық белән түгел.

**Қыстыбыйларға** хәдәре пешерер ийек аулағида.

Аулағиларда утырғанда кемнең лампысы йақтырақ йана, сорап торыр ыйық.

Өчле қуықлы лампы, җиделе қуwықлы лампы, унны қуwықлы лампылар булды. Кайсы кешедә суқыр лампы булды.

Җиделе лампы йақты йана
Эчендә майы булса.
Безнең җанқай қайтыр әле
Эчендә җаны булса.

Сандуғачлар сайрап тора
Қайында да чыршыда.
Ник сөймәскә, сөйәм аны,
Гармунчы да, җырчы да.

Уйна дустым шахты көйен
Шахты көйен җаратам.
Шахты көйен җырлағанда
Бар қайғымны таратам.

– Аулағи гармунсыз булмыйдырыйы. Қызлар йаулық чигәләр ийе аулағида. Қызлар җегетләрне мунча ташы апқайтырға җибәрәләр ийе (*Олыяз*).

– Бер қыз җарма апкилә, берсе май алып килә. Аулағида бәлеш пешерәләр. Қайсы чақта пичтән бәлешне урлап та апчығып китәләр. Аулағида җыр атышқан wақытта рәхәтләнеп җырлап утырадырыйық.

Олы йулдан өчәү килә,
Мин аларны таныйым.
Аллы күлмәк, гармун тотқан
Ансы минем җаныйым.

Безнең күрше җегетенең
Исемнәре Нурғата.
Мәхәббәтем йөрәгемдә
Нурланып чәчәк ата.

Қулымдағы йөзегемнең
Исеме матур Хәбиб.
Сөйәсеңме, сөймисеңме
Чын дөресен әйт тә бир.

Ақ қуйан дип атқан ыйым
Булды тауның қатлаwы.
Олы җулдан берәү килә
Гел дә шуның атлаwы.

Кич утырғанда ойоқ бәйли, бийәләй бәйли, гармун уйнап тора, җырлыйбыз.

Без андый малай түгел,
Без мондый малай түгел.
Төрле қулға қарамыйбыз,
Күгәргән қалай түгел.

Тәрәшлесен биреп җибәргән.

«Менә син шуның хәтлене орчоқны эрләп апқайт, киләп җаса». Қабасын, орчоғын, сүсен биреп җибәргән. Җегерме тәрәшме анда. «Менә шуны эрләп бетермиче қайтма».

Қулымдағы йөзегемнең
Исемнәре Мортаза.
Ай-қойаш дип торған ыйым
Син икәнсең уртада.

Басу қапқасын чыққанда
Зәңгәр чәчәк житен ул.
Бергә чақта ансатыйы,
Айырылғач читен ул (*Түбән Сон*).

**Утырма.** – Туғаннарың қайсы аwылда, шунда утырмаға бараларыйы. Алар сиңа килә. Утырма ул қара-қаршы булайы.

– Утырмада кич чыққач, қунақ қызын жегетләр күзли. «Әнә шул қунақ қызын мин озатам». «Йарый, түлке әйбәт, тәртипле генә озат».

Қунақ қызны ашқа алалар. «Сезгә қунақ қызы килгән икән, безгә дә апкил, җәме», – диләр ийе.

Башқа аwылға утырмаға барып, қунақ қызы булып қунаққа җөргән. Үзенең туғаннарына барған. Қайсын урлап алып қалғаннар қызларны.

Кыз бала – ул қызыл чәчәк,
Ир бала – зәңгәр чәчәк.
Қызыл чәчәк, зәңгәр чәчәк
Бергә ғомер итәчәк.

Қулымдағы йөзегемнең
Исемнәре Муллахмәт.
Мине зурлап, мине сөйеп
Килүегезгә рәхмәт.

Тәрәзә ачып җимнәр сиптем.
Ашағыз, қошқайларым!
Мәкнең асыл чәчәге күк
Йәшәгез, дускайларым (*Сәртек*).

– **Чабата өмәләре** булыр ыйы. Без җыйылышып утырып, утызар кийем чабата җасар ыйық кешегә. Уникегә тикле кич утырып уйнар ыйық андары чабата өмәсендә.

Чабата өмәсендә, җарып, қоры бәрәңге пешерерләр ийе. Җә бер табақ аш эчәр ийек пешерсәләр, өйрә ашы эчәр ийек.

**Қарама чабата** да җасадық. Қарама чабата җүwештә кийәргә җарамый, қорода кийәрләр ийе қарама чабатасын.

**Җиделе җүкәдән чабата** – йәш қызларға дип йасадылар.

**Туғызлы җүкәдән чабата** – олы айақлы қешегә кийәргә.

**Җаңа чабата** – сабан туйында кийәргә.

Қазан белән Бишбалтаның
Биш чақырым арасы.
Җөзләреңә нурлар сибә
Қашларыңның қарасы.

Җырлыйк әле, җырлыйк әле,
Җырлыйк әле күп итеп.
Бергә булған wакытларны
Онытa алмаслык итеп.

Җырлыйк әле, җырлыйк әле,
Барыбыз бергә чақта.
Озақламый таралырбыз
Төрлебез төрле җаққа.

– Суғыш wакытында чабата җасадық, чабата өмәләре булыр ыйы. Утызар кийем чабата җасар ыйық тағын анда аш әзерләрләр ийе, чабата җасап бетергәч. Җә бәлеш пешерерләр ийе, җә тоқмачлы аш булыр ыйы, җә дучмақлар булыр ыйы, бәрәңге йағып пешергән. Шулай сыйланыр ыйық тағын, андары утырып уйнар ыйық күңелле иттереп. Су чыққан wақытта күтәртмәле чабата кийәр ийек, әтиләр җасап бирер ийе. Сөйән ағачыннан (*Урта Кирмән*).

Җаңғыр ботқасы дип әйтәләр ийе. Олы қазаннар асып, җаңғыр ботқасы пешерерләр ийе. Қайсы җарма, қайсы май бирә. Ботқа пешкәч, утырып ашыйлар күңелле иттереп. Андары су сибешәләр ийе. Манма су булып қайталарыйы.

Суның теге җағында чишмә җақын гына йы. Без балалар шунда җөрдег инде.

Қарчықлар ындыр артына чығып, қыйбылаға қарап, җаңғыр доғасы уқыйлар ыйы. Ходай тәғаләдән җаңғыр сорыйлар.

«Шифалы җаңғырлар бир, Ходай,
Игеннәр үссен,
Хайwаннар хақына,
Балалар, йәшләр, қартлар хақына» –

дип, теләк тели-тели җаңғыр ботқасы җасыйлар ыйы.

Қайсы җарма, қайсы май бирә. Қазан астына кирпечләр қуйып, учақ йағып ботқа пешерәләр. Без, бер көтү балалар, җаңғыр ботқасы ашарға барадырыйық җыйнаулашып (*Шәмәк*).

## Йорт-җир, өй эче

– **Қычийақта** да сәкейе, олы йақта да сәкейе. Менә монда йанда да буладырыйы **дүртайақ** дигән **сәке**. Анысы киң түгел ийе. **Йан сәке** булыр ыйы ул.

Сарық бәрәнләсә, мал өйең булмаса, бәрәннәрне тутырырлар ыйы шунда сәке астына.

Мал өйләре ул бай кешеләрдә генә булыр ыйы.

– Қечекйақта сәке, аның җанында өстәл булыр ыйы. Анда сәкедә дучмақ, бөккәннәр йасап пичкә тығасың.

Олы йақта да сәке булды. Чаршау қорып қуйар ыйық. Сәкедә айақ бөкләп утыралар ашағанда.

– Мөрҗә қырыйында сандық була. Сандық өстенә урын-җирне җыйыштырып қуйалар матурлап өйеп, челтәрләр қаплап.

**Идән йуу –** Идәннәрне дә торомнан торомға көл белән, себеркеләр белән ышқып җуwа торған ыйық. Идәннәр ақ булсын, чичта булсын, кеше кергән чақта: «бақчи, идәнең», – дип торырлық булсын. Кешедән қалышасы да килми бит. Қомнап та җудық.

– Идәнне мунчала белән, қайсысы көл, қайсысы қом белән ышқып җуwарлар ыйы. Қайсысы шул көйенчә генә җуwар ыйы. Түшәмнәрне қом белән ышқып җуwар ыйық. Анда күзгә төшәр ийе көлләр, қомнар. Үзенә күрә кеше чичта торды барыбер.

– Қом белән ышқып җуған идәннәр сап-сары булыр ыйы, көл белән ышқып җусалар ап-ақ булыр ыйы.

Қом белән ышқып җусаң – идән сары була.

Көл белән ышқып җусаң – ак була (*Ямаш*).

## Таш суwы чығару

– Элеке кеше ташны басудан җыйған. Тишекле таш җыйалар ыйы. Шул ташны киптереп өйеп қуйғаннар мунча җалдына. Йоморырақ, тишекле таш. Йандырып суға салғач, ул изелеп төшәдерийе, ташы қалмыйдырыйы аның.

– Ташны wатып мунча пиченә салабыз утын белән аралаштырып. Бер дә қымшатырға җарамый. Ул җана, қыза қып-қызыл булып. Чиләк белән су алып кереп, қысқыч белән шул ташны алып суға салабыз. Ул қайный шапырдап. Ап-ақ булып чыға ул таш суwы. Аны өстен қаплап, салқынча урынға қуйабыз да, су белән сыйықлап морҗаны ағартабыз.

– Мунча пиченә таш сала торған ыйық. Ул басудан җыйған тишекле таш булыр ыйы. Ул таш қыза инде мунча пичендә. Чиләккә су салабыз да, шул пичтә җанып қызған ташка қысқыч белән алып, чиләктәге суға салабыз. Ул лағор-лоғыр қайнап чыға. Бер кешенеке чығар ыйы, ә қайсы кешенеке чықмас ыйы ул таш суwы.

«И, таш суwы чығарып бир әле», – дип әйтерләр ийе. Имеш, таш суwы чықмаған қатынны ире җаратмый.

«И-и, сине ирең җарата шул», – диб әйтерләр ийе таш суwы әйбәт чықса, шайарыб инде ул.

Ташына қарағандыр инде ул. Ташлыйыйлга дигән йылға бар бездә. Шуннан таш алып төшәдерийек. Эче ақ таш булыр ыйы ул.

Тәрәзә қашағаларын да шул таш суwы белән ағартырыйқ. Элек буйаулар жуғыйы. Тәрәзә қапқачларын қыш көне қаплап қуйа торғаннар ыйы. Бер чиләк таш суwы әллә ничә айға җитә, қуйы була ул. Шуны су белән сыйықлап ағартабыз (*Түбән Ушма*).

## Киндер, җитен эшкәртү

**Киндерне булдыру** – киндер сабагын суга салып йомшарту.

– **Киндерне булдырырға** суларға салалар ыйы. Судан алып, киптереп, талқыйлар ыйы.

– **Киндер талқу –** киндер сабағын йолқып суға салалар ыйы дағын, ул йомошыйдырыйы. Аны киптерәләр ийе. Андары талқы белән талқыйлар ыйы. Киндерне қара мунчаларда, су буйы мунчаларында талқырлар ыйы. Мунчада оторо киптерәләр, оторо талқырлар ыйы. Тузаны өйдә чықмасын өчен шулай мунчаларда талқыдылар, тәртипләп җасадылар (*Түбән Тәкәнеш*).

## Киндер суғу

– Ашаулықлар, алтастымаллары суқтық. Ыстаны бар ыйы. Шул ыстанда суғар ыйың. Алтастымалым әле дә җөри, әни белән суққан. Түшәк тышлары суқтық. Ул түшәк тышын ақтан суқты да әни, имән чикиләрен (*чикләвекләрен*) алып, төйнәп-төйнәп қуйды дағын, төйнәгән бер җирен бәйләп қуйды матурлап-матурлап. Аннарығысын әни шуны буйау белән манды. Буйау белән мандыдағын киптерде. Теге төйнәгән җирен чишеп җиппәргәч, төйнәгән җире парча булып қалды, ақ булып қалды.

– «Қайан алдығыз моны?» – дип сорадылар, қызықтылар кешеләр. Бик матур булған ыйы шул бизәкләре. Әни дәген бик остайы, әти дәген бик оста балта остасы булды (*Түбән Яке*).

## Киндер майы чығарту

– Киндер орлоқлары җиткәч, басудан орлоғын уwып алып қайтыр ыйық бала-чагалар җыйылып.

Киндерне башта җаралар ыйы дағын **майын чығаралар** ыйы. Киндер майын чығарып, пич бәрәңгесен киндер майына манчып ашыйдырыйық.

Орлық салып бәрәңге белән бөккән пешерә торған ыйық, орлоқны төйеп.

Ул орлоқны мичкә йалқынға қуйып киптереп, аны төйәр ийек майландырып.

Мичкә ипи салып пешерәбез дә йаңға пешкән ипине орлоқ майына манчып ашыйбыз.

Бәрәңгене бөтөннәтә пешереп тә орлоқ майына манчып ашый торған ыйық (*Кукчишмә*).

## Җитен йолқу. Җитен майы чыгарту

**Җитенне** дә йолқып алалар ыйы айаққа бәрә-бәрә: «балчық кермәсен».

Җитен ул ансысы қысқарақ та буладырыйы, орлығы да бик күп чықмас ыйы. Аннары аны сабағач беләп суғып, суwырып, җитен орлығын җарырға алып баралар ыйы. Анық майын чығарталар ыйы. Майы бик тәмне булыр ыйы. Бәрәңгеләр манчып ашый торған ыйық.

«Менә җитен майы қайтыр, балалар, шуның беләп бәрәңге ашарбыз», – дип әйткәне бар әнәйнең.

Табақ беләп бәрәңге пешерде әнәй. Шул май қайтқанны көтеп утырдық қабықлы бәрәңге пешереп (*Югары Кыерлы*).

## Киндер орлыгы, җитен орлыгы ашлары

**Төп. –** Қул җарғычы булыр ыйы. Орлоқны җарғычта җарадырыйық та җулпычта җилпер ийек. Орлоғын көйлегә салып төйә торған ыйық. Көйленең төйә торған ағачы да бар, **кисап** дип әйтәләр ийе. Ул инде **көйле сабы** дигән сүз булғандыр. Төйәдериек-төйәдериек тә андары баса торған ыйық. Басқанда анық майы чыға. Ана шуннан қалғаны төп дип атала (*Түбән Яке*).

**Йылғыр** ул пилмән шикелле, түлке ит беләп түгел, төйгән орлоқ беләп пешерерләр ийе. Кем wағырақ итеп, кем олорақ итеп

пешерә. Су қайнап тора, тиз генә салып пешереп, судан сөзеп алалар да қайнар көйенә ашыйлар.

**Эремчек йылғыры, бәрәңге йылғыры** да була, шулай пилмән шикелле була, түлке йылғыр дип әйтелә (*Түбән Яке*).

**Күмәч. –** Ә төйгән җитен орлоғының төбеннән күмәч итеп салыр ыйық. Аның майы белән бәрәңге ашар ыйық, ә төбе белән күмәч салыр ыйық. Анысы җитен орлоғыннан. Тегермән тартып он итә торган нәстәләр түгел алар, шулай май чығара торған (**Түбән Яке**).

**Бөккән. –** Киндер орлоғын көйлегә салып төйәбез. Бөккәннәр пешерәбез киндер орлоғыннан. Аның тәмлелеге! Майлары сығылып торадырыйы. Хәзер жуқ бит менә шулар (*Түбән Тәкәнеш*).

## Башка төрле ашлар

**Чәй төше** – чәкчәк формасындагы камыр ашы.

– Чәй төшен балға қатыралар, wағрақ була. Чәй төшен ике патнусқа йасаталар.

**Чәй тоқмачы** – кош теле, қыйықлап кисеп пешерелгән камыр ашы.

– Чәй тоқмачларын, чәй төшләрен туй алдыннан пешереп, матур саwытларға салып қуйарлар ыйы.

– Күкәйгә генә қамыр басып, жуқа ғына итеп җәйәсең дә өчпочмақлап кисәсең, қайнаған майға саласың. Шул қайнаған майда бик тиз генә күпереп менә ул. Чәй тоқмачы була. Тоқмач җәйгән кебек қамыр җәйәсең дә кисеп пешерәсең (*Олыяз*).

**Дәwешләмә** – төпсез бәлеш. – Дәwешләмә ди торған ыйық. Асты қамырсыз бәлеш, өстән генә қамыр қаплап қуйалар ыйы. Бәрәңге белән, ит белән булыр ыйы, әзрәк киндер орлоғы да қуша.

– Қаз итләре турап пешергән дәwешләмә бик тәмле булыр ыйы, шулпалы булыр ыйы.

– Дәwешләмә дип бәрәңге, әзрәк киндер орлығы қуша, табаға сала. Төбе қамыр булмый, өсте әз генә, жуқа ғына қамыр була (*Тулбай*).

**Дучмақ** та, **дурочмақ** та дип әйтәбез. Аны сезнең Балтач йақлары пәрәмәч дип әйтәләр. Бәрәңге дучмағы, орлоқ дучмағы пешерәбез. Қамырны қуйасың. Қамыр қабарып менә. Бәрәңгене

пешерәсең дә изәсең. Қабарған қамырны түгәрәк-түгәрәк итеп җәйәсең дә шул қамыр өстенә төйгән бәрәңгене җәйәсең. Өстен күкәй белән майлап, пичкә тыгасың. Шул дучмақ була. Сары май белән майлап җибәрә инде, майы булса. Телеңне йотарлық була.

**Орлоқ дучмағы** да була. Орлоқны төйеп, төйгән бәрәңгегә қушарлар ыйы.

**Қара дучмақ** дип, киндер орлоғының үзеннән генә дә пешерерләр ийе. Бездә бер қатынның қушаматы қара дучмақ ыйы (*Түбән Яке*).

**Бәлеш. – Солы йармасы бәлеше** – иң тәмлесе була торған ыйы. Солыны башта қазанда қайната, киптерә дәген төйеп, **жулпычта җилпи**. Аның қабықлары, **кибәге очып бетә, чын йармасы** ғына қала (*Урта Кирмән*).

– **Солы йармасы бәлешен** қабақ белән дә, сарық ите белән пешердек.

– **Борай бәлеше** дә бик данлықлы бәлеш булды ул. Борай бәлешенә тура салып пешерәләр ийе.

## Табында бәлеш кисү

– Ашны эчәргә башта. Бездә шулай «аш эчү» дип әйтәбез, сезнең Балтач йағында аш ашау диләр. Ашны эчкәннән соң бәлеш ашарға. Бәлешне оста ғына кисә бәлеш бүлүче.

Әғузе бисмилла әйтә, шунсыз ризыққа тотонырға җарамый.

Бәлешнең қапқачын түгәрәкләп кисеп, кисәкләргә бүлеп кеше сайын өләшеп чығам. Бер өлеш – иң беренче муллаға, аннан соң аның қырыйында утыручыға, рәттән бүлеп чығам бәлешне. Қайсы кеше бер генә қалақ бәлеш салдыра, ул өйендә ашап килгән була, қайсы ике, йә өч қалақ салдыра. Ул йә йармалы белеш, йә ит белән бәрәңге, йә җимешле-қабақлы бәлеш була. Шулай қалақ белән кеше сайын салып чығам.

Мулла үзе әйтә: «Әйдәгез, бәлешне аwыз итик», – дип. Иң беренче бисмилла әйтеп мулла қаба, мулла қапмый торып аwыз итәргә йарамый. Йарты бәлеш кенә ашала хәзер. Қала ул. Қайсы кеше төбен дә кистерә.

«Бәлеш төбен ашамасаң, Йоқың керми», – диләр (*Урта Кирмән*).

Бәлешне табында кешегә ашата белергә дә кирәк. **Табын қараучы** бәлешнең өсте қапқачын ача дағын турый. Ничә кеше

була, шуңа җитәрлек булсын өлешләре. Шулай тигезли торғаннар ыйы. Өстен кисеп, майын да шунда сибәләр.

Чамасын белгән, аш-суға йөреп өйрәнгән, рәтен белгән кеше кирәк аш бүләргә, бәлеш бүләргә дә.

Анда әле пич башындағы бәләкәй балалар қарап торалар.

«Әнекәйем, бәлешнең төбен кисәләр, безгә қалыр микән?» – дип.

Хәзерге шикелле өстәлләр сығылып тормады элек. Хәзер бит қоштабақлар қуярға да урын җуқ өстәлдә, табыннар мул хәзер.

Аллаһы тәгалә шушы нигъмәтләрдән айырмасын, дөнйалар имин булсын!

«Бик тәмле булған аш-сулары, шундый мул итеп, әйбәт итеп әзерләгәннәр», – дип, рәхмәтләр әйтеп қайтып китәләр ийе (*Урта Кирмән*).

## Қаз қоймағы

– Қаз қоймағы пешерәләр қаз суйған көнне. Қоймақ пешерәләр, қаз майын эретәләр дәген төтеннәре чыққанчы бик қаты қайнаталар, көйдерәләр. Көйдермәсәң, ул синең эчеңне җибәрә. Қаз қоймағы – данлы қоймақ булды ул (*Хәсәнша*).

– **Шишара** ул төче қамырдан була. Майлар, күкәйләр, суды салып пешерәләр. Ипи булмағанда пешереп алғаннар шишараны. Аның сүзе дә бар:

«Ипи йуққа бичара, пешергәннәр шишара».

Самаwыр қайнатып, шишара белән сөтле чәйләрен эчкәннәр тәмле иттереп (*Түбән Ушма*).

## Ипи пешерү

**Ипи башы. –** Элек күәс була торган ыйы. Әзерәк кенә қамыр қалдырабыз ипи қамырыннан, тәлинкә хәтле генә, ипи башы була. Ипи пешерергә әзерләгәндә икеме-өчме чоқыр су салып, қамырыңы әйбәтләп изеп қуйасың җылымса суға. Әзрәк тоз саласың. Қоймақ шикелле генә итеп кичтән изеп қуйасың.

**Ипи камыры басу. –** Иртә белән иртүк торып қамыр басасың да өстен җәймә белән қаплыйсың да, җылымса урынға қуйабыз. Ул қабарып менә. Иртә белән тағын әзрәк кенә су салабыз әче булмасқа. Үзләнгәнче басасың дағын ул күпереп менә әзерәк торғач.

**Ипи әwәләү.** – Ипине әwәлисең түгәрәкләп. Пумаланы суға тығып, мичеңне себереп аласың. Әзерәк күмер қалдырабыз «ипинең йөзе килсен», – дип. Бераз күмерен кечучаққа тартабыз аның.

Ипине әwәлисең түгәрәкләп, ул әзерәк қабара. Ипи көрәгенә салабыз да ипийеңе тығып қуйасың. Мич қапқачын қаплап қуйасың. Күпереп, тәмле исләр чығарып пешә инде ипи мич төбендә.

Арыш ипекәйен йорт бодай оны беләң басасың, бигерәк тәмле була инде.

**Ипине мичкә тығу.** – Әwәләп қуйғач, ипине күпчеккә саласың әле җәймә җәйеп. Ул шунда қабара йоморы ғына булып. Әзерәк тора ул қабарып. Көрәккә қуйғач, су беләң майлап, мичкә тығалар.

**Ипи қамырыннан көлчә.** – Ипи қамырыннан табаға салып көлчә пешереп алабыз, ипи пешергән сайын көлчә дә пешерәбез.

**Ипине кәбестә йафрағы өстенә салып пешерү.** – Ипине кәбестә йафырағына салып пешерәдерийе әни. Ипи көрәге өстенә кәбестә йафырағы қуйа да, шуның өстенә әwәләп ипине қуйып, пичкә тыққан. Ипи бик тәмле булып пешкән.

**Кибән башы ипи.** – Кийәү өйенә килеп төшкәндә кибән башы ипи кисеп бирәләр йегет беләң қызға. Түгәрәк ипидән қайырып кисеп бирәләр. Шуны ашап бетерергә.

**Кендек ипийе.** – Бала туғач та ипи пешерәләр бәләкәй генә итеп. Баланың кендек тирәсендә әйләндереп, хәйергә бирә торғаннар ыйы. «Кендек ипийе» дип.

**Қәдер киче ипийе.** – Қәдер киче ипийе дип пешереп қуйалар абыстайға бирергә, ураза беткәндә, ғәйет алдыннан бирәләр (*Шәмәк*).

**Бул'ки, (бәрәңге күмәче).** – Бәрәңгене пешереп төйәбез, аны әчетергә қуйабыз кичтән. Аннары қапчыққа саласың да таш беләң бастырасың. Ул бастырып қуйған бәрәңгең әчегәч, қырған бәрәңге қушып нығытып басасың да wақ-wақ итеп түгәрәкләп пичтә пешереп алабыз. Ул бик тәмле була. Он җуғында шулай итеп пешереп қунақ чақырдық. Ул қабарып пешә, бул'ки дип әйтәләр аны.

– Бәрәңге күмәче пешерәләр ийе бәрәңгене қырып. Шуны **бул'қи** дип әйтерләр ийе.

– Пешкән бәрәңгедән баш йасап қуйарлар ыйы. Ул әчи. Әчегәч шуңа тағын қырған чи бәрәңге салып басасың да үзләндереп,

қабарып менә ул. Қабарғач аннары шуны күмәч итеп пичкә тығарлар ыйы. Шуны бул'ки дип ашар ыйық, чәй эчәр ийек. Ул бик тәмле булыр ыйы.

– Бәрәңге күмәче пешерер ийек. Бәрәңгене пешереп төйә дәген әзерәк эчетергә қуйа. Чи бәрәңгене қырып қушалар дағын, табаға салып, күмәч итеп пешерәләр. Ач булғанда ул бик тәмле булыр ыйы. Шуны бул'ки дип йөрер ийек. Пешкән бәрәңгесеннән баш йасап қуйарлар ыйы әбиләр. Пешкән бәрәңге әзерәк әчи дәген шуңға қырған бәрәңге қушып, бул'ки дип пешерәләр. Булса, табаға май салып қуйарлар ыйы.

– Көз көне бәрәңге қазығанда басуда күмелеп қаладырыйы бәрәңгеләр. Ул җаз көне қазығанда черек бәрәңге булып чығадырыйы. Шул бәрәңгенең қабығын салдырып алғач, ап-ақ кырахмалы ғына калыр ыйы. Шуны төйеп, оны булса, әз генә он қушып күмәч итеп салыр ыйық табаға тезеп. Ул күмәчләрнең тәмлеген белсәң син! Без менә шуңға озақ йәшәгәнебездер инде (*Сәртек*).

**Тоқмачлы аш, қысыр аш, умачлы аш**

– Тоқмачлы аш булыр ыйы сарық ите белән. Қунақ килсә, туйларға шулай тоқмачлы аш булды.

– Умачлы аш булыр ыйы күбесенчә. Қатық қатып ашадылар умачлы ашны. Умач уғанда башта оныңны саласың, суны әз-әз тамыза-тамыза оныңны әwәләп барасың инде. Ул үзе умачлана. Ул таралыбрақ тора торған булырға тийеш инде умач.

– Қысыр аш – итсез аш була инде. Қысыр ашқа чөгендер җафырағы төйеп салабыз, қычытқан салабыз. «И-и, бер қалақ қына он булсайы», – дидек инде (*Шәмәк*).

**Сөт, май ашамлыклары**

– Балчық чүлмәктә сөт тора базда. Аның қаймағын җыйып торыр ыйық.

Ул қаймақны гөбе чиләгендә туғылап йаза торған ыйық. Май әйрәне белән қоймақ пешерер ийек.

**Тура.** – Тура ул қызарғанчы қайнатып йасалған була. Тураны аны қайсы кеше эчегән сөттән, қайсы эремчектән йасый, май сала. Тураны аны киптереп тә қуйалар, суңынтын төйәләр дә илиләр.

**Туралы май.** – Туралы май дип, тура йанына йаңа йазған майны да қуйа торғаннар ыйы.

Туралы майны қар базына қуйып торабыз, кирәк чақта ғына базға төшеп алабыз. Туралы май – қунақ сыйы инде ул. Қунақ килсә, шул туралы май була торған ыйы. «Май бәрәкәтле булсын», – диделәр микән инде аны.

**Қапламыш** – туралы май саwыты.

– Туралы майны қапламыш дигән ағач саwытқа салып қуйабыз қунақларға. Ул матур қапқачлы саwыт. Аста тура, өстән май салып қуйған булыр ыйы. Ул инде бик қәдерле қунақ сыйы булыр ыйы (*Кече Кирмән*).

## Керәшеннәр сөйләшендә халык традицияләре

### *Туй йолалары*

– Қода булып **қыз сорарға килгәндә бөтен ипи белән килгән**. Ипи белән килгән қоданы борып чығармағаннар. Жөргән жегете барын белсәләр дә, барыбер биргәннәр. «Ипи белән килгән, ипине борырға жарамый», – дигәннәр (*Юкәче*).

**Әңки** – туйда «икенче әни» итеп билгеләнеп куелган хатын-кыз. Русча посаженая мать. Аны кыйаматлық әңки дип йөртәләр.

– Қыз сорарға барғанда әңки белән баралар. Арада бер жөрүче була бит. Ипи белән баралар қыз сорарға. «Ипи белән килсәләр, кире борырға жарамый», – диләр (*Жөри*).

**Кәбен қойдыру** – өйләнешкәндә чиркәүгә барып христиан дине йолаларын үтәү. **Қыйаматлық** – туйда «икенче әни» итеп билгеләнгән кеше.

Мамадышқа барып та кәбен қойдырып қайтабыз без. Қыйаматлық була, бер жақыны инде. Алар ирле-қатынлы булалар, әткәйәнкәй булалар. Қызның башына бинис (< рус. венец) кигертә. Әнкәй булған кеше ипи белән бистәр тота, бал тота инде бәләкәй генә саwыт белән:

«Ипиле-баллы булсын», – дип.

«Ипиле-тозлы булсын», – дип тоз да қуйалар инде менә шулай иттереп.

Чәчне бер генә толым итеп үреп барған була, қыйаматлық әнкәй ике толымға айырып үреп қуйа (*Юкәче*).

**Қунак өйе, қыйаматлық өйе. –** Әwәле қызны сыразы ғына кийәү өйенә алып қайтмадылар. «Қунақ өйе» дип, бер йақын кеше-

се өйенә алып қайталар. Ул күбесенчә қыйаматлық булған кешенең өйе булды. Қыйаматлық – туйда икенче әни инде ул, кәбенгә дә қыйаматлық барды.

Қыз инде шул қунақ өйендә қоймақлар пешерде пичкә йағып.

Бийем булған кеше үзе килеп, җәш килен буласыны көн сай-ын ашқа алып чыға торған ыйы. Җәш киленне элү белән чақырып баралар ыйы. Элү инде ул җә җаулық, җә бер бистәр булды (*Кече Бөрсет*).

**Туй атлары. –** Башқа аwылдан булса атларны бизәп, қыңғы-раулар тағып, дуғасына бистәрләр элеп, шаулатып килерләр ийе (*Җөри*).

– **Сандық арбасында** қызның сандығы булыр ыйы. Аны кийәү белән қыз сатып алырлар ыйы, бүләк бирә инде сандық китерүчегә. Сандық өстендә күпчекләр булыр ыйы (*Кече Бөрсет*).

**Әйбер элү. –** Өйгә әйбер эләбез җырлый-җырлый. Без, керәшен-нәр, почмаққа элү эләбез. Тәре ашаулығы эләбез. Ул шунда, элгән урынында тузсын, диләр.

Басуларға житен чәчтем
Житеннәрем житен булсын, дип.
Бу ди әйберләрне без эләбез
Элгән жирләрендә тузсын, дип.

Қәләмперләр салдым ақмасқа,
Бадийаннар салдым батмасқа.
Бу ди әйберләрне элеп қуйдық
Берсесе дә әйләнеп қайтмасқа (*Кече Бөрсет*).

– Туй булса – олы қапқа ачық булды, тәрәзәләргә, ишекләргә килерләр ийе. Қапқа ачық торадырыйы. Бөтен урам туладырыйы халық белән, туй қарарға килүчеләр күп булыр ыйы (*Юкәче*).

– Туй киткәндә болай дип җырлыйлар ыйы:

Сулар аға арықтан,
Қодалар қарый жарықтан.
Қодалар қарый жарықтан,
Жиккән атқайлары зарыққан.

Иртәләр дә торып мин сызғырдым,
Болын печәннәре кипсен дип.

Болын печәннәре кипте инде,
Қайтыр бақытлар җитте инде.

Тагын шайан җыры да бар әле:

Ары да шыбыт булдық,
Бире дә шыбыт булдық.
Инде шөкер бер қодайға,
Қодалардан қотылдық.

Китәр алдыннан қодалар шулай җырлыйлар ыйы:

Пар атларны җиктем и җаратып,
Килгән җулларыбызға ла қаратып.
Безләр килдек сезләргә и җаратып,
Сезләр қалырсыз микән лә җаратып.

Тәрәзәләрнең өлгесен
Күтәреп қуй бер читен.
Қаршы алулары бик күңелле
Затулары бик читен.

Әнә килә афтамабил
Төйәгәннәр перәннек.
Айырылышу минутына
Менә килеп терәлдек.

Урақайлар урдым, қуйдым сослан,
Аның араларыннан җил үтмәс.
Безләр барыбыз да тату булсак,
Ич бер әдәмнәрнең лә сүзе үтмәс.

Сары атлар алдым ла сатуға
Сары майлар эчтем лә қатуға.
Безгә әдәмнәрнең исе китә
Без барыбыз шушылай татуға (*Кече Бөрсет*).

**Қода сыйлау.** – Килгән қодаларны түргә утырталар. Қара-қаршы җырлашып, хуҗа җағындагылар айақ өсте басып сыйлыйлар. Теге қодалар утырып қына торалар.

Қырақлый таwық қырақлый
Әллә қарчығалар килгәнме.
Бик йәмле таwыш ишетелә
Әллә қодаларыбыз килгәнме.

Алтын булып ағыймmы,
Көмеш булып тамыймmы.
Сез қодалар қаршысында
Шәмнәр булып җаныймmы (*Юкәче*).

**Айақ өсте торучылар** – туйда қода сыйлаучылар.

– Туйда айақ өсте торучылар жырлый-жырлый қодаларны сыйлыйлар:

Өстәл өскәйләренә ни килешә
Күтәрепкәй суққан ашаулық.
Никләр ашамыйсыз, ник эчмисез,
Сезнең өчен пешерғән ашамлық.

Өй ди түрләрендә и сатығыз
Сатығызға җибәргән атығыз.
Килгәннәрдән бирле қарап торам
Әүлийәләр икән затығыз (*Юкәче*).

Алтын балдақ, көмеш қаш,
Кирәк булса, сандық ач.
Сезнең кебек булса булыр
Сәхрәләрдә сандуғач (*Җөри*).

## Саwым

**Саwым** – туйга қодалар алып килгән күчтәнәч ашамлыклар; туйга катнашкан кешеләрнең күчтәнәч итеп алып килгән ашамлыклары.

Билләреңә йапқан алйапқычың
Нинди күчермәләрдән күчергән.
Қарағыз әле безнең қодаларға
Нинди тәмле ашлар пешергән.

Менә шушылай бер табақ тутырып саwым аппаралар ыйы туйға.

**Бәлеш, қатлама, кумушка** (көмешкә) өч литырлы саwыт белән. Менә монысы шуның саwымы, дип әйтеп чығарлар ыйы. Жырлый-жырлый чығалар ыйы өстәл қаршысына басып.

**Пирмән чығарғанда** жырлыйлар ыйы:

Эшләрем бүген шундый булды:
Пирмәннәр булды бөккәнем.

Қапқа төпләренә чыға-чыға
Сез булдығыз минем көткәнем.

**Саwым табағын** тоталар ыйы да жырлый-жырлый чығарлар ыйы:

Бийекәй тауның башларында
Жалтырапқай жата ташлары.
Безнең қодаларның ашын-суwын
Ничек тартып килгән атлары.

**Каз чығарғанда** жырлыйлар ыйы:

Қыйқақ-қыйқақ қаз қычқыра
Болыннарға төшкән қаз икән.
Болыннарға төшкән қаз булмаған,
Қодалар өчен үскән қаз булған.

Қыйқақ қына қыйқақ қаз қычқыра,
Қанат очқайлары ақ була.
Бу ди қаз итләрен ашасағыз
Безне сөйүләрегез қақ була.

Туйға килгәндә қодалар да пар қаз алып киләләр, монда да пар қаз пешерәләр. Аларның китергән қазларын берсен турыйлар ыйы, ә төп қоданың қазының берсен килгән қодаларға биреп жибәрәләр ийе (*Юкәче*).

**Тау итү** – рәхмәт әйтү, зурлау, мактау.

– Туй мәжлесе беткәндә айақ өсте басып, тау итү жырларын жырлыйлар ыйы:

Тау ашыңа, қода, тау ашыңа!
Дәүләт жаусын синең башыңа.
Бүдәнәләр кебек журғалап
Рысқалың килсен башыңа.

Қайыннарны кисеп мин аудардым,
Имәннәре қалды тирбәлеп.
Ашадық та эчтек, хөрмәт күрдек,
Өстәлләре қалсын тирбәлеп.

Ындыр артқайлары тигәнәк,
Жаңғырлар да килә сибәләп.
Ашадықай эчтек, хөрмәт күрдек,
Тау итәргә кирәк чибәрләп.

Шыбыр ғына шыбыр жаңғыр жаwа
Басқыч башларына ташларға.
Күпләр ашадық, күпләр эчтек,
Тау итийек ашаған ашларға.

Без утырған урыннарға
Сандуғачлар килеп утырсын.
Безнең ашағанны без эчкәнне
Бер қодайым үзе тутырсын.

Әткәй безгә атлар бирде,
Таудан тауға ғына чап, диде.
Кечти генә аш-су тотсағыз да
Үз туғаннарың белән қап, диде.

Әтинең жырыwы бу (*Юкәче*).

**Қода ипийе** ашау – қода күчтәнәчләре белән сыйлану.

– Аннары икенче көнне өстәл артында утыручылар да, айағ өсте йөрүчеләр дә туй үткәргән йортқа жыйылалар ыйы «қода ипийенә киләбез», – дип.

– Қодаларның ипиләрен қуйалар өстәл башына, ул ипиләр тора шунда. Икенче көнне жыйалар ыйы қода ипийе ашарға. Ике жақ та жыйыла.

– Кечти генә мал суйалармы, дуңғыз суйалармы, хәзер ашқа жыйдылар. Бөтен туғаннары белән жыйылышып, чөкердәшеп ашап утыралар ыйы.

– Икенче көнне туйдан соң ипи ашау берсе, «қода ипийе ашау була».

– Қода ипийе ике жақта да буладырыйы. Иң беренче қыз жағында буладырыйы туй, андары жегет жагында. Ике жақта да үз жағындағы туғаннарын, қодаларын, қодағыйларын чақыра (*Чиябаш*).

**Қара-қаршы жырлашу**

Урақайлар урдым мин учмалап,
Чүмәләләр қуйдым ла ниргәләп.
Әле бергә без йөрибез,
Тағында йөрсәк ийе бергәләп.

Ачып қуйдым бүлмә ишекләрен,
Бүлмәләргә қачып ла қалмасын.
Қызыбыз да әйбәт дип мақтанмағыз,
Алып килдек жегетнең лә алмасын.

Ак та Иделләр бигерәк киң,
Диңгезләрдән бер дә лә ким түгел.
Җегетебез алма, кызыбыз чийә,
Берсеннән лә берсе ким түгел.

Җиктек атның җирәнен,
Арбаларның тирәнен.
Үзебез чибәр булмасак та,
Алдык кызның чибәрен.

Идел бозлары киткәндә
Карап калабыз бозны.
Җегете безгә ошамаса,
Бирмидерийек кызны.

Тимерчеләр бара тимергә,
Күмерчеләр бара күмергә.
Безнең кызыбыз сезгә бара,
Айга-җылга түгел, гомергә.

Сикереп төшкән, гөрләп үскән
Кыр башында калган бер бодай.
Сезгә генә безне, безгә сезне
Сөйеп кушкан икән бер Ходай.

Тәрәзә төбендә ай тутый кош
Сыйпап кына сыйпап тотыгыз.
Сүзләрем дә бүләк, үзем кунак
Мине исегездә лә тотыгыз.

Җырларымы мин җырлыйым
Дусларыбыз кушканга.
Җырлыймын бу җырларымы
Эчләрем бик пошканга
(*Кече Бөрсет*).

## Борынгы киемнәр

**Баш бәйләү** – яшь киленнәр кияргә тиешле баш киемнәрен, тәңкәле бизәнү әйберләрен кию.

– Җәш киленнәр сыйырны баш бәйләми куса, «җалкау килен икән», – дигәннәр. Торган, кийенгән, башы бәйләнгән, чәчен асылындырып җөрөмәгән.

**Чигәчәләр, мәләнчекләр** куйып баш бәйләгәнләр. **Җепәк җаулығы** бар ыйы җәш киленнәрнең.

**Түгәрәк җаулык** кругум чуқлыйы. Хәзер жуғ инде алар.

Керәшен күлмәкләре кидек. Чигүле алҗапқычлар, җақалар бәйләдек, чигәчәләр, беләзекләр кидек қыччағындағыларны. Шулай чигәдә тәңкәләр буладырыйы (*Чиябаш*).

### Туганлык мөнәсәбәтенә караган сүзләр, эндәшү, мөрәҗәгать итү сүзләре

*Нәнәй* – әни,
*Тәтәй* – әти,
*Бийем* – кайнана,
*Бийата* – қайната,
*Бийағай* – иренең абыйсы,
*Җанағай* – иренең энесе,
*Җырақ әби* – энисенең әнисе,
*Җырақ бабай* – энисенең әтисе,
*Җырағай* – энисенең абыйсы.

### Нардуған

**Нардуған** – Яңа ел көннәрендә үткәрелә торған йолалар, күңел ачулар, күрәзәлек итүләр.

– Алты атна ураза була. Қыш көне 27 нуйабердә башлана, 7 йамбарда аwыз ачыла. 17 сенә қадәр ун көн нардуған була. Анда әкәмәт була, иренмәгән кеше җөри. Битен ачмыйлар. Җеннәр бит инде алар.

– Нардуған булды. Мин бик җөрмәдем. Күңелле була торған ыйы. Кем булып кийенеп чыға. Төрлечә кийенәләр.

– Ат булып чығучылар да булды. Төрлечә төрләнеп чығалар.

– Берсендә иптәш қатыным айу булып кийенде, мин чыбырқы тотып айучы булып кийендем.

– Нардуғанда мин нуғыт қараучы булып, орчық селкетеп, нуғыт қарап йөрдем (*Юкәче*).

**Бабайға чығучылар** – нардуган көннәрендә өйдән-өйгә кереп, төрлечә киенеп йөрүчеләр.

– Бабайға чығу, диләр, булыр ыйы алар бездә. Бер өйдән икенче өйгә җөриләр ийе. Бабайға чығучылар қайсы-берсе бийүче дә була. Тақмақ әйтеп бийетәләр:

Себереп сал, себереп сал,
Чәчелмәсен тарысы.
Айағыңны басып бийе,
Қарап торсын барысы.

Бийер әле, бийер әле
Җәш чағында бийегән.
Хәзер инде бийи алмый,
Падшипнигы эрегән.

Имән микән сайғағы,
Җүкә микән сайғағы.
Имән булса, бик чыдар,
Җүкә булса, шарт сынар.

Мич артында сары май
Жуқтыр аның сызығы.
Нардуғанда бийемәгәч,
Жуқтыр аның қызығы (*Юкәче*).

– Жаңа жылға қаршы, нардуғанға қаршы қул эше эшләттерми торған ыйы әни:

«Бәйрәм җитте, эшлисе түгел».

«Тәрәшле булырға ди өйдә. Тәрәшле булмаса, өй ийәсе чығып китә», – ди.

– Жаңа жылда иртә белән торғанда инде бөккәннәр пешкән була.

«Мичне буш қалдырасы түгел», – ди торғаннар ыйы.

Иске жаңа жылда да, хәзерге жаңа жылда да мичне буш қалдырмыйбыз. Қатлама булса да пешереп алабыз. Қатлама ул қечтейқечтей генә ипей була инде.

Жыл аwышқанда шулай мич әйбере пешерәләр инде (*Кече Бөрсет*).

– Балалар қайталар, пичкә жағып әйбер пешерәбез. Әле менә бүген генә тәҗел (*ашыгыч*) булды.

Пич қоймағы тәмле, дурочмақлар, өчпочмақлар пешерәбез жаңа жылда (*Юкәче*).

## Җөзөк салу, балдақ салу

– Жаңа жылға қаршы көнне җөзөк саладырыйық. Без элеке мунчада саладырыйық. Җегетләр, қызлар жыйыла. Чишмәгә суға чық-

қанда пычақ аладырыйық. Бер җегет, бер қыз чығабыз. Ул да, мин дә эндәшмибез.

Суны шушылай өч тапқыр қач сызып алабыз. Суны алып қайтып мунча ләүкәсенә қуйабыз чиләк белән. Менә шунда балдақларны салабыз. Үзенекен үзе тамғалап сала да:

И Қодай, туған-тумачаларға,
Аwыл-күршеләргә байлықлар,
Шатлықлар, сөенечләр китер, –

дип әйтеп саладырыйық. Аwыз эченнән генә қач сызабыз да аннан соң алабыз (*Чиябаш*).

**Қач ману** 19 январьда була, урычча крещение. Қач ману – Җөри белән Җүкәче авылы бәйрәме.

Без аларға қунаққа барабыз, алар безгә киләләр кышқы Микулаға.

Қач манған көнне изгеләр чишмәсеннән су алабыз.

Шул қач манған суны бөтен өй почмақларына, абзарға, ризықларға сибәм, аннарысы мунчаларға, мал өйләренә, мал өсләренә дә сибәм. Ул изге су була.

Өч көнгә хәтле Қодай мана ди. Чишмәгә төшәсең, иманнар уқыйсың, Қодайға йалбарасың. Шул чишмә суwы бозылмый, саф тора.

Элгәре зур итеп бәке ачып қойонғаннар. Қәзер инде иманнар әйтеп, су алып менәләр безнең аwылда. Элгәре бик зур бәйрәм булған ул.

Боздан қач йасап қуйғаннар матур итеп. Бәйрәм көнне хәйер бирәсең:

«Үлгәннәр өчен», – дип.

«Үзебезгә дә исән-сау йөргәнлеккә», – дип (*Чиябаш*).

## Бәрмәнчек

**Бәрмәнчек** – руслардагы «вербное воскресенье»; «песи»ле тал ботаклары.

Бәрмәнчек алып қайтабыз. Иң беренче көтү чыққанда малларны қуwабыз шул бәрмәнчек белән. Аннары абзарға қыстырып қуйабыз.

Бәрмәнчекне аны чиркәүгә алып менеп, чиркәүдә аңғар қач сулары сибәләр. Шушылай чуқлап чиркәүгә алып менәбез. Тегендә тау бар, балалар жыйып алып қайталар. Шушылай малларға суққалап алабыз:

«Исән-сау җөрегез, үрчегез,
Wақытында өйгә қайтыгыз».

Тәре бабай алдына да ҡуйабыз, абзарға да ҡыстырабыз. Ул икенче жылға тикле тора. Аннары ул бәрмәнчекне әле ҡаз өйасына да салабыз, анысын онотҡанмын әле әйтергә. Ҡаз бибиләре күп чыға, диләр, бәрмәнчек салсаҡ.

## Май чабу

**Май чабу** – масленица бәйрәме көннәрендә атларга утырып урам әйләнеп йөрү.

– Май чабуда бабайлар ат җигеп бирәләр дә җәшләр атларға утырып урамнардан әйләнәләр. Җидешәр ҡат әйләнерләр ийе. Бала-чағаны атларға утыртып чабып йөриләр ийе.

Май чабуның җырлары да бар. Хәзер менә исемдә әле.

Майларны да чапсаң, син ҡаты чап
Чана үрәчәләрен шаңғыратып.
Җырларны җырласаң, ҡаты җырла,
Җүкәче урамнарын җаңғыратып.

Җырлыйҡ әле, җырлыйҡ әле
Килешерләр микән көйебез.
Килешерләр булса көйебез
Җалан шушылай бергә җөрербез.

Җырлыйм әле җырларымны,
Сез дусларым ҡушҡанға.
Җырлыйсым килеп җырламыйм,
Җырлыйм эчем пошҡанға (*Юкәче*).

## Олы көн

**Олы көн** – пасха бәйрәме.

– Олы көнгә өйләрне жуwабыз, ишек алларын себерәбез. Бер ҡара кер дә ҡалырға тийеш түгел. Бер ҡат сығып булса да элеп киптерәбез.

– Бала-чағалар җөри олы көндә. Беренче кергән баланы мендәргә утырталар, күкәй бирәләр: «Чебиләр чыҡсын, тағын күкәй салсыннар», – дип.

Күкәйләрне кичтән манып ҡуйабыз, суған ҡабығы суwына, чөгендер суwына манабыз. Әwәлдән шулай ҡалған.

– Өй сайын кереп күкәй жыйабыз да, шул күкәйләрне таудан тәгәрәтеп уйныйдырыйыҡ (*Җөри*).

**Йафрақ бәйрәме, труйсын**

– Йафрақ бәйрәме ул труйсын була. Аны «ағач бәйрәме» дип тә әйтәбез. Ул 23 ийүнгә туры килә быйыл.

Йафрақ бәйрәменә қаршы кичтән бөтен қапқа-қоймаларға ағач қыстырабыз, җапырақ, тәрәзәләргә қыстырабыз.

Қайын ағачын чуқлап, җаулықлар таққаннар ул көнне.

Қайын ботақларын ағым суға салғаннар җырлап. Анда «қайын җырулары» җырладылар:

И қайын ул, қайын ул,
Қайын аwыл сайын ул.
Җыру бездә генә түгел,
Җыру кеше сайын ул.

Ақ қайын башлары уйылған,
Аның җапырағы қойолған.
Без җырламый кем җырласын,
Бар туғаннар бергә җыйылған.

Иртә белән урам әйләнәләр ийе җырлап. Тройсында җәнәшәтирә аwыллары килә, түгәрәк уйынға чығалар. Чатта халық гөжләп торыр ыйы.

Ағач башлары селкенә
Әкерен җилгә, даwылға.
Нинди матур қунақ қызлар
Килгән безнең аwылға.

Тройсын көнгә қаршы җапырақ сындырып тәрәзә артына қыстыралар. Җапырақ бәйрәме була ул.

Көн-таң атқан ыңғайли, уйыннан қайтқан ыңғайли җәшләр қыстырып китәләр җапырақ.

Труйсын бәйрәме – ул йафрақ бәйрәме, безнең Владимирның җәйге уйын бәйрәме, бик матур озын көй җырлыйбыз түгәрәк уйында. Ике қатлы түгәрәк уйыннар буладырыйы.

Җырла-җырла, диб әйтәсез,
Сезгә нинди җыр кирәк?
Сезнең алда җырлар өчен
Сандугач теле кирәк.

Ақ қайынның йәмнәре
Йафрақ белән, туз белән.

Җәйге уйыннарның эйәмнәре
Қулларыннан тотқан қыз белән.

Җаулық белән бәйләп қуйдым
Сибелгән чәчләремне.
Ай күтәрә, җолдыз баса
Түгелгән йәшләремне (*Кече Бөрсет*).

**Җир җаралған көн**

– Йафрақ бәйрәменең икенче көне – «җир җаралған көн» дип әйтелә, «хәтәр көн» дип.

– Җир җаралған көнне җалғыш җиргә қағылырға да җарамый, җиргә қатырақ басарға да җарамый:

«Үлем-җитем күп була», – дигәннәр. Басу қапқасын җабып қуйғаннар, чығармағаннар (*Юкәче*).

**Питрау**

– Питрау була ийүлнең 12 сендә. Уйынға чығабыз, гел җырлап әйләнәбез.

– «Озын уйын» диләр ийе Питырауда. Түгәрәк уйныйлар ыйы. Керәшен аwылын җаратып, күрше-тирә аwыллардан да җыйылып киләләр ийе. Питырау җыруларын барыбыз да беләбез.

Ағыйдел суwы ай тирәндер,
Тирән дә җирләре билдәндер.
Җыру башлаулары ай бездәндер,
Күтәреп алулар сездәндер.

Қунақ қызлар күп киләдерийе. Җегетләр қунақ қызларына қызығалар инде, бийергә чақыралар, әйләнергә.

Җегетләргә җырлар ыйық:

Менә җитте питыраулар
Қунақ қызлар алырсыз.
Қунақ қызларығыз киткәч,
Барыбер безгә қалырсыз.

Итәк очлары дулқыннанып торор ыйы, қызларның киндер күлмәк, киндер алйапқыч. Кич белән уйынныққа чығаралар ыйы да таң атқанда ғына таралыр ыйы.

Питраудан соң уйынға чығарға қушмыйлар ыйы. Эш күп, эш қаты булды. Печән чабасы, җыйасы, кибән куйасы. Печән өсте эшләре килеп җиткән булды.

– Питырауға қаршы көнне себерке бәйләргә кирәк. Қайын себеркесен бөтнекләр, қычытқаннар тығып бәйлибез. Аның исе эссе суға тыққач бик тәмне булып чыға, чабынып туймыйсың мунчада.

– Питырау көнне мәтерүшкәләр җыйабыз. Ағач башларын сындырып җыйып җөриләр. Даруға җарый ул. Питырауға тикле үләннәрнең файдасы җафыракта була, питыраудан суң тамырға күчә, диләр. Питыраудан суң үлән тамыры файдалы (*Юкәче*).

## Қорман

Безнең Владимир аwылында өч төрле қорман йасыйлар ыйы. Қорманда бөтен аwыл қатнаша анда.

**Боламық қорманы.** – Боламық қорманында боламық пешереп, Ходайдан йаңғыр сорап, суға боламық салалар.

«Җир анасы, су анасы», – дип теләп салалар. Элеке белә торған қарчықлар бар ыйы.

Боламық қорманында он белән, күкәй белән боламық пешерәләр, суға да салалар.

**Таwык қорманы.** – Таwық қорманы менә монда, бу тықырық қырыйында ғына буладырыйы. Кем таwық бирә, кем күкәй. Таwықны пешерәләр, күкәйне әрчи.

«Су анасына ризық булсын», – дип суға да салалар.

Шул пешергән ботқаны да салалар. Ходайдан теләп. «Йаңғырларыңны бир», – дип.

**Бәрән қорманы.** – Бийек тауда була бәрән қорманы. Шунда бик шәп аға торған шишмә бар, бәрән суйып ботқа пешерәләр.

Белгән иманнарны әйтеп, итен, ботқасын җиргә дә күмеп қуйалар, җирне қазып. «Җир аналары, әрбер мәндәнә булсын», – дип.

Қорман көнне ару кийенеп бaралар. Болай ғына чығып китү түгел.

Шунда инде шишмәдән су алып, талдан бәрмәчтеки алып, кешеләргә шуның белән су бөркеп җөриләр.

Адарына қайсы кеше қорманға бәрән бирергә. Шуны бирә, тау башында суйып пешерәләр, бәрмәчтеки белән су сибешәләр (*Кече Бөрсет*).

МӘГЪЛҮМАТ БИРҮЧЕЛӘР ИСЕМЛЕГЕ

**Владимир:** Долгова Нина (1938 елгы)
Кириллова Матрена (1937 елгы)
Малов Иван (77 яшьтә)
Малова Мария (74 яшьтә)
Сафурина Екатерина

**Дусай:** Минһаҗева Миңненур (1935 елгы)

**Җөри:** Ефремова Мария (80 яшьтә)
Кузнецов Владимир (1971 елгы)
Мансурова Анастасья (78 яшьтә)
Павлова Анастасья (78 яшьтә)

**Кече Кирмән**: Гайфуллина Нурзидә (1941 елгы)
Исмәгыйлова Миңнур (78 яшьтә)
Миңнеханова Роза (1932 елгы)
Сафина Гамилә (82 яшьтә)
Шакирова Зәйнәп (102 яшьтә)
Шаһиева Гандәлиф (86 яшьтә)
Шәмсетдинова Гамилә (71 яшьтә)
Шәмсетдинова Фагыйлә (77 яшьтә)

**Кече Сон:** Габделханова Зөлхәбирә (1938 елгы)
Галиуллина Миңнура (80 яшьтә)
Сабитова Миңнегалләм (80 яшьтә)
Фәттахова Нурзидә (1927 елгы)

**Күкчишмә**: Вәлиева Наҗия (1930 елгы)

**Олыяз:** Әгъләмова Хашыйга (85 яшьтә)
Әгъләмова Язилә (1963 елгы)
Газизова Һаҗәр (1932 елгы)
Заһидуллина Мәдинә (78 яшьтә)
Хуҗаҗанова Һаҗәр (78 яшьтә)

**Сәртек:** Зарипова Кәримә (90 яшьтә)
Зарипова Нәрихә (1925 елгы)
Нигъмәтова Сөембикә (1937 елгы)
Сәлимова Сания
Фәйзуллина Әлфия (85 яшьтә)

**Тулбай:** Гайфетдинов Мөхәммәтхарис (78 яшьтә)
Гайфетдинова Зилә (78 яшьтә)

**Түбән Сон**: Гобәйдуллина Әминә
Сафина Вәрәкыя
Сафиуллина Рәсимә (1944 елгы)
Хәбибуллина Таңбикә (1928 елгы)

**Түбән Тәкәнеш:** Динмөхәмматова Мәчтүрә (84 яшьтә)
Динмөхәмматова Рауза (77 яшьтә)
Муталингова Бибинур (79 яшьтә)
Фатыйхова Мәскүрә (74 яшьтә)
Һадиева Өммениса (97 яшьтә)

**Түбән Ушма**: Абдуллина Гөлсинә
Фәхретдинов Илнар
Фәхретдинова Резеда
Шакиров Фәрит
Шакирова Зәйтүнә

**Түбән Яке:** Вәлиева Оркыя (1930 елгы)
Гасыймова Асылбикә (81 яшьтә)
Исхакова Хәдичә (1933 елгы)
Муллахметова Миңнегаләм (80 яшьтә)
Насыйбуллина Сания (95 яшьтә)
Шаһвәлиева Нажия (1933 елгы)
Яппарова Ситдига (1929 елгы)

**Урта Кирмән**: Галимәрданов Фаяз (1937 елгы)
Галимәрдәнова Гөлҗиһан (1932 елгы)
Хәсәнова Рәшидә (78 яшьтә)

**Урта Сон:** Галиева Гамбәр (1926 елгы)
Садыйкова Гамилә (88 яшьтә)

**Үсәли (Өчиле):** Галиева Минниса
Газизова Дания (52 яшьтә)

**Хәсәнша:** Гасыймова Мәрьям
Касыймова Рәйсә (1924 елгы)
Мөбәракшина Факиһә (82 яшьтә)

**Чиябаш (Никифорово):** Гарьянова Евдокия
Иванова Мария (1936 елгы)
Казакова Татьяна (73 яшьтә)
Максимова Мария (1937 елгы)
Спиридонова Валентина (1944 елгы)
Степанова Федосья (74 яшьтә)
Федотова Федосья( 83 яшьтә)

**Шәдче:** Вәлиев Илдар
Җамалиева Наилә
Мирзаянова Маһинур (88 яшьтә)
Нуриева Зәлимә (77 яшьтә)

**Шәмәк:** Әгъләмҗанова Мәсфүрә (84 яшьтә)
Газизова Зәкия(1925 елгы)
Галимуллина Нурдия (1935 елгы)
Фәйзетдинова Фәүзия (1925 елгы)
Шәвәлиева Нажия (80 яшьтә)

**Югары Кыерлы**: Әхәтова Галимә (81 яшьтә)
Вәгыйзова Миңнегөл
Гарипова Миңнеһаҗәр (75 яшьтә)
Исмәгыйлова Әнисә (50 яшьтә)
Фәрхуллина Нурфай (79 яшьтә)

**Юкәче:** Анисифирова Анна (82 яшьтә)
Васильева Татьяна (76 яшьтә)
Лукина Анастасия(1947 елгы)
Николаева Елизавета (76 яшьтә)
Николаева Зоя (36 яшьтә)
Петрова Мария (1951 елгы)
Семенова Мария (75 яшьтә)
Такарликова Елизавета(1940 елгы)
Филиппова Мария (87 яшьтә)
Федорова Анастасья (86 яшьтә)

**Ямаш:** Шәехова Хәерниса (1928 елгы)

## МАМАДЫШ СӨЙЛӘШЕ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Алина Хөсәенова*

Фонетик яктан мамадыш сөйләшендә авазлар ясалышы һәм составы әдәби телдән аерылмый. Шулай да кайбер үзенчәлекләр күзәтелә. Бу хезмәттә шуларның кайберләренә аерым тукталу максаты куелды. Сузыкларда ***а*** авазына иренләшү хас*: Сугыштан җа*$^{o}$*ра*$^{o}$*ланып кайтты дагын, ба*$^{o}$*ла*$^{o}$*лы иде, қа*$^{o}$*ла*$^{o}$*да эшләде* һ.б.

Мамадыш сөйләшендә еш очрый торган авазлар тәңгәллеге күренешләреннән түбәндәгеләргә игътибар итәргә мөмкин. Мәсәлән, әдәби ***э*** урынына ***и*** авазы: *ирэн* – эрен, *инә* – энә. Кайбер сүзләрдә әдәби ***и*** авазына ***ә*** сузыгы тәңгәл килә: *бәк* – бик, *әнәй* – әни. Киресенчә, әдәби телдәге ***ә*** урынына ***и*** авазы кулланыла: *чинечке* – чәнечке, *пирәмәч* – пәрәмәч. Билгеле бер төркем сүзләрдә ***о ~ у, ө ~ ү, у ~ ы*** авазларының тәңгәллеге дә күзәтелә**:** *аннан суң* – аннан соң, *үмә* – өмә, *былды* – булды. Кайбер сүзләрдә киң әйтелешле ***а*** сузыгы әдәби ***у*** авазына тәңгәл килә: *алабата* – алабута. Әдәби ***ы*** вазы урынына ***и*** сузыгы әйтелә**:** *сиер* – сыер.

Тартык авазларның әйтелеше ягыннан өйрәнелгән сөйләшләр әдәби телдән аерылмый. Сөйләшкә хас булган диалекталь үзенчәлекләр төрле аваз тәңгеллекләрендә һәм башка фонетик күренешләрдә чагылыш тапкан.

Ике сузык арасындагы ***д*** авазы урынына мамадыш сөйләшендә **з** тартыгы кулланыла: *назан* – надан. Киресенчә, әдәби телдәге **з** авазына сөйләштә интердентал ***d*** авазы туры килә: *кad* – каз, *bed* – без, *dаман* – заман.

Мамадыш сөйләшенең үзәнчелеге булып әдәби телдәге ***ч*** авазына ***с*** авазы тәңгәл килүне дә күрсәтергә кирәк: *силәк* – чиләк,

*күмәс* – күмәч, *ас* – ач, *кескенә* – кечкенә, *ҡочтырып* –кыстырып, *баҡрас* – диал. бакрач – аш чүмече.

Мамадыш сөйләшендә ***ч ~ ш*** тәңгәллеге очраклары күзәтелә. Бу тәңгәллек ике күренештә чагылыш таба. Әдәби телдәге тел очы ***ч*** тартык авазы урынына ***ш*** авазы әйтелә: *шишмә* – чишмә, *шыршы* – чыршы, һәм, киресенчә, кайбер сүзләрдә әдәби ***ш*** авазы урынына ***ч*** тартыгы кулланыла: *чеченеп үләләр* – шешенеп үләләр.

Аерым сүзләрдә генә күзәтелә торган тәңгәллекләр: ***з~н:*** *намана* – замана; ***р~л:*** *пирмән* – пилмән; ***т~ч:*** *тишмә* – чишмә; **б~м:** *босо* – монысы; ***х~ҡ:*** *ҡатын* – хатын.

Рус алынмаларындагы тартык авазларның түбәндәге үзенчәлекле тәңгәллекләрен күрсәтеп була.

а) татар теленең башка сөйләшләрендәге кебек үк, мамадыш сөйләшендә дә әдәби ирен-теш ***в*** авазы урынына ирен-ирен ***б*** яки ***w*** тартыгы әйтелә: *бичер* – вечер, *абария* – авария, *бербавать итеп* – вербовать, *силсәwит* – сельсовет;

б) иҗек яки сүз азагындагы позициядә ирен-теш ***в*** авазына ирен-ирен ***п*** саңгырау тартыгы туры килә: *гүпчи* – вовсе, *сәпсим* – совсем һ.б.

Мамадыш сөйләшендә ассимиляциянең түбәндәге очраклары бар.

Кайбер сүзләрдә сүз башындагы позициядә килгән ***с, ч*** авазлары ***ш*** тартыгына охшашлана: *шыршы* – чыршы, *шишәмбе* – сишәмбе, *шуғыш* – сугыш.

Бер төркем сүзләрдә тел очы **с** тартыгы үзеннән соң килгән ***ч*** **а**вазына тулысынча охшашлана: *чөйөнче* – сөенче, *бачҡыч* – баскыч. Алынмаларда да шулай ук ***с*** авазының тулы ассимиляциясе урын алып тора: *чичла* – число, *чичталык* – чисталык.

Түбәндәге үрнәкләрдә диссимиляция процессын күзәтеп була: *тишмә* – чишмә, *тушы* – шушы, *пирмән* – пилмән.

Кайбер сүзләрдә түбәндәге тартыклар төшеп кала: *муча* – мун̲ча, *агус* – ав̲густ, *йалында* – өйалд̲ында.

Аерым сүзләр, сүзтезмәләр, кыскарып, үзенчәлекле яңгырыйлар: *аппарды* – алып барды, *апкил* – алып кил.

Татар теленә гарәп-фарсы сүзләре белән кергән ят аваз булганга күрә, ***һ*** авазы күпчелек сөйләшләрдә әйтелми.

Метатеза (янәшә яки арадаш торган авазларның урынын алышу) күренеше түбәндәге мисалларда күзәтелә: *җерегменче* – егерменче, *күгәлә* – күләгә, *күсәртү* – күрсәтү.

## Грамматик үзенчәлекләр

Мамадыш сөйләшендә очрый торган кайбер морфологик үзенчәлекләрне карап китик. Икеләтелгән тартым кушымчасын ялгау аеруча алмашлыкларда, тагын *бер, каршы* сүзләрендә күзәтелә: *ансысы* – анысы, *босысы* – бусы, *берсесе* – берсе.

Ел фасылларын белдерә торган сүзләрдән *-лый*/*-ли(й)* кушымчалары ярдәмендә дәвамлы вакыт рәвешләр ясала: *Қышлый* (кыш буе) *балаларда, қалада торам, җәйли* (җәй буе) *мона тушы өйдә торам инде.*

Нәтиҗәле үткән заман хикәя фигыльләрнең *-ған*/ *-гән* кушымчалы формаларына зат кушымчалары урынына тартым кушымчалары ялгану мамадыш сөйләшенең үзенчәлекле билгеләреннән берсе булып тора: *килгәнем* (килгәнмен), *килгәнең* (килгәнсең), *килгәнебез* (килгәнбез), *килгәнегез* (килгәнсез); *алганым* (алганмын), *алганың* (алгансың), *алганыбыз* (алганбыз), *алганыгыз* (алгансыз).

Тамырлары ***-р*** сонорына беткән хикәя фигыльләрнең киләчәк заман 1 нче зат берлек сан формасы тулы һәм кыска вариантларда кулланыла: *Барсысын да сөйләрем* (сөйләрмен), *гөлкәйем.*

Мамадыш сөйләшендә йөкләтү юнәлешенең ясалышында *-ғыр*/ *-гер, -қыр*/*-кер* (урта диалекттагыча), *-гыз*/*-гез* (мишәр сөйләшләрендәге кебек) вариантлары күзәтелә: *Туйларны хәдер ничек үткәзми* (үткәрми) *калым инде. Бутыйларын кигерәм* (кидерәм), *жәлли ийем шул.*

Өйрәнелгән сөйләшкә хас иркәләп эндәшү сүзләре түбәндәгеләр: *Белмим, ник,* ***кәкәм****, қартайғач шулай буласың,* ***кәкәм,*** *әйе. Күргән нужамны йаздырам инде,* ***гөлкәйләрем.*** *Эй,* ***малақай****, ул даманнарны әйтеп бетәрлек түгел.*

## Лексик үзенчәлекләр

Тупланган материаллар күрсәткәнчә, күпчелек казан арты сөйләшләре кебек үк, мамадыш сөйләшенә хас лексик-семантик система да татар әдәби теленең сүзлек фондына бик якын. Шулай да өйрәнелгән сөйләшнең кайбер аерымлыклары бар. Табылган диалекталь сүзләр тормыш-көнкүрешнең төрле өлкәләренә карыйлар.

*Туганлык атамалары: хәмдәш* – туган-тумачалар, *әнәй* – әни, *әтәй, тәтәй* – әти, *түти*/*түтәй* – апа, *апай* – апа, *нәнәй* – дәү әни, *сандай* – абый, *дәдәй* – абый, *апый дәдәй* – олы абый, *кечте дәдәй* –

бәләкәй абый, *бием* – каенана, *биатай* – каената, *биагай* – иренең абыйсы, *печкәчә* – иренең сеңлесе, *балдыс* – иренең сеңлесе, *җанагай* – иренең энесе.

Мамадыш сөйләшендә ***кешене тасвирлый торган сүзләрдә*** дә кайбер аерымлыклар күзәтелә: *титақ-митақ* – аксак, *лаек-лаек* – исерек, *исәйү* – үсеп китү, *шайтан чабу* – йөгерү, *барлы-көрле* – бай тормышлы, *мәтелде* – русча: упал замертво, *бака шарты* – рак.

***Йорт-җир, хуҗалык атамалары:*** *сәке* – кече бүлмә, *сайрақ* – идән, *қойма* – кәртә, *почмақ* – кухня, *түр як* – зал, *шашофка* – чана, *танарақ* – улак, *каралты қура* – йорт биналары бергә, *чоқыр* – чынаяк, *тапчан* – сәке, *палуторка* – тонна ярым тутырырлык машина, *сослан* – 11–13ләп көлтәдән өелгән чүмәлә төре, *шөлдер* – бәләкәй кыңгырау, *чабағыш* – борчак суга торган таяк, *стан* – станок, *ултар* – абзар алдындагы малны бүлеп чыгара торган урын, *өй түре* – бакча, *сөлән* – чылбыр, *ақ өй/ал өй* – өйдә өлкәннәр, ата-аналар тора торган як, *артқы өй* – яшьләр тора торган як, *уша* – урындык, *чөм* – утырта торган бәрәңге күзе, *бөстәр* – тастымал, *тәпән* – савыт-саба, *бақрас* – половник, *тузтаған* – стакан, *сөйем* – баш бармак белән имән бармак аралыгындагы үлчәү берәмлеге, *грәбәнкә* – 200 гр, *қадақ* – 400 гр, *пулян* – ярган утын, *тәләкә* – капканың биге, *су кисмәге* – канистра, *япон тактасы* – синтезатор, *сила* – авыл, *иске қурпы* – былтыргы печән, *пристинка* – ашханә, *рәмә* – тәрәзә.

***Кием-салым атамалары:*** *башмақ* – йон оек, *букча* – чүпрәктән тегелгән портфель, *тулға оек* – йон оек, *кун калуш* – ботинка, *бутый* – резин итек, *қаптырмалы бутый* – кыска кунычлы итек.

***Аш-су атамалары:*** *тура* – кызыл эремчек, *беләк* – икмәкнең башы, *қоры сары қоймақ* – мичтә пешерелә торган коймак, *шәлпәк, чәй тукмачы* – чәк-чәк, *чебрик* – пәрәмәч.

***Терек һәм терек булмаган табигать атамалары:*** *дусай печән* – какы, *қаз печәннәре* – каз ашый торган үлән, *сәрдә* – ашый торган печән, *бақа* – ракушка, *чики* – чикләвек, *әкәли* – имән чикләвеге, *марҗа алқасы* – бүре җиләге, *бәти* – бәрән.

Китерелгән материаллар Мамадыш районындагы татар сөйләшләренең лексик-семантик системасының бай һәм кызыклы булуы турында сөйли. Өйрәнелгән сөйләш татар теле диалектлар системасында мөстәкыйль урын алган, татар теле тарихы, диалектология фәне өчен әһәмиятле сөйләш булып тора. Мамадыш

сөйләшенә түбәндәге локаль үзенчәлекләр хас: фонетик вариантлар (*сайраҡ* – идән, *баҡрас* – половник), мәгънә күчешләре (*сәке* – кече бүлмә, *почмаҡ* – кухня, *чоҡыр* – чынаяк, *башмаҡ* – йон оек), әлегә теркәлмәгән диалектизмнар (*хәмдәш* – туган-тумачалар, *мәтелде* – русча: упал замертво, *баҡа шарты* – рак, *ултар* – абзар алдындагы бүлеп чыгара торган урын, *сөлән* – чылбыр, *чөм* – утырта торган бәрәңге күзе). Шулай ук экспедиция барышында үзенчәлекле ай исемнәре теркәлде: *Дәлү* – гыйнвар, *хут* – февраль, *хәмәл* – март, *сәүвәр* – апрель, *мидан* –август, *ширбахөрбан* – июнь, *әрбәге бинҗегеән* – сентябрь, *токрау* –октябрь, *зәкти* – ноябрь, *кауыш* – декабрь (сөйләүче: Мәхдүмә әби, 1923 елгы. Урта Кирмән авылы).

Мамадыш сөйләше әдәби телгә якын булган сөйләшләрнең берсе. Шулай да аның үзенә генә хас фонетик, лексик, грамматик үзенчәлекләр системасы формалашкан. Тарихи чыганаклардан күренгәнчә, мамадыш сөйләше күпчелек башка төбәкләргә (бәрәңге, каргалы, стәрлетамак һ.б. сөйләшләргә) чыганак сөйләш булып тора. Өйрәнелгән территориядән күчеп китүчеләр нигезендә формалашкан сөйләшләрдә (мәсәлән, Оренбург өлкәсенең каргалы, богырыслан, өлешчә шарлык сөйләшләрендә) мамадыш сөйләше үзенчәлекләре саклана. Шуларның берсе – *анысы, монысы, кайсы, шунысы* алмашлыкларында 3 нче зат берлек санда икеләтелгән тартым кушымчалары ялгану (*ҡайсысы, шунсысын), -дагын/ -тагын* һ.б.

Мамадыш якларында яшәүче татарлар үзләренең кунакчыл, ачык күңелле булулары белән аерылып торалар. Рухи байлыкларын, күркәм йолаларын саклап калып, яшьләргә тапшырып яшәргә омтылалар. Түбәндәге сөйләм үрнәкләрендә мамадыш татарларының борынгыдан килеп, бүгенге көнгә берникадәр үзгәрешләр кичергән, матур сөйләм чагылыш тапкан.

## Авыллар тарихы

Бу аwыл, урман аша Ҡомазан аwылындан чыҡҡан. Иван Ғрозный wаҡытында, чуҡындырғанда, унҗиде семйа, чуҡындырудан ҡачып, шушы урманға ҡачҡан. Аларны тапмағаннар. Шушы урманда, Шийа йылғасы буйында, өйләр салып утырғаннар. Алар анда үз эчләрендә генә ҡайнағаннар, бер ҡызны читкә бирмәгәннәр, бер җегетне читтән алмағаннар. Соңыннан читкә бирә башлағаннар.

Тора торғач зур аwыл барлыққа килғән. Бер заман бик зур ташу булған йаз көнне, су басқан. Олы йаз исеме шуннан қалған. Шуннан әкрен-әкрен монда күчкәннәр.

*Сөйләүче: Хәбибуллина Әлфия*
*Хәйретдин кызы (1934 елгы).*
*Олыяз авылы*

Ɗир (*җир*) булмаған Олы Кирмәндә (*авыл исеме*). Мында элек урман булған, урман эчендә шишмә булған. Шул шишмә буена утырырға булғаннар Кирмәннән килғән кешеләр. Хасанша исемле кеше, организапать итеп, туған кешеләрен җыеп алып килгән, пуҗымнарны (йорт урыны) шыбаға сикертеп утыртқаннар. Бер қарчық Фахырниса исемле, Кирмән башында җафаландым, шишмә йырақ булып, менә шушы шишмә қырында утыру әйбәт булыр, дигән. Хәсәнша исемне кеше, гел туғаннар қилгән, өчешәр, өчешәр. Ничә ел қуақ төпләп йәшәделәр, мин малатилкада эшләгәндә дә әле, бөтөн төпләрне қартлар утынға җағып беттеләр.1929 нчы йылны нигез салынған безнең аwыл. Мәчет қырында Хәсәнша дигән қешенең пуҗымы, ул хәɗер йуқ инде.

*Сөйләүче: Мөбарәкшина Факиһа*
*Сәхәбетдин қызы (1930 елгы).*
*Хәсәнша авылы*

## Йолалар турында

Элек туй ул, киленне күрсәтмиләр ийе. Кийәү йағыннан ақча түләсәләр генә күрсәтәләр иде. Туйға төп қодалар пар ипи, пар қаз алып барғаннар. Өйғә кергәндә килен әйбер элеп керергә тиеш иде.

*Сөйләүче: Иванова Татьяна*
*Яфимовна (1931 елгы).*
*Түбән Тәкәнеш авылы*

Йаңғыр йаумаса, су буенда олы қазан белән һәрбер кешедән бәрәңғеме, йармамы җыеп берәр кеше пешерә иде, шуны қашықлап ашыйдыр идек. Аннан бер-беребезгә, бастырышып, су сибә идек. Берсе дә үпкәләми иде.

*Сөйләүче: Садриева Фәхрибанат*
*Захетдин кызы (1931 елгы).*
*Шәмәк авылы*

Нуранийаләргә аулақ өйгә йөри идек. Туқмач кисә белмибез, үзенчә кисә идек. Күкәй пешерә белми идек, әнәй самавырға салып пешерә торған иде. Урлап күкәй, май, бәрәнге алып керә идек аулаққа. Әнәйнең қотылоқта (рус. *котелок*) майы бар иде, шуны урлап апчықтым, дус булам, дип.

Мона шушы өй төшендә (*өй урынында*) рамазан аенда бабайлар уқыйлар иде. Әнәй безгә қоймақлар, төшләр пешереп бирер иде. Ниқахлар уқыйлар иде, муллаға әйтеп уқыталар иде.

*Сөйләүчеләр: Газизова Сария (1930 елгы),*
*Җәләева Суфия (1943 елгы).*
*Олыяз авылы*

Җегетләр армийәгә китәсе булса, қызлар иң туқ чикләвекләрне қапчыққа тутырып, җегетенә биреп озата торған иде. Урам буйлап атта шөлдерләр (көмеш бәләкәй кыңгырау) тағып, гармун уйнап үтәләр иде.

Аулақ өйләр була иде, мин биштә уқығанда, кертмәгән җегетләр, үч итеп, бу қызның өй алдын сүткәннәр. Йөрегән җегетләр шулардан уқ жыйдыртып, туқмақлап қайтарып җибергәннәр. Йазалы уйный идеқ. Олы йақта (*залда*) уйныйдыр идек.

*Сөйләүче: Хәбибуллина Әлфия*
*Хәйретдин кызы (1934 елгы).*
*Олыяз авылы*

## Өмәләр турында

Қаз өмәләре була торған иде. Қазларны йолқығаннан соң силәкләр тотып чишмәләргә бара идеқ. Жырлар жырлап, ғармун уйнап төшә идек – бәк күңелле булған иде.

*Сөйләүче: Гомәрова Закирә*
*Галимулла кызы (1935 елгы).*
*Уразбахты авылы*

Тула өмәсе – эрләгән йоннынан, серле беләк белән тәгәрәткәннәр, сәкегә утырып. Шуннан егетләр белән қызлар елғаға тула йуарға төшеп китәләр иде. Соңыннан бәлешләр пешереп матур итеп үтә иде.

*Сөйләүче: Сәхәпова Әлфия (1933 елгы),*
*Гыйльмиева Гандәльшә (1946 елгы).*
*Өчиле (Үсәли) авылы*

Қаз өмәсенә, җон өмәсенә йөри идеқ. Иртәнге уннардан төнге умберләргә қәдәр утыра идеқ. Дрәгә җөретәләр иде мени мине. Шуңа җоретәләр иде.

Җырлый-җырлый җоннар эрлик,
Монда өмә, дисеннәр.
Боларда өмә икән, дип күршеләр дә керсеннәр.
Җырлый-җырлый җоннар эрлик,
Орчығыбыз тулғанчы.
Орчықларыбыз тулғанчы
Хуҗа күңле булғанчы.
Ақ айлапқычлар тектердек инде қарасы тулды,
Безнең йашьле ғүмеребез шулай «рәхәттә» узды.
Урта Кирмән колхозында қаз өмәсе, дигәннәр,
Өмә қарап қайтыйқ, диеп Қазаннар да килгәннәр.

*Сөйләүче: Бибинур Мәгъзүмова (1930 елгы).*
*Урта Кирмән авылы*

Қаз өмәләре була торған иде. Җыйылалар қызлар, җегетләре йөриләр иде тирәләрендә, қызлар қазларны йолқалар, су буена төшәләр иде көйантә белән. Кичкә бәлешләр пешерәләр, чәй эчәләр иде. Кичке уйынға җегетләре киләләр иде. Қанат сыдыру өмәсе дә була иде.

*Сөйләүче: Хәбибуллина Әлфия*
*Хәйретдин кызы (1934 елгы).*
*Олыяз авылы*

## Уеннар турында

Йарты ерлы уйын – парлап бер егет, бер қыз утыра иде дә дағын, торып баса дағын икенче пар қырына барып йырның йартысын әйтә, белмәсәләр – урын бирәләр, белсәләр, икенче кешегә китәсең инде. Көлдөргеч – кем оста шул көлдереп әйләнеп чыға, қем қөлми – шул утрып қала, қем қөлә – шуңа җаза бирәләр иде.

*Сөйләүче: Гомәрова Закира*
*Галимулла кызы (1935 елгы).*
*Уразбахты авылы*

Әwәлғе инде йазалар бит, элек тормыш барыбер күңелле иде. Кичке уеннар була иде: тау битендә, ындыр артында. Уйыннарда йаза бирәләр иде. Чебен уйыны, сыдықлы уены уйный идек.

*Сөйләүче: Хәбибуллин Хөснулла*
*Кәримулла улы (1934 елгы).*
*Өчиле (Үсәли) авылы*

Клубта постойалый двор уйный идек – тезелешеп утырадыр идек тә, «кердем сарайға, алдым җөгән, дилбегә, чыбырқы». Әйләнми қалсаң, җаза бирәләр.

*Сөйләүче: Филиппова Мария Васильевна (1926 елгы). Юкәче авылы*

Минем белән қычкырыбрақ сөйләшегез, айу баласы басып киткән. Җиде йәшемдә суғыш башланды. Тәпәнне (*сызыклы,* рус. *классики*), қачышлы уйный идек. Буқча чүпрәктән асып, басуға борчаққа бара идек. Суғышқа атлар, машиналар, полуторкаларны (тонна йарым төи торған машина) алып киттеләрэ. Әниләр қар жырып урақ уралар иде, 11–13 көлтәдән сослан қуйалар иде. Қыш көнне, чанада тавық тизәге җыйа идек.

*Сөйләүче: Хәбибуллина Әлфия Хәйретдин кызы (1934 елгы). Олыяз авылы.*

**Тормыш-көнкүреш турында**

Суғыш wақытларында рәт йақлары шундый ғына булды инде. Уйлап утырамдағын. Үзем чытлығырак булдым. Җеғерме йыл колхузда эшләдем. Мин тәвәкелләдем дә, 1972 елдан 1992 елларны пучтада эшләдем. Самай аwыррақ елларны сабан туйы булмыйча да қала иде. Йаз көнне Ленин бабай өмәсе була иде.

*Сөйләүче: Гомәрова Закирә Галимулла кызы (1935 елгы). Уразбахты авылы*

Әни 5 баланы үстереп, эме, тормыш итеп үстерде. Черек бәрәнге ашатып үстерде. Иғезәкләр бар иде безнем, алар ач, урамға чығып сазлар ашыйлар иде. Бәк аwыр тормышта йәшәдек. Тормышқа чыққач, иптәшем әйбәт булды. Каd өмәсендә таныштық. Қайнаналарым, қайнаталарым бәк йаwыз булдылар, өйдән қуып чығардылар. Шул хәдәр әйбәт киленем.

*Сөйләүче: Мөхтәсимова Таһирә Нахизулла кызы (1938 елгы), Уразбахты авылы*

Минем җәшем җитмәгән ул wакытта. Ике игезәк қызларыбыз бар иде. Җыл башында тудым. Мин шалаван (шук) идем. Шулай итеп өч ай җөредек без иптәшем белән. 60 ел торабыз инде. Киленнәр, җенәчәйләр бар әле. Җәшел қычытқан ашый идек. Бәк тилмермәдем инде. Күрғән нужамны йаздырам инде.

Ике чананы, қушып, берғә тарта 4 қатын, симена ташыдық көз көнне, йаз көнне күтәреп ташыдық. Эшләмәсәң, ачқа чәченеп үләләр иде.

*Сөйләүче: Муллахмәтова Факия*
*Мөбарәкша кызы (1931 елгы).*
*Түбән Яке авылы*

Син үмкәләдеңме миңа? Без бер-беребезне аңышмадық. Мин теге пьйанчукны қарап чығарға идем. Мичне җағып җибәргән, чүпчапрақны җыеп йаққан.

*Сөйләүчеләр: Сәхәпова Әлфия Шәйхетдин кызы (1933 елгы),*
*Гыйльмиева Гәндәльшә (1946 елгы).*
*Өчиле (Үсәли) авылы*

Мин зағыф мужик тәрбийәләдем, тумыштан суқыр. Бәк оста байанист иде. Мин көтү көтә идем. Мин эшләдем, титақ-митақ булсам да, тик тормадым. Комаровкадан мин, еғермешәр сотка урақ урдым мин. Сигез йәштән урақ урдым. Урындық башыннан килеп төштем, тез қапкачы йуқ минем. Әниләр үлғәч, мин монда қунаққа килдем дә қалдым, әлеғә қадәр йәшим, бер қызым бар.

Мин тормышка қырықта ғына чықтым. Күп җеғетләр арттан йөределәр, трантаслар белән киләләр иде, сау кешеғә чығасым килмәде. Мин бәк оста, бәк әшәке идем.

Бичерлар була иде, биеми идем, җыру җырлый идем. Радиодан җырны эләктереп ала идем. Җә амбарға қуласы әйләндерерғә, көлтә кертерғә бара идем.

Безнең заманда туй йуқ иде. Мужиғым байанист булып эшләде. Күзе күрмәғән кеше. Ул wақытта қалай түбә йуқ иде. Без беренче йаптық. Мин қатлама пешерәм. Төче қамыр пешерә белмим. Ашқазанға төче қамыр йарамый. Әни әйтә торған иде – әче қамырдан қоймақ пешерсәң, бөтен ғәйләң туқлықлы булыр, ди торған иде.

*Сөйләүче: Тарасова Анна Андреевна (1931 елгы).*
*Кече Кирмән авылы*

Бәк күмәк үстек, 10 кеше. Үғезләр белән суқа суқаладык. Сәрдәләр – ашый торған печән, қысытқан җыйа идек. Әбәкле уйын уйный идек.

Иптәшем күтәреп алып китте, урам буенча күтәреп қайтты, мин җылыйм. Әнкәй булған кеше идәндә йатқан. «Медәнәй, сиңа қыз апқайттым, қызың да шул, килен дә шул, нық тот, җибәрмә!» – диде, менә сүзе шул. Аннан әнкәйнең изгән қоймағы булған, мин

ушада (*урындык*) утыра идем. Бер-ике таба қоймақ пешерде дә, чығып: «Арлы-бирле йөрисе түгел, тел йәшерәсе түгел, сөйләшәргә кирәк!» – диде. Минем қызлардан ишеткәнем бар иде, килен булып төшкәч, башта ук әнкәй, әткәй дип әйтмәсәң, аннары ғумер буе әйтмәссең, диләр иде. «Әнкәй, бар әткәй белән утрып чәй эч, мин пешереп бетермен, дидем. «Җоласы шундый, бар, сишмә йулын күрсәт киленгә», диде әнкәй.

*Сөйләүче: Мостафина Мәрьямбикә*
*Миңнехан кызы (1929 елгы).*
*Түбән Шүләнгер авылы*

Тормышлар җарый инде шунда. Бәләкәй чақта пычқы, чуйен сыза идек, түгәрәкле, назалы уйный идек. Тәтәй, нәнәй бар иде минем. 47 җылларны без басуда черек бәрәңге җыйдық, wәт анысы тәмне иде.

Утын алып қайталар иде, қаз өмәләре, орчық җерләргә, тула баса идек. Бәләкәйдән үк мал тота идек. Йорт – ишек алды, йорттағы биналар – қаралты алды, ултар – абзар алдында бүлеп чығара торған урын. Өй әйләнәсе белән чат, монсысы өй түре.

*Сөйләүче: Филиппова Мария*
*Васильевна (1926 елгы).*
*Юкәче авылы*

Элекегене сөйләп бетерерлек түгел, балалар. Җирләр кипкәч, чиркәү қырында уйный идек, председатель безне қуа иде «шайтан чапмағыз монда», дип. Тауда җул ачарға йәшләрне җыйдылар, тау қазырға. Ач чақлар иде, көрәк күтәрерлек хәл йуқ иде, ә чоқырға кирәк, һәрберсенә метрлап бүлеп бирәләр иде, қарап торалар иде, қазырға кирәк.

Элек билчәк, ирен җырғычы, дусай печәне ашап үстек. Бәләкәй генә, өч тәрәзәле өйдә тордық. Қыш көнне сыйыр керә иде өйгә. Гупчи инде ул, балам, қазан да мич. Йортта сарай, тавық сарйы, җылы сарай була торған иде.

*Сөйләүче: Иванова Татьяна*
*Яфимовна (1931 елгы).*
*Түбән Тәкәнеш авылы*

Җиде бала үстек. Шулай үстек инде барыбыздағын. Иң кече энебез исән әле. Қачышлы уйный идек, өйдә утырмадық. Суғышлар башланғач, эш тә эш, ашарға тамам булды инде.

Алар инде ашау йағыннан йахшы торалар иде. Җәйаү йөреп эшләдем. Өмәләр бик булмағандыр инде. Болай қазлар асрый идек,

үзебез ғенә эшкәртәдериек инде. Ғомер бйые мал белән йашәдек инде. Қаралты-қурада малларны тотабыз. Ашлықны тутырып тимер тағараққа сала идек. Өйдә инде қоры сары қоймақ, дучмақ пешерә идек. Ул wақытта никәх уқыттылар. Уқымышлы қартны чақыртып уқыттылар.

*Сөйләүче: Газизова Зәкиябану*
*Нәҗип кызы (1925 елгы).*
*Шәмәк авылы*

Исеме мәтрүшкә, бүтән җирләрең зәғыйф,
Айағың кәкре эшкә.

Ат җиғеп йөри идек, име. Утыз җыл сийыр саудым. Чабатаға күтәрмә қағып үрәләр иде. Чистайға су күтәрелә дип таш кисерғә бардық. Җәйәү қайттық алты чақрым. Айақта чабата. Без күрғәнне, урамда йөреғән әшәке ас эт тә күрми.

*Сөйләүче: Садриева Фәхрибанат*
*Захетдин кызы (1931 елгы).*
*Шәмәк авылы*

Мин бер бала үстем. Әтәй суғышта үлде, әнәй кийәүгә китте, әме. Мин әтәйнең абыйсында үстем. Мин 19 йәштә кийәүғә чықтым, җийын күгәрчен арасында чәүкә булып тормыйм, дидем. Иптәшем җиңғәнең туғаны иде. Әйбәт тордық, туғыз бала китердем. Ниқахта мулла уқыттық та кийәү булды да бетте.

Қаз үмәләре, җеп җегерләү үмәсе, киндер суғу үмәләре була торған иде. Безнең ауыл йегерме генә өй иде, әме. Шулай да кино килә иде. Туманный килде дип йөгөрешә идек, шулай дийә идек без аны.

*Сөйләүче: Вәлиуллина*
*Маһиямал апа (1913 елгы).*
*Шәдче авылы*

## Халык иҗаты

Ақлы ситцы күлмәгемне табалмадым, ишләрем,
Бу урамда рәхәт ийе, чит урамда нишләрем.

Оста тегүчеләр теккән өстемдәге бишмәтне,
Сиксәнем уңышлы узды, сиксән бере нишләтте.

Ипиен дә пешерәләр хөкүмәт мичләрендә,
Бар мөлкәтем утқа чықты биш минут эчләрендә.

Чәчләремне тарап қуйғач, мин үрмичә кем үрсен,
И, Ходаем, бир сабырлық, мин күрғәнне кем күрсен.

Балақайым, чығып киттең, айрылабыз, диден дә,
Басқан жирдә йылап қалдым, башымны түбән идем дә.

Биш ел буе сыйыр саудым ап-ақ халатлар кийеп,
Киткән чақта әйтмәдең бит, әни, сау булып тор, диеп.

Бер утырып йыллар үтәм, бийек тауға менгәнче,
Ана баланы ташламый гүргә барып кергәнче.

Синең йанға менәр ийем, йылға аша йулыбыз,
Җылға тирән, таwы текә, сузылып җитмәс қулыбыз.

Балақаем, чәчләреңне бер толымнан үрерсең,
Ғазиз башым, йалғыз қалдың, тағын ниләр күрерсең.

Алтын бер йөзек қашым, көмештән җөрлек қашым,
Биш бала үстереп, йалғыз қалдыңмы, ғазиз башым?

Бийек тауның башларында ғәүәр чәчәкле җитен,
Сиксән йәшләреңә җитеп, йалғыз қалғач, бик читен.

Безнең бақча башларыннан челтерәп сулар ақты бит,
Сиксәннәргә җиткәч, башым йапа-йалғыз қалды бит.

Қулымдағы йөзөгемнең исемнәре Миннәхмәт,
Сиксән икене тудырдың, Ходай тәғәләм, рәхмәт.

* * *

Балам, монда йарлы да йуқ, бай да йуқ, қойаш та йуқ, ай да йуқ,
Минем өчен елама, утлар-сулар елытма, тик хәйер бирергә онытма.

Балақаем, моннан беркемнең дә қайтқан йуқ, қайтыр йулны эзләп
тапқан йуқ,
Шулай булғач, син мине көтмә, аш-суың суытма, тик хәер
бирерғә онытма.

Балам, монда қағәз дә йуқ, қаләм дә йуқ, йаза алмам сиңа хат
та, сәләм дә,
Шулай булғач син миңа үпкә тотма, тиқ хәйер бирерғә онытма.

## Үги қыз бәете

Иптәшләр, җырлыйм хәзер мин сезгә
Туры килер бу эш һәрқемгә,
Ничек зирәк минем иптәшләрем
Җиргә түгелә күз йәшем.

Әти-әниләр тордылар йахшы,
Қайғы төште бу матур қызға,
Әнисе үлде, қалды қыз йәтим,
Мәңге сарғайырға, ғомергә.

Үз әнкәйем мине йаратты,
Орошмады, бер сүз әйтмәде,
Үги әнием, қара йөрәқле,
Әткәйемне эшкә өйрәтте.

Көннәрдән бер көнне
Әткәйем әйтә: Зәйнәб қызым, әйдә йөрөргә,
Қара урманнарға, зиратларға,
Әнкәйеңнең қаберен күрергә.

Бармыйм, әткәй, анда йөрөргә,
Анда әлләниләр күрергә
Барсам да барырмын анда йөрөргә,
Барам әнкәйемнең қаберен күрергә.

Шул сүземне әйткәч, киендем,
Әйдә әткәй, әйдә барыйқ,
Әнкәйемнең қаберен чәчәкләр
белән бизәп қайтыйқ.

Зиратлардан чәчәкләр җыйдым,
Җыйған чәчәкләрем бер қочақ.
Әткәйемнең қулында мине суйарға
Йалт-йолт итә бер пычақ.

Суйдым баламны, сөйгән қызымны,
Дөнйасында тормыш қалмағач,
Қәфердин усал булдым балама
Йәш хатынның сүзеннән.

Иптәшләр, жырлыйм хәзер мин сезгә
Тыңламыйча берегез қалмағыз, ди.
Хатын үлсә, бала өстеннән
Икенчеләй хатын алмағыз, ди.

* * *

Сахибәдан қалған тулуп, Миннәхмәт, кигәннәрең
Туқсан туғыз төрлө, Сара, миннән соң сөйғәннәрең.
Хорум күн итекләр киеп, айақларың талмасын,
Кикерүк тиғән балаң төшеп қалмасын.

* * *

Әжәлләр житәр, тыннарың бетәр,
Йасин уқырға wақытлар житәр.
Уқый алмассың, бетәр сулышың,
Артыңнан қалсын доға қылучың.

Ғазраил килер, жаныңны алыр,
Қызыл йөзләрең сарғайып қалыр,
Тордым дөньйада бераз wақытлар,
Салқын туфрақтан безгә йастықлар.

Зифа буйыңны үлчәп алырлар,
Қараңғы гүргә илтеп салырлар,
Қараңғы гүрдә қалыр бер башың,
Ақ фәрештәләр булсын йулдашың.
Бу йат илләргә кемнәр китерғән,
Безгә жортларны кемнәр житқерғән.

*Сөйләүче: Мәгъзүмова*
*Бибинур апа (1930 елгы).*
*Урта Кирмән авылы*

И, Нағыймә, дәхлем мөшкел (*хәлем начар*),
Ни киңәшләр бирәсең.

Кимим бүркем булса да,
Жыламыйм күңлем тулса да.
Инде жылап niләр файда,
Чыдыйқ аwыр булса да.

*Сөйләүче: Мәхдүмә әби (1923 елгы).*
*Урта Кирмән авылы*

Ғармун уйный бер малай,
Ғармун телләре қалай,
Әйтер исәпләрең булса,
Әйтешип қарыйқ давай.

Җырлыйм әле, җырлыйм әле,
Уникегә тулғанчы,
Уникеләргә тулғанчы,
Дуслар кңле булғанчы.

Җырлыйм әле, җырлыйм әле,
Җырлыйм әле икене
Җырламас идем икене,
Сез дусларым сөйкемле.

Җырлыйм әле, җырлыйм әле,
Җырлыйм әле өчләрне,
Җыруларға қушып җырлыйм
Уйымдағы хисләрне.

Җырлыйм әле, җырлыйм әле,
Җырлыйм әле, дүрт булсын,
Җыру тыңлаған қызларның
Ике күзе ут булсын.

Җырлыйм әле, җырлыйм әле,
Җырлыйм әле бишләрне,
Җырламас идем бишләрне
Йаратам дус-ишләрне.

Җырлыйм әле, җырлыйм әле,
Җырлыйм әле алтыны.
Җырламас идем алтыны,
Бүген безгә йал көнө.

Җырлыйм әле, җырлыйм әле,
Җырлыйм әле сигезне,
Җырламас идем сигезне,
Йаратам үзегезне.

Җырлыйм әле, җырлыйм әле,
Җырлыйм әле уннарны.
Җыруларға қушып җырлыйм,
Башымдағы моңнарны.

Җырлыйм әле, җырлыйм әле,
Җырлыйм әле умберне.
Мин җырламадым гел берне,
Мин җырладым умберне.

Мин җырладым да җырладым
Уникегә тулғандыр.
Уникеләргә тулғандыр,
Дуслар қүңле булғандыр.

*Сөйләүче: Хәбибуллина Әлфия*
*Хәйретдин қызы (1934 елгы).*
*Олыяз авылы*

Қызарып қойашлар чыға,
Незнай куда байышын.
Белый қүлмәген қигән дә
Кигән черный қайышын.

Минем иркәм армийдә,
Бик сағындым, қайт диеп,
Иркәм миңа хат җибәрде,
Матур йарләр тап диеп.

Минем иркәм армийәдә,
Утын бетте, қайт, диеп.
Иркәм миңа хат җибәрде,
Өй почмағын йақ, диеп.

Мысқыллап қычқырулар: «Күрсәтергә килдеңме әллә, чәкүшкәдәй буйыңны?!», «Йар тапмасаң, силсәүеткә биреп қара ғариза», «Уфада, Бәләбәйдә бәрәңге әрчергә йарарсың, алам да қайтам әйдә».

*Сөйләүче: Җәмилова Мөстакыймә*
*Гата кызы (1932 елгы).*
*Түбән Шуләнгер авылы*

Бисмиллаһи дип башлыймын,
Уқы, дисәгез, уқырмын,
Күңелләрегез ачылсын,
Сигез оҗмахның нурлары
Шушы йортларға чәчелсен.

Уқыйқ Қоръән, әйтик wәғазь,
Артсын бу йортның дәүләте
Қоръән уқып, wәғазь әйтү,
Пийғәмбәрләрнең сөннәте.

Мәҗлесегез күркәм булсын,
Өйегез нур белән тулсын.
Бу мәҗлестә булғаннарға
Сигез оҗмах насыйп булсын.

Килеп кердем өйегезгә,
Диспе күрдем чөегездә,
Иман нуры йөзегездә
Балқысын гүрегездә.

Сабыр булыйқ, сабыр булыйқ,
Сабыр булсаң, шайтан қачар,
Сабыр бәндә оҗмах ишеген
Үз қуллары белән ачар.

Сезгә бирим нинди бүләк,
Миннән сезгә изге теләк,
Қыйәмәт көнө булғанда,
Ходай қылсын изге зинхақ,
Ходай ачсын бәхетебез,

Оҗмах булсын тәхетебез,
Дин ислам белән қуанып,
Тыныч булсын wақытыбыз.
Ходай ғомребезне бирсә,
Мәҗлесләрдә күрешербез.

Иманыбыз қамил булса,
Ахирәттә қауышырбыз.

Айәтел көрси – зур айәт,
Йортығызда сез тотығыз.

Айател көрси уқымый
Әй ғафил булып йатмағыз.
Уқыйқ айәтел көрсине.
Хифздүхимә дигән сүзне.

Йаүмәл мәшхәр көннәрендә
Мәххәрүм қылмас ул безне.
Айәтел көрси – зур айәт,
Аны һәркем дә зурласын.

Аны зурлаған адәмнәр
Оҗмахларға туры барсын.
Айәтел көрси уқыған
Оҗмахларға керми қалмас.

Айәтел көрси белмәгән
Оҗмах йулларын и тапмас.
Айәтел көрси – зур айәт,
Биш намазлар да уқығыз.

Адашқанда, саташқанда
Шушы айәтне уқығыз.
Уқыйқ Айәтел көрсине,
Хифздүхимә дигән сүзне.

Җәннәтләрдә кәүсәр
шәрәфетдин
Эчерер ул безне.
Айәтел көрси уқығыз,
Сәфәр чықан wақытларда.

Хәтәрләрдән имин кыйлыр,
Айәтел көрси хақында.
Уқыйқ Айәтел көрсине,
Хифздүхимә дигән сүзне.

Мәрьйәм ана туйларында
Бергә қыйлсаң иде безне.

Миданға илтәр ул безне.
Ул бит Рәсулулла қызы.

Рәсулулла әләмендә
Бергә қыйлсын Алла безне.
Ләиллаһаиллаланың
Қарамағыз азиненә.

Ләиллаһаиллалаһы
Мәңге бетмәс хәзинә.
Ләиллаһаиллалаһы
Йулға чықсаң, йулға – шул.
Ләиллаһаиллалаһы
Йалғызлықта сердәш ул.

*Сөйләүче: Мостафина Мәрьямбикә*
*Миңнехан кызы (1929 елгы).*
*Түбән Шүләнгер авылы*

# ҖИР ЙӨЗЕНДӘ ҖИСЕМЕ БАР, ТАРИХ ӨЧЕН ИСЕМЕ БАР

*Гүзәлия Хажҗиева-Демирбаш*

Кыз бала исеме йолдыз балкышына
охшасын,
Назлы гөлчәчәктәй нәфис булсын!
Ир-ат исеме кылычлар чыңлавын
хәтерләтсен,
Аның мәгънәсендә акыл гәүдәләнсен!

*Рәсүл Гамзатов*

Татар исемнәре аерым бер система тәшкил иткән, билгеле бер чорларга нисбәтле рәвештә, үсеш-үзгәреш кичереп, җәмгыять тарихы белән бергә өйрәнелүне таләп итә торган антропонимиканың төп берәмлекләреннән саналалар. Тарихи материаллар нигезендә, билгеле бер чорга караган аерым төбәк исемнәрен барлау, статистик ысулларга таянып, аларны тарихи-лингвистик яктан анализлау антропонимик системаның үсеш-үзгәреш тенденцияләренең аерым аспектларын билгеләргә ярдәм итә. Шул рәвешле, Мамадыш шәһәренең исемиятен тикшерү антропонимик системаның үсеш-үзгәреш темпларын, антропонимиконның социаль дифференциациясен ачыклауда мөһим роль уйный. Аерым алганда, өйрәнү объекты булган исемнәрне диахроник аспектка таянып анализлау билгеле бер тарихи чорда яисә бер ел дәвамында теге яки бу торак пунктта, төбәктә, районда һ.б. җирләрдә ир-ат һәм хатын кыз исемнәренең кайсысы киң таралуын, кулланылышка яңа исем кергәндә, икенче беренең кулланылыш сферасы тараюын

яки бөтенләй юкка чыгуын билгеләргә мөмкинлек бирә. Шуңа күрә, халык саны азрак булган шәһәрләрдә яшәүчеләрнең исем системасы, исем бирү йола-гадәтләре зур шәһәрләрдәгедән бик нык аерыла һәм моны анализлау тел тарихы җәһәтеннән әһәмиятле булып санала[1].

XIX йөз – татар әдәби теле һәм матур әдәбият стиле тарихында яңару һәм үзгәрешләргә бай, гаять үзенчәлекле, катлаулы чор. Иҗтимагый мөнәсәбәтләр, милли күтәрелеш һәм җәмгыятьтәге тарихи вакыйгалар, балага исем кушуның тулысы белән муллалар кулына күчүе бу чорда дини эчтәлектәге исемнәренең артуына китерә. Дин әһелләре XIX гасыр ахырларында исем дөньясына кагылышлы махсус китапчыклар бастыру эшен дә киң җәелдерәләр. 1848 елда Казанда басылып чыккан «Исме Аллаһы Тәгалә әл-хәсәни», 1865 елда «Авради Фәтхия», 1899–1900 елларда Ахун Бендуковның «Исем. Балага күркәм исем бирергә киңәш һәм укучы сабыйларга һәдия кылырга муафикъ китап» кебек җыентыклар киң катлау укучыга тәкъдим ителә.

«Ревизская сказка» мәгълүматларына караганда, 1870–1874 елларда Мамадыш өязендә 534 ир балага 162 төрле исем бирелгән. Бер үк исем йөртүчеләрнең уртача коэффициенты 3,2 гә туры килә. Еш кулланылучы ун исем түбәндәгеләр: *Мөхәммәтвәли, Әхмәтҗан, Мостафа, Мөхәммәтгали, Мөхәммәтзариф, Мөхәммәткәрим, Мөхәммәтша, Мөхәммәтшакир, Мөхәммәтҗан, Мөхәммәтрәхим.* Әлеге исемнәрдән күренгәнчә, еш кулланылучы ун ир-ат исеменең сигезе *Мөхәммәт* компоненты нигезендә ясалган. Бу компонент барлыгы 24 ир-ат исеме ясауда катнаша һәм, барлык исем йөртүчеләрнең уртача коэффициентыннан чыгып исәпләгәндә, 30,7% ны тәшкил итә.

Мамадыш өязендә *габд-/габде-/габдел-* антропоформанты 24 ир-ат исемендә чагылыш тапкан. Бу антропоформант ярдәмендә 52 ир-ат исеме ясалган. Бу барлык исемнәренең 9,7 % ын тәшкил итә.

Мамадыш өязендә XIX гасыр ир-ат исемнәренең зур күпчелеге гарәп-фарсы чыгышлы булуы ачыкланды. Шулай ук, төрки чыгыш-

---

[1] Мәкаләдә Мамадыш өязенең XIX гасырга караган исемнәре «Ревизская сказка» материалларыннан, XX һәм XXI гасырларга караганнары ЗАГС бүлегенең туу турындагы кенәгәләреннән тупланды.

лы компонентларны да,аерым исем буларак яки исемнәр нигезендә, аз санда булса да очратырга мөмкин: *Аблак, Ташмәрдән, Котлымөхәммәт, Тимергали, Тимербулат, Биккенә, Биктимер, Килмәмәт, Аллабирде* һ.б.

Структур яктан караганда, Мамадыш өязендә ике составлы ир-ат исемнәре барлык ир-ат исемнәренең 77 %ын тәшкил итә һәм бу күренеш, Казан шәһәре белән чагыштырганда, 4 %ка күбрәк. Димәк, Мамадыш өязендә XIX гасыр ахырына таба традицион ике компонентлы исемнәр калыбы тотрыклы саклана, дип әйтергә нигез бар.

Исемнәргә ясаган лингвистик анализ нәтиҗәләре халык саны төрле булган территорияләрдә яшәүчеләрнең (Казан шәһәре һәм Мамадыш өязе мисалында) исем составы ягыннан аерылуын ассызыкларга ярдәм итәләр. Бу, беренче чиратта, иҗтимагый-сәяси, дини шартларның әлеге территорияләрдә үзгә булуын һәм халык саны аз булган шәһәрләрдә, авылларда консерватик фикерләүнең исем кушуда чагылыш табуын социаль күзлектән чыгып күзәтергә мөмкинлек бирә. Икенче чиратта, халкы аз булган территорияләрдә гореф-гадәтләрнең, йола-традицияләрнең нигезле саклануы исем системасының тотрыклылыгын тәэмин итүдә әһәмиятле урын алып тора.

XX гасыр – төрле сәяси-иҗтимагый, мәдәни вакыйгаларга бай чор. Аларның һәркайсы татар антропонимик системасының үзенчәлекле формалашуына, үсеш-үзгәрешләренә тәэсир итә. Мамадыш шәһәренең XX гасыр исемнәре ике хронологик вакыт аралыгына аерылды һәм ЗАГС материалларына нигезләнеп анализланды. 1930–1939 елларда 723 ир бала туган булса, аларга 127 төрле исем бирелгән. 1990–1999 елларда исә 812 ир балага 128 төрле исем кушыла. Казан шәһәрендә һәм Мамадышта яшәүчеләрнең исем зәвыкларын чагыштырып карау максатыннан, унбиш еш кулланыла торган ир-ат исеме 1 нче таблицада бирелә (I графа – исемнәр; II графа – аларның саны; III графа – гомуми күрсәткече %ларда).

*1 нче таблица*

| 1930–1939 | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **Казан шәһәре буенча** | | | **Мамадыш шәһәре буенча** | | |
| Илдус | 84 | 5,74 | Рафаил | 12 | 5,74 |
| Рәшит | 60 | 4,10 | Илдус | 7 | 3,34 |
| Равил | 57 | 3,89 | Азат | 6 | 2,87 |
| Рәфкать | 50 | 3,41 | Ирек | 6 | 2,87 |
| Мансур | 49 | 3,35 | Илгиз | 6 | 2,87 |
| Рафаил | 49 | 3,35 | Наил | 5 | 2,39 |
| Әнвәр | 47 | 3,21 | Мансур | 5 | 2,39 |
| Наил | 44 | 3,00 | Рәфкать | 5 | 2,3 |
| Илдар | 41 | 2,80 | Марат | 4 | 1,91 |
| Шамил | 37 | 2,53 | Рәшит | 4 | 1,91 |
| Фәрит | 35 | 2,39 | Марсель | 4 | 1,91 |
| Илгизәр | 34 | 2,32 | Роберт | 4 | 1,91 |
| Камил | 28 | 1,91 | Марс | 4 | 1,91 |
| Мәхмүт | 27 | 1,84 | Рәүф | 4 | 1,91 |
| Фоат | 27 | 1,84 | Альберт | 3 | 1,43 |
| Габдулла | 20 | 1,36 | Равил | 3 | 1,43 |
| Гомәр | 20 | 1,36 | Алмаз | 2 | 0,95 |
| Ренат | 18 | 1,23 | Габдулла | 2 | 0,95 |

Әлеге таблицадан күренгәнчә, Мамадыш шәһәре ир-ат исемнәре системасында рус һәм Көнбатыш Европа алынмаларының, Казан шәһәре белән чагыштырганда, күбрәк булуы күзәтелә. Казан шәһәрендә еш кулланылучы 15 исемнән икесе рус теле һәм Көнбатыш Европа телләреннән алынган. Бу – исемнәрнең 13% ын тәшкил итә. Мамадыш шәһәрендә, таблицадан күренгәнчә, алты исем рус теле һәм Көнбатыш Европа телләреннән кергән. Бу – исемнәрнең 40 % ын тәшкил итә. Димәк, Мамадыш шәһәрендә 1930–1939 елларда «европалашу» тенденциясе 27 % ка күбрәк булуы ачыклана. Бу чорда аббревиатур исемнәрнең артуы күзәтелә. Аббревиация ысулы белән ясалган исемнәрне, структур-ясалыш үзенчәлекләреннән чыгып, түбәндәге төркемчәләргә аерып карарга мөмкин:

1. Исемнәрнең беренче хәрефләрен кушу нәтиҗәсендә ясалган исемнәр: *Вил – Владимир Ильич Ленин; Вилен – Владимир Ильич Ленин; Владлен – Владимир Ленин* һ.б.

2. Инициалларга апеллятив лексиканың кушылып ясалуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән ир-ат исемнәре: *Вилор – В.И. Ленин организатор армии; Вилюр – В.И. Ленин любит рабочих; Вилсор – В.И. Ленин создатель октябрьской революции* һ.б.

3. Инициалларга традицион төрки һәм гарәп-фарсы чыгышлы антропокомпонентлар кушылу нәтиҗәсендә барлыкка килгән исемнәр: *Вилнур – В.И. Ленин нуры; Вилданшаһ – Вил+дан+шаһ* һ.б.

4. Апеллятив лексиканың кыскаруы нәтиҗәсендә ясалган исемнәр: *Ким – Коммунистический интернационал молодежи; Рэн – революция, энергетика, наука; Рэм – революция, энергетика, механизация* һ.б.

90 нчы елларга таба бу төр аббревиатур исемнәрнең Мамадыш шәһәренә караган исем материалларында азаюы күзәтелә.

1990–1999 елгы ир-ат исемнәрен Казан шәһәре мәгълүматлары белән Мамадыш шәһәрен чагыштырган түбәндәге 2 нче таблицаны карыйк (I графа – исемнәр; II графа – аларның саны; III графа – гомуми күрсәткече % ларда):

*2 нче таблица*

| **1990–1999** | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **Казан шәһәре Киров районы буенча** | | | **Мамадыш шәһәре буенча** | | |
| Артур | 216 | 8,13 | Айрат | 20 | 2,91 |
| Руслан | 184 | 6,93 | Илнур | 18 | 2,62 |
| Тимур | 170 | 6,40 | Рамил | 17 | 2,48 |
| Гадел | 144 | 5,42 | Габдулла | 17 | 2,48 |
| Булат | 99 | 3,73 | Гадел | 16 | 2,33 |
| Айрат | 90 | 3,39 | Айдар | 16 | 2,33 |
| Марат | 70 | 2,63 | Марат | 16 | 2,33 |
| Алмаз | 70 | 2,63 | Айнур | 15 | 2,18 |
| Рамил | 66 | 2,48 | Ришат | 15 | 2,18 |
| Айдар | 64 | 2,41 | Артур | 14 | 2,04 |
| Ренат | 59 | 2,22 | Рәмис | 14 | 2,0 |
| Динар | 59 | 2,22 | Раил | 12 | 1,75 |
| Эмиль | 57 | 2,14 | Илшат | 12 | 1,75 |
| Эдуард | 57 | 2,14 | Альберт | 12 | 1,75 |
| Данил | 56 | 2,11 | Рөстәм | 11 | 1,6 |
| Альберт | 54 | 2,03 | Дамир | 11 | 1,6 |

XX гасыр ахырына таба зур шәһәрләрдәге ир-ат исемнәре системасында европалашу тенденциясе ныграк чагыла башлый; кечкенә шәһәр, район, авыл мәдәнияте өстенлек иткән территорияләрдә милли ир-ат исемнәренең саклануы, традицион ир-ат исемнәре тотрыклылыгы күзәтелә.

Шәһәр ир-ат исемнәре исем репертуары ягыннан төрлелеге белән аерыла. Кечкенә шәһәрнең исем репертуары төрлелек ягыннан чикле. Бу күренешне зур шәһәрләрдә төрле этнокультураларның тыгыз бәйләнештә торулары һәм аларның татар мохитенә тәэсире белән аңлатырга мөмкин. Бигрәк тә, Көнчыгыш һәм якын Кавказ илләре белән сәяси-икътисади, сәүдә элемтәләре урнаштыру, туризмнһ үсеше антропонимик системабызга татар ир-ат исемнәренең яңа дулкыны үтеп керүгә сәбәп булып тора. 1990–1999 елларда татар антропонимиконында *Азаман, Анар, Аршак, Айзек, Алишер* кебек ир-ат исемнәренең артуы – моның ачык мисалы.

XX гасыр ахырларына исемнәр системасында ир-атлар өчен ясалма исемнәр арта. Ата-аналарның иҗаты нәтиҗәсендә барлыкка килеп, зур тизлек белән таралу алган ясалма исемнәр традицион исемнәрнең фонетик ономавариантларын тәшкил итәләр. Бу исемнәрне балага кушуда фоносимволизм төп мотив итеп карала. Мәсәлән, Реназ– Ренас исеменең («революция», «наука», «союз» сүзләренең аббревиатурасы) фонетик варианты. Бу очракта Реназ исеменең соңгы компонентында исемне миллиләштерү тенденциясе күзәтелә. Аваз ассоциацияләре, эвфония, какафония исем сайлауда мөһим процесс саналалар. Исемнәрнең авазлар ассоциациясен билгеләүдә исемнең билгеле бер бердәм музыкаль фраза басымы астында әйтелүенә, аның ритмикасына, мелодикасына, пластикасының әһәмиятенә күп кенә галимнәр игътибар итәләр. Шуңа күрә, исемнең фонетик яңгырашын югары күтәрелешле авазларның түбән күтәрелешле авазлардан өстен булуы, аерым бер сузык авазларның (мәсәлән, [а], [о], [е], [и]), сонор авазларның (мәсәлән, [м], [л], [р], [н]) килүе кебек үзенчәлекләр билгелиләр һәм шулай ук исем сайлауда мөһим роль уйныйлар. Шул рәвешле, татар исемнәре арасында *Марат, Ленар, Реназ, Наил* һ.б. кебек сонор авазлар белән билгеләнгән исемнәр рейтингның рейтингның югары шкаласын билиләр. Исемнәрдә кулланылган [р], [с], [п], [т] кебек тартык авазлар исә исемнәргә калынлык биреп, аһәңлелек өсти.

Ассызыклап әйтсәк, XX гасырда татар исемиятендә сизелерлек үзгәрешләрне билгеләргә мөмкин. Ир-атлар өчен ясалма исемнәрнең саны арту, рус һәм Көнбатыш Европа исемнәренә охшаш исемнәр ясалу тенденцияләре, ата-аналарның уңай семантик мәгънәгә ия исемнәргә игътибар итмәве милли антропонимик берәмлекләрнең традицион үсешенә тискәре йогынты ясый. XIX гасыр ир-ат исемнәреннән аермалы буларак, XX гасыр антропонимик системасының «гадиләшү» тенденциясе ике компонентлы исемнәренең аз санда кулланылуы белән билгеләнә.

XX гасыр ахырына таба еш кулланылучы исемнәр арасында гасыр уртасында кулланылган исемнәр сирәк күзәтелә. Димәк, татар антропонимик системасы һәрдаим яңару процессы кичереп, шул ук вакытта традицион калыптагы исемнәрне дә репертуарында саклый, дип әйтергә нигез бар.

XX гасыр ахыры – XXI гасыр башында, халкыбызның гореф-гадәтләргә, традицияләргә нигезләнгән исем бирү йола-гадәтләре белән бергә, экстраоригиналь исемнәр кушу тенденциясен, кешенең психик эшчәнлеге нәтиҗәсендә килеп туган ассоциатив мотивларның билгеләнүен күзәтә алабыз. Татар антропонимиконында күпчелек исемнәр алынма булганга күрә, исемнәрнең беренчел лексик мәгънәләре игътибарга алынмый, нәтиҗәдә, татар антропонимиконында исем бирү мотивларының ассоциатив төрләре барлыкка килә. Тел күренеше буларак сүз, үзенең парадигматик вариантлары һәм синтагматик мөмкинлекләре белән бергә, субъектның, ягъни сөйләүченең иҗади-психик эшчәнлеге нәтиҗәсендә, чынбарлыктагы башка объект-системалар белән реаль ассоциатив бәйләнеш хасыйл итә. Антропонимик берәмлекләрдә тышкы яңгырашның эчке мәгънә барлыкка китерүеннән, телнең тарихи үсеше процессында исемнең яңа эчтәлек алуыннан, авазларның фонетик мәгънәләреннән оешкан ассоциатив бәйләнешләр, кеше сөйләме һәм фикерләвенең эчке бәйләнеш-мөнәсәбәтләре исем бирү мотивларында чагыла. Исемгә бәйле ассоциацияләр исем кушуда билгеле бер мотив барлыкка китерәләр. В.А. Гречко исемнең мәгънәсен кешенең үзенә бәйләп карый: «для круга людей, знающих определенное лицо, смысл имени изменяется по мере изменения самого человека в зависимости от его возраста, деятельности, взаимоотношения с людьми, близости с ними и др. Во всем обнаруживаются особенности характера человека, его качества, способности

и пр., что и находит отражение в конкретном содержании антропонима»[1]. Кешенең кылган гамәлләре, эшләре аның исемен билгели. Исем шәхеснең матрицасы булып та кабул ителергә мөмкин. Исем сайлаганда, билгеле бер кеше, аның кылган гамәлләрен күзаллау рәвешендә килеп баса. Мәсәлән, Адольф исеме татарлар һәм руслар арасында популялашып китә алмады, чөнки бу исем Адольф Гитлер белән туган ассоциацияләр бирә. 2000–2005 елларда *Тамерлан – Тимерлан, Чыңгыз, Чыңгызхан* исемнәре тарихта эз калдырган шәхесләр белән ассоциацияләшә. Бу исемнәрне кушуда ассоциатив мотивлар мөһим роль башкаралар.

Гаилә эчендә барлыкка килгән ассоциацияләр исемнең башка гаилә әгъзалары белән рифмалашуында чагыла. Төрки халыкларда исемнәр рифмалашу мәсьәләсендә күп кенә тикшеренүләр үткәрелгән. З.Г. Ураксин исем бирүдә рифмалашуның әһәмиятен билгеләп болай ди: «немаловажное значение при выборе имени имеет и созвучность начальных и конечных частей имени ребенка с именем отца, матери, или старших братьев и сестер. Эта древняя традиция сохраняется поныне и является одним из важных моментов при наречении тем или иным именем»[2]. Төрле буын арасында рифмалашу – вертикаль рифмалашу дип аталса, бер буын арасындагы (абый һәм апа, игезәкләр һ.б.) рифмалашуын – горизонталь рифмалашу, дип атыйлар.

Горизонталь һәм вертикаль рифмалашуның түбәндәге төрләре бар:

Аллитерация – пост яки препозициядә билгеле бер авазның яисә авазлар кушылмасының, формант яки компонентның кабатланып килүе. Препозицион аллитерация нигезендә ясалган исемнәр: *Айрат – Айнур – Айвар – Айдар – Айбулат, Илшат – Илнар – Илдар, Рамил – Радик – Раил* һ.б.

Постпозицион аллитерация нигезендә ясалган исемнәр: *Илназ – Айназ; Галимҗан – Сәетҗан – Шакирҗан; Булат – Марат – Айрат* һ.б.

Мамадыш шәһәренең XXI гасырга караган исем кенәгәләрен анализлау барышында горизонталь һәм вертикаль рифмалашу күренешләрен күзәтергә мөмкин.

---

[1] Гречко В.А. Теория языкознания: учебное пособие. М.: Высш. шк., 2003. 372 с.

[2] Ураксин З.Г. Башкирские антропонимы из этнонимов // Ономастика Поволжья. Уфа, 1973. № 3. С. 86–89.

XXI гасырга караган исемнәрне тулырак күзаллау максатында Мамадыш белән Казан шәһәрләрендә 2000–2012 елларда еш кулланылган ир-ат исемнәре 3 нче таблицада тәкъдим ителә.

*3 нче таблица*

| **Казан шәһәре буенча** | | | **Мамадыш шәһәре буенча** | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Данил | 113 | 7,90 | Булат | 36 | 5,97 |
| Артур | 81 | 5,66 | Алмаз | 35 | 5,80 |
| Тимур | 79 | 5,52 | Илназ | 23 | 3,81 |
| Руслан | 68 | 4,75 | Гадел | 21 | 3,48 |
| Булат | 67 | 4,68 | Инсаф | 19 | 3,15 |
| Эмил | 61 | 4,26 | Руслан | 18 | 2,98 |
| Эмир | 43 | 3,00 | Ислам | 17 | 2,81 |
| Камил | 37 | 2,58 | Илдар | 16 | 2,65 |
| Айрат | 35 | 2,44 | Ильяс | 16 | 2,65 |
| Марсель | 28 | 1,95 | Нияз | 15 | 2,48 |
| Азат | 26 | 1,81 | Илнур | 12 | 1,99 |
| Алмаз | 26 | 1,81 | Рөстәм | 12 | 1,99 |
| Дамир | 26 | 1,81 | Рамил | 10 | 1,65 |
| Айдар | 24 | 1,67 | Дамир | 10 | 1,65 |
| Рөстәм | 22 | 1,53 | Эмир | 10 | 1,65 |
| Динар | 20 | 1,39 | Айдар | 9 | 1,49 |

Әлеге таблицадан күренгәнчә, XXI гасыр башында Мамадыш шәһәре исемнәренең «чуарлануы» күзәтелә. Бер яктан, исемнәр системасында европалашу тенденциясе чагылса, икенче яктан исә, ислам кануннарына йөз тоткан, миллилеген югалткан «азияләшү» тенденциясен ассызыкларга кирәк.

XXI гасыр башы исемнәре арасында, нигездә, мәҗүси йолаларга, төрле предмет-әйберләрнең көченә ышанган исемнәрнең дә кулланылуын билгеләргә мөмкин. Мәсәлән, *Тимер, Тимерулат, Булат* кебек исемнәр – тимернең, корычның ныклыгын балага күчерү нияте белән кушылган һәм асылы белән мәҗүси йола-традицияләргә нигезләгән антропонимик берәмлекләр.

Шулай ук, XXI гасыр башы антропонимик системасының үсеш тенденциясен билгеләгән теологик аспектка тукталып үтү дә урынлы булыр. Дини эчтәлекле исемнәрнең арту күренеше Мамадыш исемиятенә дә хас. Бигрәк тә, теопрефикслы исемнәр еш күзәтелә. Мамадыш шәһәрендә популяр теофор исемнәр: *Ильяс, Салават, Габдулла, Рамазан, Ибраһим, Мөхәммәт, Динислам, Кәрим* һ.б.

Татар антропонимик системасында башка тарихи чорларда очрамаган исемнәр арасында «идел», «ил», «таң», «ал», «ай», «яз» һ.б. компонентлар ярдәмендә ата-аналарның иҗат мөмкинлекләрен чагылдырган антропонимик берәмлекләрне дә билгеләргә мөмкин. Төрки нигезле компонентлар ярдәмендә ясалган һәм ата-аналарның балага булган теләк-ниятләрен чагылдырып иҗат ителгән исемнәр дә антропонимикон репертуарын тулыландыралар: *Иделә, Иделия, Илдан, Иршат, Иделман, Айзат, Айшат, Алнур, Язнур, Язгөлем, Таңгөл, Гөлнур* һ.б.

Мамадыш шәһәре исемиятендә 2000–2012 елларда ике составлы исемнәрнең саны арта. XIX гасырга хас ике составлы исемнәр ясауның яңадан-яңа иҗади мөмкинлекләре күзәтелә, исем репертуарын төрлеләндереп, яңа төр ике составлы исемнәр ясала башлыйлар. Мәсәлән, чор өчен яңа дип табылган исемнәрдән *Әмирхан, Гәбделваһап, Бикбулсын, Әмиртимур, Әбүрәхил, Әмирбәк, Гомәрҗан, Сәетбәк, Таһирҗан* кебек исемнәрне әйтергә мөмкин.

Традиция, йола-гадәтләргә, модага, ата-ананың зәвыгына туры килә торган исемнәр XXI гасырда да чагылыш таба. Әйтергә кирәк, исем кушу, исем сайлау традиция-йолалары, үзләренең формацияләрен, функцияләрен үзгәртеп, бүгенгәчә яшиләр. Мәсәлән, «ай» компоненты нигезендә ясалган исем мәҗүси традицияләргә бәйле булмыйча, ә «бала ай кебек матур булсын» теләге яки «айлы кичтә туган бала» дигәнне аңлатуга кайтып кала. Димәк, бу исемнәр ай культына бәйле түгел, аларда теләк, вакыйганы чагылдыру төп мотив булып тора. Татар антропонимиясендә ай антропокомпоненты төрки халыкларның уртак хәзинәсе булып тора. Шунысы үзенчәлекле: төрки халыкларда ай, табыну объекты булып түгел, ә ай календаре традицияләренә бәйләнешле кулланыла. Димәк, «ай» компонентлы исемнәрдә ел, ай календаренә бәйле традицияләр чагылыш таба. *Айтуды, Айбарс, Айкилде, Айтуган, Айбулат* кебек исемнәр татарлардан тыш, казакъларда, башкортларда, төрекмәннәрдә, үзбәкләрдә, төрекләрдә дә кулланыла. Мәсәлән, «ай» компонентлы исемнәр төрекләрдә *Айбарс, Айтимер, Айхан, Гөкай, Аканай, Бирай*, казакъларда *Айтуган, Айдан, Айбас,* башкортларда *Айбәк, Айкилде*, кыргызларда *Айзат, Айнурзат* кебек ир-ат исемнәрендә актив кулланылып, борынгы төрки катлам ир-ат исемнәрен тәшкил итәләр.

Кешенең исемнең язмышка тәэсир итүе турындагы күзаллаулары яисә сүзнең магик көченә ышану мотивы бүгенге антропони-

мик системадагы кайбер исемнәрдә дә чагылыш тапкан. Мәсәлән, «миң» компоненты белән ясалган *Миңбулат, Миңтимер, Миңлекамал, Миңлеҗан* һ.б. кебек исемнәрнең нигезендә сүзнең магик көченә ышану ята. Борынгы заманнардан ук исем кешенең «икенче мин»е итеп кабул ителгән.

Исемне начар уйлар белән әйтү исем йөртүчене авыруларга дучар итәргә яисә аның үлеменә китерергә дә мөмкин, дигән ышану яшәгән. Шуңа да ике исем йөртү киң таралаган, берсе – «табу» исем, икенчесе явыз көчләрдән «саклау исеме» булган. Борынгы төрки халыкларда яңа туган бала янына усал, явыз көчләрне, җен-пәриләрне китермәү, аларны куркыту максатыннан чыгып, аңа «начар» мәгънәле исем бирү йоласы яшәгән. Шуңа нисбәтле, борынгы төрки традицияләрнең күчемлелеге яңа гасыр исемнәрендә дә чагыла.

4 нче таблицада дүрт чорның исемнәре чагылыш алган (I графа – исемнәр; II графа – аларның саны; III графа – гомуми күрсәткече %ларда):

Татар антропонимикасы номинатив чыганакларының күп аспектлылыгы, исем бирү традицияләренең байлыгы, мотивларының төрлелеге белән характерлана. Исем бирү мотивлары исемнәрнең эчке һәм тышкы формаларында ачылалар. Исемнәрнең эчке формасында исемнең билгеле бер традиция-йолалар, ата-ананың балага булган изге теләкләре, тарихи шәхесләргә, милли геройларга, сәнгать әһелләренә багышлау кебек билгеләр төп рольне үти. Исемнең яңгырашы, фамилия, ата исеме белән аваздашлыгы, гаилә әгъзалары белән рифмалашып килүе исемнәрнең тышкы формасын тәшкил итәләр. Исемнәрнең эчке формасы исемнәрнең яңа эчтәлеген ача, семантикасын билгели. Исемнәрнең яңа эчтәлеге ир-ат исемнәренең лексик-семантик төркемнәрендә ачыла.

Аерым алганда, Мамадыш шәһәренең тарихи чыганакларындагы антропонимик система традицион исемнәрнең тотрыклы рәвештә үсеш-үзгәреше белән билгеләнә. XX гасыр урталарында рус антропонимикасыннан алынган һәм Көнбатыш Европа чыгышлы исемнәрнең өстенлекне алып торуы күзәтелә. Бу чорда антропонимик система «чуарлану» чорын кичерә башлый. Ике составлы ир-ат исемнәренең куллынылышы бермә-бер азая төшә. XX гасыр һәм XXI гасыр исемнәре арасында кискен аерма күзәтелми. Ономастик киңлекнең форма һәм эчтәлек ягыннан башка антропонимик берәмлекләрдән үзгә гомумуниверсаль берәмлекләрен тәшкил

*4 нче таблица*

| XIX гасыр | | | XX гасыр | | | | | | XXI гасыр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1870–1874 еллар | | | 1930–1939 еллар | | | 1990–1999 еллар | | | 2000–2012 еллар | | |
| Исхак | 73 | 9,4 | Рафаил | 12 | 5,74 | Алмаз | 42 | 6,13 | Булат | 36 | 5,97 |
| Ибраһим | 54 | 6,95 | Илдус | 7 | 3,34 | Булат | 39 | 5,69 | Алмаз | 35 | 5,80 |
| Йосыф | 45 | 5,79 | Азат | 6 | 2,87 | Руслан | 30 | 4,37 | Илназ | 23 | 3,81 |
| Мостафа | 42 | 5,41 | Ирек | 6 | 2,87 | Илназ | 28 | 4,08 | Гадел | 21 | 3,48 |
| Исмәгыйль | 38 | 4,89 | Илгиз | 6 | 2,87 | Илдар | 22 | 3,21 | Инсаф | 19 | 3,15 |
| Хәсән | 37 | 4,38 | Наил | 5 | 2,39 | Ленар | 21 | 3,06 | Руслан | 18 | 2,98 |
| Хөсәен | 34 | 4,38 | Рәфкать | 5 | 2,39 | Айрат | 20 | 2,91 | Ислам | 17 | 2,81 |
| Мөхәммәтҗан | 34 | 4,38 | Мансур | 5 | 2,39 | Илнур | 18 | 2,62 | Илдар | 16 | 2,65 |
| Якуп | 31 | 3,99 | Марат | 4 | 1.91 | Рамил | 17 | 2,48 | Ильяс | 16 | 2,65 |
| Мортаза | 31 | 3,99 | Марсель | 4 | 1,91 | Габдулла | 17 | 2,48 | Нияз | 15 | 2,48 |
| Мөхәммәтшәриф | 28 | 3,60 | Рәшит | 4 | 1,91 | Гадел | 16 | 2,33 | Илнур | 12 | 1,99 |
| Муса | 27 | 3,47 | Роберт | 4 | 1,91 | Айдар | 16 | 2,33 | Рөстәм | 12 | 1,99 |
| Әхмәтҗан | 23 | 2,96 | Рәүф | 4 | 1,91 | Марат | 16 | 2,33 | Рамил | 10 | 1,65 |
| Мөхәммәтвәли | 22 | 2,83 | Марс | 4 | 1,91 | Айнур | 15 | 2,18 | Дамир | 10 | 1,65 |
| Мөхәммәтгали | 18 | 2,31 | Альберт | 3 | 1,43 | Ришат | 15 | 2,18 | Әмир | 10 | 1,65 |
| Гобәйдулла | 18 | 2,31 | Равил | 3 | 1,43 | Артур | 14 | 2,04 | Айдар | 9 | 1,49 |
| Әхмәт | 15 | 1,93 | Алмаз | 2 | 0,95 | Рәмис | 14 | 2,04 | Раил | 9 | 1,49 |
| Мөхәммәт | 13 | 1,67 | Габдулла | 2 | 0,95 | Раил | 12 | 1,75 | Азат | 9 | 1,49 |
| Бикбай | 11 | 1,41 | Шамил | 2 | 0,95 | Илшат | 12 | 1,75 | Данис | 9 | 1,49 |
| Сөләйман | 8 | 1,04 | Самат | 2 | 0,95 | Альберт | 12 | 1,75 | Динар | 9 | 1,49 |

иткән татар исемнәренә тарихи-лингвистик анализ ясау аларның спецификасын, йола-традицияләргә бәйле кулланылышын ачыклауда, трансонимизация процессы нәтиҗәсендә барлыкка килгән ономастик берәмлекләрнең беренчел чыганакларын билгеләүдә зур әһәмияткә ия. Кыскасы, Мамадыш шәһәренең исем системасы җәмгыять тарихы, аның хокукый институтлары, иҗтимагый вакыйгалар тәэсирендә үсеш-үзгәреш кичереп формалашкан универсаль антропонимик берәмлекләрне тәшкил итә. Тулаем алганда, татар исемнәренең үсеш тенденцияләрен ачыклау халкыбызның милли үзаңы дәрәҗәсен, гореф-гадәтләре, традицияләренең халык көнкүрешендә яшәешенең торышын, шулай ук тел мәсьәләләрен чишәргә мөмкинлек бирә.

КУШЫМТА

Мамадыш өязе ир-ат исемнәренең «Ревизская сказка» материаллары буенча тупланган кулланылыш ешлыгы:

| 1870–1879 | | |
|---|---|---|
| Ир-ат исеме | Аларның саны | Гомуми күрсәткече (% ларда) |
| 1 | 2 | 3 |
| Мөхәммәтвәли | 17 | 3,18 |
| Әхмәтжан | 14 | 2,62 |
| Мостафа | 14 | 2,62 |
| Мөхәммәтгали | 14 | 2,62 |
| Мөхәммәтзариф | 14 | 2,62 |
| Мөхәммәткәрим | 13 | 2,43 |
| Мөхәммәтша | 13 | 2,43 |
| Мөхәммәтшакир | 13 | 2,43 |
| Мөхәммәтҗан | 12 | 2,24 |
| Мөхәммәтрәхим | 12 | 2,24 |
| Хөсәен | 11 | 2,0 |
| Шаһиәхмәт | 11 | 2,05 |
| Мөхәммәтлатыйф | 10 | 1,87 |
| Әхмәт | 9 | 1,68 |
| Габдулла | 8 | 1,49 |
| Сәйфетдин | 8 | 1,49 |
| Биктимер | 7 | 1,31 |
| Гайнулла | 7 | 1,31 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| Гайфулла | 7 | 1,31 |
| Муса | 7 | 1,31 |
| Габдрахман | 6 | 1,123 |
| Ибрай | 6 | 1,12 |
| Корбангали | 6 | 1,12 |
| Мөхәммәтсадыйк | 6 | 1,12 |
| Мөхәммәтсафа | 6 | 1Д2 |
| Мөхәммәтшәриф | 6 | 1,12 |
| Хәбибулла | 6 | 1,12 |
| Бикчәнтәй | 5 | 0,93 |
| Габделатыйф | 5 | 0,93 |
| Гобәйдулла | 5 | 0,93 |
| Дәүләтша | 5 | 0,93 |
| Исхак | 5 | 0,93 |
| Йосыф | 5 | 0,9 |
| Мортаза | 5 | 0,93 |
| Мөхәммәтгариф | 5 | 0,93 |
| Мөхәммәтзакир | 5 | 0,93 |
| Фәхретдин | 5 | 0,93 |
| Хәсән | 5 | 0,93 |
| Габделгаллэм | 4 | 0,74 |
| Габидулла | 4 | 0,74 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| Исмәгыйль | 4 | 0,74 |
| Корамша | 4 | 0,74 |
| Нәҗметдин | 4 | 0,74 |
| Ярулла | 2 | 0,37 |
| Аблак | 1 | 0,18 |
| Габделабдрахман | 1 | 0,18 |
| Габделвәли | 1 | 0,18 |
| Габделгани | 1 | 0,18 |
| Габделҗаббар | 1 | 0,18 |
| Габделзаһир | 1 | 0,18 |
| Габделкәрим | 1 | 0,18 |
| Габделлатыйф | 1 | 0,18 |
| Габделтаһир | 1 | 0,18 |
| Габделфәттах | 1 | 0,18 |
| Габделхәсән | 1 | 0,18 |
| Габденасыйр | 1 | 0,18 |
| Габди | 1 | 0,18 |
| Габдрәхим | 1 | 0,18 |
| Габдуллатыйф | 1 | 0,18 |
| Гаделша | 1 | 0,18 |
| Гайнетдин | 1 | 0,18 |
| Галәветдин | 1 | 0,18 |
| Гали | 1 | 0,18 |
| Галләм | 1 | 0,18 |
| Гатаулла | 1 | 0,18 |
| Гыйбәтулла | 1 | 0,18 |
| Динмөхәммәт | 1 | 0,18 |
| Әбубәкер | 1 | 0,187 |
| Әсмәндияр | 1 | 0,18 |
| Миссиярсафа | 1 | 0,18 |
| Әхмәтвәли | 1 | 0,18 |
| Әхмәтсадыйк | 1 | 0,18 |
| Әхмәтшакир | 1 | 0,18 |
| Әхтәм | 1 | 0,18 |
| Зәйнетдин | 1 | 0,18 |
| Иблиәмин | 1 | 0,18 |
| Ихсан | 1 | 0,1 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| Кәрим | 1 | 0,18 |
| Кәримулла | 1 | 0,18 |
| Котлымөхәммәт | 1 | 0,18 |
| Миндубай | 1 | 0,18 |
| Мозаффар | 1 | 0,18 |
| Монасыйп | 1 | 0,18 |
| Мөхәммәт | 1 | 0,18 |
| Мөхәммәтфатыйх | 1 | 0,18 |
| Мөхәммәтхөсәен | 1 | 0,18 |
| Мөхәммәтшамил | 1 | 0,18 |
| Мөхәммәтшәриф | 1 | 0,18 |
| Мөхәммәтюнысҗан | 1 | 0,18 |
| Нигъмәтҗан | 1 | 0,18 |
| Низаметдин | 1 | 0,18 |
| Ногман | 1 | 0,18 |
| Рафикъ | 1 | 0,18 |
| Сабит | 1 | 0,18 |
| Сафиулла | 1 | 0,18 |
| Ситдыйк | 1 | 0,18 |
| Талетдин | 1 | 0,18 |
| Ташмәрдән | 1 | 0,18 |
| Төхвәтулла | 1 | 0,18 |
| Фәтхулла | 1 | 0,18 |
| Хәмзә | 1 | 0,18 |
| Хәйрулла | 1 | 0,18 |
| Хаким | 1 | 0,18 |
| Хәнәфи | 1 | 0,18 |
| Хәсәнетдин | 1 | 0,18 |
| Хисаметдин | 1 | 0,18 |
| Хисметдин | 1 | 0,18 |
| Хөсни | 1 | 0,18 |
| Хөснетдин | 1 | 0,18 |
| Шәңгәрәй | 1 | 0,18 |
| Шанханнан | 1 | 0,18 |
| Шәмардан | 1 | 0,18 |
| Шәмсетдин | 1 | 0,18 |
| Шиһабгали | 1 | 0,18 |

# ЗӘҢГӘР ҖЕФӘККӘЙЛӘР, ӘЙ, СУЗАЕК

*Илсөяр Закирова*

Вы не поверите, что я скорее бы
стал жить в Мамадыше, чем
в Венеции, Риме, Неаполе.

*Л.Н. Толстой*

Татарстан Мәдәният министрлыгы каршындагы Татар дәүләт фольклор үзәге дә халык иҗатын җыю һәм өйрәнү максатыннан даими рәвештә фәнни экспедицияләр оештырып килә. Йолалар, гореф-гадәтләр, фольклор, милли киемнәрне өйрәнү, барлау, җыю максаты белән Мамадыш районына оештырылган экспедицияләрнең берсендә миңа да катнашырга туры килгән иде. 21 авылда – Түбән Тәкәнеш, Югары Тәкәнеш, Чәбия, Шәмәк, Никифорово, Олыяз, Дүсмәт, Дусай, Комазан башы, Иске Комазан, Шәдче, Җөри, Ташлыяр, Юкәче, Комырык, Ямаш, Түбән Ушма, Югары Ушма, Иске Завод, Урта һәм Кече Кирмән авылларында һәм Мамадышның үзендә булып, шактый гына материал туплалык.

**Түбән Тәкәнеш.** Авылның исемен Текә инештән килеп чыккан, инешнең суга төшә торган җире текә булган, дип аңлаталар. Әмма Тәкәнештән башка якларда очрамаган «Тәкәле» һәм «Тәкә салыш» уеннары белән танышкач, бу гипотезага шикләнеп карый башлыйсың. Берәр изге яки тотем тәкә хөрмәтенә Тәкәнеш булып китмәде микән бу авыл? дип уйлыйсың.

Тәкәнешнең ул чактагы җирле үзидарә советы рәисе Мурзина Римма Нуретдин кызы – әйбәт оештыручы, тәҗрибәле җитәкче, зур планнар белән яши, бөтенесен күрә, бөтенесенә өлгерә торган ханым иде. Римма апа үзе Свердловск шәһәрендә туып-үскән булса

да, күп еллар шушы авылда укытучы булып эшләгән, авыл халкын бик яхшы белә. Вакыт табып, әби-бабайлар янына да безне үзе йөртте.

Түбән Тәкәнештә истә калган икенче кеше – Гомәр абый Идиятов. Гомәр абый догалар ярдәмендә дәвалый, өшкерә, кешеләргә югалган җан тынычлыгын кайтарырга булыша. Аның янына, тәннәренә һәм бигрәк тә җаннарына дәва эзләп, еракларда киләләр.

Әлеге авылдагы информантыбызның иң өлкәне – 1915 елгы Маһинур әби Фатыйхова кичке уеннар, аулак өйләр турында гына сөйләп калмады, халык җырларын да җырлап биргән иде. Ә Зәкиябану әби Камалиеваның (1908 елгы) мөнәҗәт-бәетләре белән оныгы Азат яздырып калган аудиотасмалар һәм әбинең дәфтәрләре аша гына таныштык.

Һәрбер авылда әле быел гына, былтыр гына мәнгелеккә күчкән берәр әби-бабайны искә алалар. «Менә ул булсамы, ул булса», – диләр. Әби-бабайларның бөтен белгәннәрен үзләре белән алып китә торган гадәтләре бар шул.

**Югары Тәкәнештә** яшәүче Мәснәви абый Фәйзуллинның тальянда борынгы көйләрне уйнавын видеотасмага яздырырга кердек. Ул үзе белән булган вакыйгаларны да матур итеп сөйли, тарихи риваятьләрне, мифологик хикәятләрне дә яхшы белә торган кеше булып чыкты. Мифологик хикәятләр кешеләрнең серле затлар – җеннәр, пәриләр, су аналары, бичуралар белән очрашуын бәян итә. Бичура-җеннәрнең булу-булмавы, һәм әлеге вакыйгаларның да чынбарлык яки фантазия җимеше булуы – бәхәсле мәсьәлә. Без Мәснәви абыйның сөйләгәннәрен ышанып кабул иттек. Аның хикәятләре текст ахырында укучылар игътибарына да тәкъдим ителә.

**Дүсмәт һәм Комазан башы.** Дүсмәт – 81, ә Комазан башы 80 хуҗалыклы керәшен авыллары. Дүсмәткә – Дусмөхәммәт, ә Комазан башына Ишмөхәммәт исемле кешеләр нигез салган. Дусмөхәммәт тора-бара Дүсмәт булып калган. Ә Комазан башы авыл янында башланган елга исемен алган. Ике авыл да көчләп чукындырылган. Елганың икенче ягындагы авыллар гына чукындырылмыйча калган. Чөнки Явыз Иванның гаскәрләре язгы ташу вакытында килгән, бозлы суны үтеп, икенче якка чыга алмаганнар. Дүсмәт һәм Комазан башы халкын язгы бозлы ташу суына куып төшереп чукындырганнар. Халык хәтеренә кан һәм яшь белән язылган вакыйгалар бу.

Дүсмәт авылында яшәүче Марҗый түтәй Козлова, Сандра түтәй Спиридонова, Марҗый түтәй Жилкина, Анный түтәй Сергеева, Микулай дәдәй Григорьевлар Нардуган йолалары, Качману, Яфрак бәйрәме, Бәрмәнчек, Питрау, Савымлы туй турында сөйләделәр. Ә керәшен җырларын, аның кабатланмас моңын һәр кеше үзе тыңларга тиеш. Ул җырларда халыкның сабырлыгы да, моң-зары да, бер-берсенә ярдәмчеллеге дә, туганлык хисләре дә, эшчәнлеге дә, шул ук вакытта матур итеп күңел ача, бәйрәм итә белүе дә чагыла.

Алпан гына тулпан без атлыек,
Армыеккай, туганнар, талмыек.
Кечерәкәй генә аш-су тоткач та,
Бер-беребезне чакырмый,
Бер-беребезне чакырмый ла калмыек, –

дип башлап җибәрделәр түтәйләр моңлы озын көйне.

Комазан башында безне җыр-биюләр белән генә түгел, керәшеннәрнең кунак ризыгы – пирмәнкә әзерләп тә көткәннәр. Пирмәнкә – пилмәннең бер төре. Ә гадәти пилмәнне монда «татар колагы» дип атыйлар икән. Пирмәнкәләрне һәрберсен матур итеп бөреп яки үзләренчә әйтсәк «өмереп» ясыйлар. Керәшен авылларында әзерләнә торган тутырма да үзгәрәк ризык булып чыкты. Эчәккә тутырып ясамыйлар аны. Хәер, йөз тапкыр ишеткәнче, бер тапкыр ашап каравың ни тора.

Милли ризык дигәннән, әче бал куюның да рецептын язып алдык бирედә. Әче бал кайчандыр кунак, бәйрәм эчемлеге, затлы эчемлек саналган. Яңа аерткан балдан, бернинди чүпрә дә, шикәр дә кушмыйча әзерләгәннәр аны. Туйлар, солдатка озатулар, Сабантуй, Җыен алдыннан әче бал куйганнар. Күпме әдәби әсәрләргә кергән әче бал хәмер булмаган, бәйрәмнең бер бизәге булган. Кымыз төслерәк. Көмешкә ясауның да серен белдек. Мәсәлән, көмешкә уңсын өчен, мичкәгә тиешле ингриедентларын салгач, мичкә тирәли балаларны йөгертергә кирәк икән. Үзең дә такмаклап әйләнсәң ярый:

Уң булсын, мул булсын,
Шаулап әчесен,
Шарлап аксын,
Дөбер, дөбер, дөбер.

Комазан башында Мария Андреева оештырган Керәшен фольклор ансамбле башкаруында халыкның уен-биюләрен, такмак-җырларын видеотасмага төшердек, им-том текстлары, риваять-легендалар язып алдык.

**Никифорово** авылын татарча **Шыя башы** яки **Чия башы** дип атыйлар. Шыя – елга исеме. Авылның да чын исеме Шыя башы булып, халыкның паспортын алыштырганда гына чияләштергәннәр булса кирәк. Әмма кәгазьгә, бигрәк тә паспорт кебек җитди документка белмичә язмаслар дип, Никифорово халкы үзе дә икеләнебрәк калган, бәлки Чия башы дөрестер, диләр.

Никифорово авылында Анный түтәй Кириллова, Марҗый түтәй Иванова, Марҗый түтәй белән Иван дәдәй Майковлар керәшен йолалары, гореф-гадәтләр турында сөйләделәр, ышану-сынамышлар белән дә таныштырдылар.

Нардуганны хәзер дә бөтен авыл бәйрәм итә икән. Нардуган көннәре 7 гыйнварда башланып китә. Башта балалар йорт саен кереп чыра җыйган. Җыелган утын-чыраларны ятим карчыкларга керткәннәр. Аннан чыра җыярга өлкәннәр чыккан. Нардуганның беренче көнендә «төнге» уникедә тынга чыкканнар. Ягъни берәр кешенең өе янына барып, эчтә нәрсә турында сөйләшкәнен тыңлаганнар, шуңа карап Яңа елның нинди булачагы юралган. Нардуган көннәрендә кеше танымаслык итеп киенеп, ягъни «төрләнеп», өйдән-өйгә кереп, Нардуган теләкләре, такмаклар әйтеп йөргәннәр. 17 гыйнварда инде Нардуганны себеркеләр белән куганнар. 19 гыйнвар – «Качману» көне. Бу көнне су буенда бәке ачалар, адарынган (нәзер әйткән) кешеләр булса, суга чумып чыга. Боздан кисеп тәре ясаганнар. Качману (хачны ману) көнне суык булса, иген-ашлык мул була. Шуңа күрә, көн җепшек торса да, «Бигрәк салкын бүген», – дип, кулларны тын белән өреп җылытырга, сикергәләргә кирәк икән. Бу көнне Качману суы алалар. Качману суы бозылмыйча озак саклана. Аны авырып киткән кешегә дә эчертәләр, әлеге су белән терлекләрне дә имлиләр, дип сөйләделәр.

Питрау 12 июльгә туры килә. Бу көнне көндезге 12 гә кадәр 41 төрле чәчәк җыярга кирәк. Бу чәчәкләрне кайнатып эчкәндә бик күп авыруларга шифасы була. Питраудан соң үләннәрнең шифасы тамырына күчә, кошлар сайраудан, күке кычкырудан туктый, чәчәкләрнең хуш исе бетә. Питрауга тәкә суялар. «Питрау тәкәсе» дигән гыйбарә шуннан килеп чыккан. Әгәр малы булмаса, мичкә

йомырка булса да тәгәрәткәннәр. Ә 2 августтан – Энҗел (Илья) көннән соң су да коенмыйлар.

7 апрель – Чана ташлар бәйрәме, бу – сынаулы көн. Ул көнне салкын булса, чана белән 15 көнлек юлга чыгарга ярый. Атнаның шул көне «кошлар оя типмәс көн» була. Ел дәвамында ул көнне зур эшкә тотынырга ярамый.

**Җөри** авылына Казан ягыннан Җөри дигән авылдан күчеп килүчеләр XVI гасырда нигез салган, дип сөйләделәр.

Җөри урамнары да гына озын урам,
Зәңгәр җефәккәйләр әй сузаек,
Зәңгәр җефәккәйләр дә җитмәс булса,
Асыл җыраулар җырлап ай узаек, –

дип җырлыйлар җөрилеләр.

Начтый түтәй Филиппова керәшеннәрдә кыз ярәшү, дөресрәге кыз урлау, туй йолалары хакында сөйләде. Егет күзе төшеп йөргән кызны урлап алган. Кыз үзен урлаячакларын алдан белмәгән. Кайвакыт кызны йөргән егете түгел, ә бөтенләй уйламаган, тиң түгел егет тә алып киткән. Кызны егет үзенең берәр туганнарына алып кайткан, бу кешеләрне алга таба «әтки», «әнки» дип атый башлаганнар. Ике көннән үз өйләренә кайткач, егетнең әти-әнисе, күчтәнәчләр алып, кызның үзләрендә икәнен әйтергә барган. Туй көнен сөйләшеп кайтканнар. Туйлар савымлы булган. Ягъни егет ягындагы туйга егетнең туганнары, кыз ягындагы туйга кызның туганнары, һәркайсын парлы итеп, күп төрле ризык алып барганнар. Савымга пар каз, пар бәлеш, пар икмәк һ.б. куелган. Кәләш туйда үзе суккан, үзе теккән өч балаитәкле күлмәген кигән. Кияүгә чыкканнан соң поп кәләшнең чәчен икегә аерган. Кияүдәге хатын чәчен бер толым урынына ике итеп үрә башлаган, киеме дә кызларныкыннан аерылып торган. Киеменә, чәченә карап, кияүдәге хатынмы, кыз кешеме икәнен аерып булган. Хәзер исә керәшен туйлары да болай узмый. Кызны алдан сорап, яучылап-сөйләшеп, өйләнешәләр.

Марҗый түтәй Федорованың белмәгән җыры юк. Ул җырлап исәнләште, җыр белән хәл сорады, җырлап озатып калды, үзе шигырьләр дә яза икән.

Иң яшь информантларыбыз – Елизавета Новикова белән Римма Игнатьевалар, 1971 елгылар, икесе дә мәдәният йортында

эшлиләр. Кызлар үртәвечләрдән генә башлаганнар иде, кичке уеннар, Нардуган йолалары, Яңгыр боткасы, Олы аш турында да, авыл тарихы белән бәйле риваять-легендаларны да, җирле мәзәкләрне дә бик яхшы беләләр икән, белгәннәрен тәфсилләп сөйләп тә бирделәр.

**Кумырык** – 41 генә хуҗалыклы бәләкәй авыл. Авыл исеме Комаровкадан үзгәртелгән. Безне бу авылда милли киемнәрен кигән түтәйләр каршы алды. Берсенең дә күлмәге дә, түше дә, чиккән алъяпкычы да югалмаган. Кайбер киемнәрнең тегелүенә гасырдан артык вакыт узган. Үзләре сиксән ягына чыккан түтәйләр әбиләренең кыз чакларындагы киемнәренә кадәр саклаганнар.

Кумырыкта туй җырларын яздырдык. Керәшен туе бер тәүлек – бер кичтән икенче кичкә кадәр – дәвам иткән. Ул башыннан ахырына кадәр кара-каршы җырлауга корылган. Кәләш белән кияүгә, кода-кодагыйга, туганнарга, якыннарга гына түгел, һәрбер ризыкка да атап җыр башкарганнар.

«Мең душлы» **Түбән Ушма** Мамадыштан дүрт-биш чакрым гына урнашкан. Ул – райондагы иң зур авылларның берсе. Кайчандыр авыл яшьләре берьюлы дүрт җирдә кичке уенга чыга торган булганнар. Хәзер дә халык берберсен исеме белән түгел, күбрәк нәсел кушаматы белән белә.

Түбән Ушма – фольклорга бай авыл булып кына калмыйча, фәнгә ике фольклорчыны биргән авыл да. Филология фәннәре докторы, фольклористика фәненең аксакалы Хуҗиәхмәт Мәхмүтов белән филология фәннәре кандидаты, яшь галимә Лилия Ибраһимова-Мөхәммәтҗанова шушы авылда туып үскәннәр.

Авыл халкы гореф-гадәтләрен, йолаларын саклап яши. Риваять-легендалар, бәет-мөнәҗәтләр шактый тупладык без бу авылда.

Түбән Ушмадан ерак түгел Хафиз бабай нигез салган **Күчтем** дигән авыл бар. Хафиз бабай беренче эш итеп мунча салып куйган да, шуның ләүкәсенә менеп: «Ник күчтем, ник күчтем?» – дип утырган, ди. Шуннан авыл Күчтем булып киткән.

Күчтем – борынгы авыл, аның янында изгеләр зираты, изгеләр чишмәсе бар. Безгә әлеге чишмә белән бәйле шактый риваятьләр сөйләделәр. Изгеләр чишмәсен кара елан саклый, диләр. Ул гөнаһлы бәндәләрне изге җиргә җибәрми, юлларына аркылы ята, берәр адым гына атласаң да башын күтәреп, ысылдап кисәтә икән.

Вакытлы-вакытсыз йөрүчеләр изгеләрнең үзләрен дә күргәләгәннәр. Мәсәлән, ахшам вакытында чишмәгә менгән бер хатын изгеләрнең намаз укыган вакытларына туры килгән. Изгеләр чишмәсенең җиде улагы бар. Шул улакның һәрберсенә туктап, су эчеп теләк теләсәң, теләгең кабул була икән.

**Югары Ушмада** шактый гына риваятьләр, уеннар яздырдык. Апалар, яшь чакларын искә төшереп, Аулак өйләрдә, Кичке уеннарда уйналган «Кыр тавыгы», «Ага сулар», «Күбәләгем», «Каеш сугу», «Йолдыз санау» һ.б. белән таныштырдылар. Җырлы-биюле уеннарны уйнап күрсәттеләр. Уеннарның кайберсе җырга-биюгә корылса, икенчеләре күңел ачу, шаяруга кайтып кала. Мәсәлән, «Йолдыз санау» уенында, йолдыз санатабыз дип, беренче тапкыр аулак өйгә аяк баскан яшь егет яки кызга бишмәт җиңе аша су сипкәннәр. Шулай итеп әлеге яшь кеше «инициация» йоласы узган, аны үз араларына алганнар.

Авыл тарихы белән безне Хәйрулла абый Шакиров таныштырды. «Мамадышка барганда, машина булмаса, мин бер дә көтеп тормадым», – дип сөйли ул. Тарихчы, мәктәп директоры, өч буын ушмалыларның укытучысы, скрипкачы, дин белгече... Машина көтеп торса, барысына да өлгерә алмас иде шул.

Бу авылда иң истә калган кеше – мәдәният йорты директоры Таһир абый Вәлиев булды. Юк, өздереп җырлавы да, баянда уйнавы да, риваятьләре белән дә түгел, ә мәзәкләре белән. «Мин мәзәк эзләп йөрим, шуннан ямь табып яшим», – ди ул. Бәлки бераздан Хуҗа Насретдин мәзәкләре кебек, Таһир мәзәкләрен дә сөйли башларлар, һәрхәлдә, берничәсе Фольклор үзәге архивына керде инде.

**Кече Кирмән** – борынгы Болгар шәһәре атамасын саклаган авылларның берсе. Мамадыш районында Кирмәннәр өчәү – Кече Кирмән, Урта Кирмән һәм Рус Кирмәне. Кирмән яки Кирмәнчек шәһәре урыны археологлар тарафыннан тикшерелгән һәм аның болгар чорына каравы исбатланган. Кирмән – ныгытма дигән сүз. Кирмәнчек шәһәре монгол яулары тарафыннан җимерелә. Казан – Чаллы трассасы буенда «Ханнар каберлеге» дип аталган борынгы зират урнашкан. Анда XIV йөзгә караган кабер ташлары табылган. Халык әби-бабаларның борынгы зиратын чистартып, карап тора.

Кирмән елгасы буенадагы изгеләр чишмәсенә изге судан авыз итәргә махсус кердек. Монда дога кылучылар, дөнья гамен

онытып, ял итәргә теләүчеләр өчен махсус чатырлар, урындыклар да эшләнгән.

Кече Кирмәндә утызга якын китабы дөнья күргән әдип Рафаил абый Газизов яши. Ул Кече Кирмән урта мәктәбе директоры да. Рафаил абый авыл тарихын, тарихи риваятьләрне махсус өйрәнгән, белгәннәрен безгә сөйләде. Бүгенге авыл, аның тормышы, кешеләре турында язар, аларның кайгыларын аңлап, шатлык-сөенечләрен тояр өчен Рафаил абый кебек авылда яшәргә, шул кешеләр белән бергә сөенергә, бергә көенергә кирәктер.

**Урта Кирмән** – без эшләгән соңгы авыл. Гүзәлия апа белән Рәкыйп абый Сабировларда орчык өмәсе иде бу көнне. Анда орчык-кабаларын күтәргән апа-әбиләр җыелды. Язып яки теттереп әзерләп куйган йонны өмә белән эрлиләр, каталар, кайберләре бәйли дә башлый. Өмә ахырында идән уртасында тау булып өелгән йомгаклар гына кала. Апалар җырлый-җырлый эшлиләр, билләрен язып, биеп тә алалар, мәзәкләр дә сөйләп җибәрәләр. Өмә буласын ишетеп, Казаннан да кунаклар кайткан.

Гүзәлия апа өмәчеләрне ашлар-бәлешләр пешереп сыйлый. Ризык әзерләгән арада эшләрен мактап, өмәчеләрнең күңелен күрергә дә өлгерә ул. Элек орчык өмәсенә кызлар җыела торган булган. Ә хәзер өлкән яшьтәге хатын-кызлар килә икән. Әмма йола бераз үзгәрсә дә, аның асылы сакланган.

Апа-әбиләр өчен бик әйбәт аралашу чарасы да бит бу. Яшь чактагы җырларны кайда җырларлар, биюләрен кайда биерләр иде алар, орчык өмәсе дә булмаса. Алар да җырламаса, кем җырлар ул җырларны, кем саклар? Орчык өмәсенә әбиләр оныклары – үзләренең җырын отар, эшләрен өйрәнер бәләкәй кызлар белән килгәннәр.

Бай һәм кызыклы фольклор материалы туплап кайттык Мамадыш якларыннан.

Безгә экспедициянең уңышлы эшләвенә ярдәм иткән җитәкчеләргә, мәдәният йорты хезмәткәрләренә, тәмле бәлеш-дурчмаклар белән сыйлаган уңган апаларга бик зур рәхмәт, һәм рәхмәтнең иң зурысы, әлбәттә, информантларыбызга. Аларның түбәндә бирелә торган текстларында сөйләм үзенчәлеге саклана.

## Миңкәй карак

Миңкәй карак – Чернов Миңкәй тумышы белән хәзерге Кукмара районына керүче Тәнкин дигән авылдан була. Ярлы крестьян гаиләсендә туып үскән егет. Аны соңгы елларда гына оныттылар, сөйләми башладылар. Булган кеше була ул. Кеше үтереп йөрми, кешегә зыян салмаган. Шәкүр карак бит ярлыга да, байга да тигән. Бу ярлыларга тимәгән.

Миңкәй карак бер кайтканда урманга кереп качкан. Өч авыл халкы эзләгәннәр, таба алмыйча кире кайтканнар. Берничәсе, Миңкәй монда юк икән, дип, урманда калган. Миңкәй тегеләрне ярган инде.

Бервакыт Кукмарада нәчәлник милициягә кереп ат сорый бу. «Мин ГПУдан», – дип. Алтынбаев дигән кеше була нәчәлник милиция. Бирә атны. Бер атнадан хәбәр килә: «Атың шунда. Рәхмәт. Миңкәй», – диелгән була.

Ачуы килгән кешеләргә хат җибәргән. «Шул көнне өең яна», – дип.

Саклыйлар өйне. Әмма саклап бетерә алмаганнар. Любой җирдә акчаны чутлата, кәгазь язып алып чыга. Тота алмаганнар. Аннары юкка чыга ул.

## Бичура

Су анасын күргәнем юк. Ну җенне точно үзем күрдем. Элек сәкедә йоклый идек. Бик эсселәп, бишмәтемне ачып җибәрдем. Аяк очында бер карчык җеп эрләп утыра, җерләгән тавышы да чыга.

Минем малай вакыт. Ураза вакыты, әни ураза тота. Әни шуның яныннан үтеп, ут яндырырга китте. Теге карчык ут янганчы утырды, ут янгач, каба-орчыгын алып, мич артына кереп китте. Киеме ак ук түгел, искерәк аксылрак кием иде.

## Җеннәр

Мин «скорая помощь» машинасында эшләдем. Дежурить иткән вакытта бер иске йортта тордык. Шунда, бер урынга яткач, йоклап булмый. Ятуга, ишек ачылып китә дә, алты-җиде бәләкәй малай керә. Янга да киләләр, төрле хайван кыяфәтенә дә керәләр. Берәр ел шул йортта яшәгәч, ияләшкәч, мин кайвакыт

боларга әйтәм: «Бүген бик ардым», – дип. Ул көнне тынычрак кылананалар.

Бервакыт морҗа агартучы бер карт кунарга керә монда. Бисмилласын гына әйтәсе була. «Кабыргага, муенга китереп төрттеләр. Аяк-куллары тояк кебек», – дип сөйли.

Олы кеше булып та кергәли иделәр.

*Сөйләүче: Фәйзуллин Мәснәви*
*Фәхретдин улы (1927 елгы).*
*Югары Тәкәнеш авылы*

## Күз тиюдән имләү

Акаеп караганнарга ак балык кылчыгы,
Челәеп караганнарга чи балык кылчыгы,
Текәлеп караганнарга тигәнәк кылчыгы,
Карурманның кара чыршы ботагы,
Кара..............
Бетте-китте.
Тугыз – тузып китсен, тьфү-тьфү,
Җиде – җилгә китсен, тьфү-тьфү.
Биш –- бизеп китсен, тьфү-тьфү,
Өч – очып китсен, тьфү-тьфү,
Бер – бер дә юк, тьфү-тьфү,
Бүтән күз тиеп тормасын.
Әпсен-төпсен, бетсен-китсен.

*Сөйләүче: Воробьева Анна*
*Сергеевна (1930 елгы).*
*Комазан башы авылы*

## Бичура

Безнең авыллар Түбән Ушмыда кунарга кергәннәр. Хуҗа әйтә, ди, иртә белән мин сине уятырмын, бер кызык күрсәтәм, ди. Иртә белән уята. Чыгып койма ярыгыннан карап торалар. Чиләк-көянтә аскан бер бик чибәр кыз суга төшә. Хуҗа әйтә, «Кызлары юк аларның, бу бичуралары», – ди. Баеп беттеләр инде, ди.

*Сөйләүче: Осипов Илья*
*Николаевич (1940 елгы).*
*Комазан башы авылы*

## Туй

Керәшеннәрдә туй сигезләрдә башлана, икенче көннең кичке сигезләрендә генә кайтып китәләр. Урлагачтын кызны өйгә алып кайтмыйлар, туганнарга алып кайталар. Аларны «этки-энки» диләр, ата-анадан бер тары бөртеге генә ким, диләр. Яшь килен бер кич кунгач, су юлы күрсәтергә төшкәннәр. Аннары он иләгән, идән юган. Аннары коймак пешерткәннәр.

*Сөйләүче: Ширыкова Анастасия*
*Прокофьевна (1924 елгы).*
*Юкәче авылы*

## Килен сөйләштерү

Керәшеннәрдә килен башта биата белән сөйләшмәгән. Тел яшергән. Иренең ир туганнары белән дә сөйләшмәгән. Биата күпмедер вакыттан соң акча биргән, аңа җавап итеп кулъяулык яки җанчык (янчык) бирәсең, шуннан соң сөйләшә башлыйсың.

*Сөйләүче: Филиппова Анастасия*
*Васильевна (1924 елгы).*
*Җөри авылы*

## Үртәвечләр

Бардым Җөригә,
Кердем бер өйгә.
Утырттылар катык,
Бирмәделәр кашык.
Килеп керде Ычтапан
Кесәсендә стакан.
Килеп керде калмык,
Ашамыйча калдык.

Ылыя – пич башлары кылыя.
Юкәче – сиңа бер үлгән мәче.
Кумырык – ыштан төбе умырык.

## Тәпи чишмәсе

Бер хатынның баласының аягы авырта торган була. Аягын шул чишмә суында югач бала терелә. Хәзер бу чишмә буенда Чәчәүнек (Часовня), анда адарынган кешеләр бара.

## Йөзек салу

Йөзекне Нардуган атнасында, 6-сы, 13-е, 18-е төнлә салалар.

Бер гаиләдән олы баланы, икенче гаиләдән уртанчы баланы, өченче гаиләдән төпчек баланы алып, суга барасың. Суны төпчек бала чәнти бармагына элеп кенә алып кайта. Суга барганда да, кайтканда да сөйләшергә ярамый. Чиләкне томалап алып кайталар. Кызлар җыелган була. Кече бала бармагы белән суны болгата.

Башта илгә атап атлы йөзек салалар:

Ындыр баганасы,
Урыс алашасы,
Иген игәсе,
Ипи ашыйсы, –

дип җырлыйлар.

Атлы йөзекне салгач, тынлап торалар, әгәр йөзек тыныч кына төшсә, илдә тынычлык була, әгәр тавышланып төшсә – илгә бәла-каза киләсегә.

Аннары йорт-җиргә атап һәр кеше үз йөзеген сала. Һәр йөзекне алыр алдыннан аерым җыр башкарыла. Өченче тапкыр салганда мал-туарга атап салалар. Соңыннан ата-анага, туганнарга һәм иң соңыннан кешенең үзенә атап йөзек салалар. Нинди җыр башкарылуга карап, киләчәкне юрыйлар.

## Яңгыр боткасы

Карчыклар әйткәч, бала-чага өй саен кереп, әйтеп-өндәп чыга. Һәрбер кеше, күкәй, он, май, ярма алып изге чишмә буена килә. Чишмә буенда мал чалалар. Корбанга сарык кирәк. Адарылган кеше булса, ул алып килә. Тавык алып килүчеләр дә була. Су буена зур казан асалар. Безнең авылда җиде чиләкле казан асалар. Башта итне пешерәләр. Аннары бөтен нәрсәне кушып ботка пешерәләр. Ботка пешкән арада әбиләр келәү әйтәләр. Ботка пешкәнче бөтен кеше бит-кулларын юа, кайберәүләр бөтен киемнәре белән суга кереп ята. Су бөтен кешегә тиергә тиеш. Килмәгән кешегә, өенә барып, урамда туры китереп, су сибәләр. Берәр гөнаһлырак кеше булса, әбиләр «аны калдырмагыз», – дип, махсус әйтеп тә җибәрәләр. Андый кешене койма артларына качып көтеп торып, барыбер су сибәләр. Аннары ботка ашыйлар. Аннан соң кичкә кадәр су сибешәләр. Яңгыр яумый калмый.

## Олы аш

Яңа нигезгә күчкәч, авырса берәрсе, малы мантымаса, йорт иясе яратмый, дип, олы аш уздыралар. Алдагы нигез хуҗаларыннан да берәүне чакыралар. Корбанга сарык чалалар, аннары балык «суялар», аннары күкәй «суялар» (әзрәк ватып куялар). Сарыкның башын, балык белән күкәйне кыздырып табынга чыгаралар.

Олы ашка килүче һәр кеше табак белән конфет, коймак, ипи һ.б. (ризык төрләре так санда булырга тиеш) алып килә. Хуҗа кеше шул табакларга салып җибәрер өчен дурчмак, юка, шишара һ.б. пешерә. Карчыклар укый. Өстәлне каплап торалар. Карчыклар укып бетергәч кенә ачалар.

Кеше алып килгән әйберләр икенче өстәлгә куела. Укып бетергәч, өч төрле әйберне кабып карыйлар, өч корбаннан да авыз итәләр, шуннан соң гына ашый башлыйлар. Корбан итен ашагач, сөякләрне бер чиләккә җыялар. Аннары мал чалган кеше – ул якын кеше, туганнары була, чиләкне муенына сөлге белән асып, авылның сөяк озата торган җиренә алып китә. Шунда алып килгән ризыкларны ашый. Сөякләрне сөяк озата торган җиргә сала. Кире кайтканда юлда чиләккә берәр әйбер сала, мәсәлән, көзен – миләш, кышын кар да ярый, яки ашлык һ.б. Өйдә калучылар ул алып кайткан әйберне авыз итә. Кунакларны озатканда хуҗа һәр табакка бер дурчмак, бер юка, бер шишара сала.

## Җылак бичура

Ташлыярдан Кумырыкка берәү килә. Ылыядан үткәндә бер кара эт иярә. Ул берәүгә ашка килә. Теге эт ияреп керә дә, өйдә өстәл астына кереп китә. Шул көннән өй тынгысызлана. Күршеләрен чакыралар төнгә, мылтык белән. Берзаман хуҗалар уянса, теге күршене мендәр белән томалаганнар, буылган теге. Көчкә коткарганнар. Шуннан бу хуҗалар икенче нигезгә күчәләр.

Шуннан теге эт яңадан Ылыяга кайта, Степан дәдәйләргә. Степан дәдәйләр янгач, сарайларында бик каты җылый. Сарайны ачып карыйлар, бернәрсә дә юк. Өй янганга шул бичура җылаган икән. Хәзер дә бар, кара чәчле хатын-кыз кыяфәтендә күренә икән.

## «Кара йөзләр»

Бик күптән булган фаҗига инде бу. Түбән Шүләнгердә мулла бер кызга кызыгып йөри. Карт кеше була инде. Кыз муллага чыгарга теләми. Шуннан мулла бу кызның бер егет белән сөйләшеп торганын күреп, халыкны җыя, зина кылганнар, дип. Башта ташлар белән бәрәләр. Аннары тау кырыенда икесен дә терелэй күмәләр. Егет берничә тапкыр аңына килеп, кабердән чыкмакчы була, көрәк белән сугып, кире күмәләр. Түбән Шүләнгердә Тирән Үзән дигән урын бар. Шунда күмелгәннәр.

## Кәләш

Ылыяда бик юаш кына Тикын (Тихон) исемле егет булган. Кызлар янына да йөрмәгән, бик оялчан да булган. Шуннан иптәш егетләре бер егетне кыз итеп киендерәләр дә, «Менә, Тикын, сиңа кәләш алып кайттык», – диләр. Теге көмешкәләр куя, өстәл әзерли. Сөенә инде. Песине тезенә утыртып, сыпырып утыра икән. «Менә песи, җиңгиле дә булдык. Менә песи, җиңгиле дә булдык», – ди икән. Егетләр: «Ул да эчә», – дип, «кәләш»кә дә эчертеп торалар, бер заман теге «Кәләш» исереп егыла.

* * *

Питр бабай карчыгы Кәтри түти белән урманга утынга баралар. Питр бабай юан бер ботакка менеп утыра да шуны чаба башлый. «Кәтри, кит, олы ботак төшә», – дип кычкыра да, үзе дә ишелеп төшә.

*Сөйләүче: Новикова Елизавета*
*Александровна (1971 елгы).*
*Җөри авылы.*

## Өч солдат кабере

Революциядән соң була бу хәл. Түбән Ушмыга Комазанга юл күрсәтүне сорап өч солдат керә. Матур итеп киенгәннәр, аякларында ап-ак ыштыр, чабата булган үзләренең. Байлар болар артыннан баралар, авылны чыгып бераз баргач, тотып алалар. Тегеләр ялынганнар, тимәгез, дип. Үзләреннән кабер казыталар. Өчесен дә атканнар, күмгәннәр. Соңрак кабер өстенә бер каен утырталар. Үсә

төшкәч каен өч кәүсәле булып үсеп китә. Хәзер бу урынны өч солдат кабере дип атыйлар. Карчыклар анда дога кылалар.

## Никах

Никахны егет ягында укыталар. Башта кыз сорарга баралар. Шунда никах көне билгеләнә. Никахның алдагысы көнне егет үзенең әти-әнисе, туганнары белән кызны алып кайта. Кызны иптәш кызлары, әти-әнисе, туган-тумачасы озата килә. Аларны өстәл әзерләп көтәләр. Күршеләре дә керә. Башка җирләрдә яшәүче туганнары да керә. Кызның туганнары: «Ачуланмагыз, өегезне карарга килдек, иртәгә бизәрбез», – диләр. Өйнең размерын алалар (пәрдәләр, челтәрләр элəр өчен ишек-тәрәзә размерларын). Кызны озата килгән берәр иптәш кызы аның белән куна.

Иртәгесен егет белән кыз муллага баралар. Мулла ничәдә киләсен әйтми, «Ут алгач», – ди. Ут алгач, туганнары җыела, мулла килә. Бала-чаганы өйдән чыгарып җибәрәләр, ишек-капка бикләнә. Бер тавыш та булырга тиеш түгел. Кыз яулыктан, егет кәләпүштән була. Туганнары кызның бирнәсен алып килә. Никахка бабайлар килә. Хатын-кызлар кодачалар ашына килә.

*Сөйләүче: Җиһаншина Нурания*
*Әгъләметдин кызы (1941 елгы).*
*Түбән Ушма авылы*

## Хозыр Ильяс

Бабай белән әбинең балалары тормаган. Боларга бер ак киемле кеше кергән. «Сезнең хәсрәтегез зур икән, балаларыгыз тормый икән, менә улыгыз туар, исемен Бабанияз кушарсыз», – дигән. Әмма әби белән бабай исемне онытканнар. Туган бала тагын үлгән. Шуннан теге юлаучы тагын кергән, теге исемне язып калдырган. Яңадан уллары туган, Бабанияз дип исем кушканнар. Безнең фамилия шулай килеп чыккан.

## Кармыш чишмәсе

Берәү урманга барган булган. Бәләкәй генә су чыгып тора икән. Ятып эчкән дә суны, кайткач хатынына сөйли икән: «И-и бер чишмә күрдем», – дигән. «Ятып, ятып эчтем, суы кар кебек

салкын, мыш-мыш итеп эчтем», – дигән. Кармыш шуннан килеп чыккан диләр.

*Сөйләүче: Бабаниязова Кәримә Зәйнәгыддин кызы (1929 елгы). Югары Ушма авылы*

* * *

Эш белән Казанга киттек. Юлда барганда шофер бик авыр хәлдә калдырды. «Тукта, мин дә сине кызык итәм әле», – дип уйлыйм. Казанга барып җиттек. Кунарга кердек бер әбигә. Әбигә әйтеп куйдым: «Бу иптәшнең начар гадәте бар. Төнлә астын юешли, уяткалап торырга кирәк», – дип. Әби тегене сәгать саен уята икән: «Бар, улым, чыгып кер, тартып булса да кер», – дип. Шофер егет ник уятканны аңламый, «Чыкмыйм мин», – дип томаланып кына ята да, әби яңадан уята, ди. Мин күрше бүлмәдә йокладым рәхәтләнеп.

## Стоматолог

Күрше авылга килен булып төшкән бер хатын бәләк белән бәреп кайнатасының тешен сындырган. Авыл халкы моңа «Теш врачы» дип исем биргән инде. Күрше егетенең теше сызлый. Чыдар хәле калмагач миңа кергән: «Әйдә, Таһир абый, стоматологка алып бар әле», – ди. «Киттек», – дим. Мотоциклга утыртып алып киттем тегене. Алып бардым теге хатынга. «Бар кер, фәлән апа, тешемне алып бир әле дип сора», – дип өйрәттем. Кергән бу, әйткән өйрәткәнчә... Ярый әле мотоциклны борып, хутлап куйган идем.

*Сөйләүче: Вәлиев Таһир Муллакамил улы (1962 елгы). Югары Ушма авылы*

## Мөнәҗәт

Газраил килер бер көн фәрман белән,
Газиз тәнне алыйм, дип, шәриф җанны алмак өчен.
Төрле-төрле хәйлә корсаң, булмас дәрман
Газраилдән котылып калмак өчен.

Әҗәл килер сезгә бер көн, и кулларым,
Куәт китәр, тота алмас буыннарым.
Кабер булыр минем ахыр урыннарым,
Кыяматтән кайткан көнне көтмәк өчен.

Җаным сездән чыга башлар, аякларым,
Кара көяр сездә булган тырнакларым.
Сөйләшерләр кәфен, кирәк-яракларым,
Гүрстанга мине илтеп куймак өчен.

Сине үлсәң, кабык өстендә юарлар,
Аннан алгач, кәфен үзәрә куярлар.
Күлмәк салып, кәфен кидең, и бичара,
Ахирәтнең мәйданына бармак өчен.

Ук-керфекләр, матур кашлар төшәр бер көн,
Бу хәлләрне килмәс, димик, килер бер көн.
Үлем хәлен искә алыйк, и дусларым,
Барчабызга киләчәген белмәк өчен.

Туганнарың карар сине кәфен ачып,
Күзләреннән канлы яшьләр сачеп-сачеп.
Фәрдә артында елашырлар качып-качып,
Күрешүнең актык көне булган өчен.

Гомеребез безнең һәр көн үтеп бара,
Сарай-мизан хәлләрене уйлап кара.
Еласаң да, яшең чыкмый, и бичара,
Төрле-төрле мәшәкатьләр баскан өчен.

Алып чыгар сине өйдән яшьләр-картлар,
Менгән атың күп аяклы җеназа атлы.
Күтәргәннәр кызу-кызу аяк атлар,
Сине илтеп гүрстанга куймак өчен.

Сине күмгәч бар кеше дә кайтып китәр,
Мөнкир-нәнкир җавабына вакыт җитәр.
Шул вакытта рәхим кылгыл, и Илаһым,
Сөальләргә җавапларны бирмәк өчен.

Мөнкир-нәнкир катыйгълык берлә сөаль сораса,
Әгъзаларым шаһит булып хәзер торса,
Шул вакытта барча тәнем тетрәр минем,
Сөальләргә җавапларны бирмәк өчен.

Бозыклыкка алып барыр усал ният,
Рәхмәтең күп, рәхим кылгыл, и Илаһым,
Һәр көн егълап тәүбә итик, и дусларым,
Җәннәт эчрә хак мидарын күрмәк өчен.

Тәүбә кылмый үлеп китсәм ни кылаем,
Тәүбә кыларга кушкан безгә, и Ходаем.
Сөяльләрем хәсәнәт булса иде,
Хозурыңа ак йөз белән бармак өчен.

*Түбән Тәкәнеш авылында яшәгән*
*Камалиева Зәкиябану*
*Гайнулла кызының (1908–1997)*
*дәфтәреннән*

# ТӘН АЗЫГЫ – ИКМӘК, ҖАН АЗЫГЫ – ХИКМӘТ

## (Татарстанның Мамадыш районында җыелган фольклор үрнәкләре)

*Лилия Мөхәммәтҗанова*

Мамадыш төбәге гомер-гомергә татар галимнәрендә зур кызыксыну уята. Халык иҗаты белән кызыксыну, фәнни эзләнүләр алып бару максаты үз чорында бирегә Казан фәнни үзәкләреннән Хәмит Ярми, Халидә Гатина, Хуҗи Мәхмүтов, Шәйхи Маннур, Марсель Әхмәтҗанов кебек галимнәрне, язучыларны китергән. Биредә табылган борынгы әдәбият җәүһәрләре, шушы төбәктә яшәгән һәм гомер кичерүче шәхесләр иҗаты, фольклор материаллары матбугатта, фәнни җыентыкларда урын ала, гыйльми үзәк фондларында, архивларда тасвирланып, фәнни әйләнешкә кертелә бара.

Халык үзе дә элгәрләре тормышына, үткәненә, мәдәни ядкарьләренә беркайчан да битараф булмаган: галимнәр белән бәйләнешкә кереп, иске кулъязмаларны, бәет-мөнәҗәтләрне, авыл тарихына мөнәсәбәтле кыйммәтле мәгълүматларны, шушы төбәккә хас мәдәни кыйммәтләрне җыйнап, фәнни архивларга тапшырган. Мондый эш белән кызыксынган кешеләрнең исемнәре дә онытылмый. Мәсәлән, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә Мамадыш районының Габдулла Хәмитов тарафыннан 1972 елда тапшырылган, Түбән Ушма һәм кайбер башка авыллар тарихына мөнәсәбәтле гарәп язулы кулъязмасы саклана.

Чыннан да, тарихыбыз тирәнрәк ачылсын, мирасыбыз тулылансын, мәдәниятебез баесын өчен галимнәр һәрвакыт халык ярдәменә мохтаҗ. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәренең татарлар яшәгән төбәкләргә оештырыла торган комплекслы фәнни

экспедиция маршрутларының берсе итеп янә дә Мамадыш районын сайлавы һич тә очраклы түгел. Миллилекне саклавы белән җәлеп итә чал тарихлы Нократ буе, шул ук вакытта борынгыдан килгән традицияләребезнең заман шаукымына ни дәрәҗәдә ияреп үсүе-үзгәрүен күзәтү дә гаять кызыклы.

Халкыбызның рухи җәүһәрләрен туплау эшенә бик күпләр хәленнән килгән кадәр өлеш кертте. Нәтиҗәдә төрле жанрга карый торган фольклор әсәрләре, йолалар, көйләр, борынгы ташъязмалар, сандык төпләрендә ята торган гарәп язулы кулъязмалар, иске китаплар, милли бизәкле сөлгеләр, гомумән, татар халкының мирасына кагылышлы ядкарьләр барланды, теркәлде, язып алынды.

Фән-техника, компьютер заманында дастан көйләүчеләр, әкият сөйләүчеләр күп булмаса да, туган ягы тарихына, туган җире сулышына битараф булмаган, үз авылы турында риваятьләр ишетеп үскән, үз ягының аждаһалы чокырларын күрсәтә белгән, шушы якта гына җырлана торган җырларга гашыйк, үз төбәгенә мөнәсәбәтле бәетләр чыгаручы, такмак-такмазаларга оста әби-бабайлар, апа-абыйлар, рухи мираска битараф булмаган яшь буын гомер кичерә биредә. Уйлап баксаң, нәкъ менә шундый кешеләр милләт сагында тора да, нәкъ менә шулар татарны татар итеп саклый бит.

Мамадыш районы авылларында халык авыз иҗатының рухи энҗеләре шактый мул сакланган. Түбән Ушма, Өчиле (Үсәли), Бөрсет-Сукачы, Күкчишмә, Кече Кирмән, Урта Кирмән, Түбән Тәкәнеш, Шәмәк, Көмешкүл, Дусай авылларында өч дистәдән артык информант белән әңгәмә корырга туры килде. Нәтиҗәдә 60 тан артык топонимик, тарихи һәм мифологик риваять, мифологик хикәят, мәзәкләр һәм мәзәк хәлләр, ышанулар, сынамыш, такмак һәм җырлар, бәетләр, туй йоласы, умай утырту йоласы һәм уен фольклоры язып алынды. Кайберләре берничә вариантта теркәлгән әлеге әһәмиятле материалларда халык хәтере, тарихи хакыйкать, мифологик фикерләүгә үк барып тоташа торган борынгылык һәм халыкчан юмор чагылыш таба. Һәрвакыт һәм һәрьяклап заман сулышын тоеп яшәгән бу төбәкнең тамырлары шуңа ныктыр.

Борынгылык белән тыгыз керешкән, заманча миллилек белән сугарылган хәзерге көн халык иҗаты – киләчәктә үзебезне, милләтебезне, телебезне һәм иманыбызны югалтмаска ышанычлы нигез дә ул. Экспедиция вакытында халык теленнән язып алынган фольклор материалларының кайберләрен укып китик:

## Межа аждаһасы нинди ул?
(мифологик хикәят)

Тумгак башлы, олы авызлы, озын койрыклы, елан шикеллерәк нәрсә булган ул аждаһа. Еланнан азган. Межа чокыры башында яшәгән. Яман авазлар чыгара торган булган. Бервакыт җилләп-давыллап бәк каты яңгыр яуган. Шуннан ак болыт бөтерелгән ул чокыр өстендә. Аннары яңгыр койган. Чокыр өстендәге теге болыт аждаһаны алырга дип килгән болыт икән. Межа башы аждаһасын бөтереп-бөтереп үзенә суырып алган.

Авызыннан утлар өргән аждаһа киткән вакытта, җирне көйдереп киткән. Авыл кешеләренә зыян китергәне-китермәгәне турында сөйләмиләр аның. Ак болыт суырмаган булса, зыян да итәсе булгандыр, ул бөтен нәрсәне дә йота торган булган бит.

Межага барырга курка торганыек. Аждаһа кабып йотар дип. Кап-караңгы тирән чокыр булган ул Межа чокыры. Еланнары белән мыжлап торган. Шул еланнар башта юхага, аннан соң аждаһага әйләнә дип сөйлиләр ие.

*Сөйләүче: Зарипова Сөембикә*
*Гыйлемхан кызы (1938 елгы),*
*тумышы белән Түбән Ушманыкы,*
*Күчтемдә яши*

## Межа аждаһасы
(мифологик хикәят)

Мин ул вакытта бабай белән печән чабып йөргәнем әле. Межа чокырында еланнар бар, дип сөйлиләр ие. Шәп кара урман ие ул төшләр. Янык урманы беткән төш. Янык урманына безнең авылдан Анак юлы, Кыек юл, Авыл башы юлы – өч юл менә. Янык урманын Кирмәннәр, Арташлар Бәләкәй урман дип йөртәләр. Межа чокыры – шул Янык урманы беткән урын инде. Межадан соң Бурсык сырты бар, бер йөрәк урыны кадәр җир, анысы Югары Ушмыга керә. Межадан соң Норма урманнары башлана.

Шул Межа чокыры якты көндә барып, көпә-көндез керсәң дә караңгы була торган ые. Куе урман инде шундый. Шунда Мунчала күле дә бар ые. Юкә кабыгы батыра торган булганнар анда, мунчала ясаганнар. Мыж елан инде ул чокыр. Шул еланнар башта юхага, аннары соң аждаһага әйләнә дип сөйлиләр ие инде. Озак яшәгәне.

Булса да булгандыр анда аждаһасы да, кем белә. Әкияттер инде, үзем күргәнем булмады. Аждаһасы үзе кешегә тими торган булган тиюен. Кешегә зыян сала башласа, аны ак болыт үзенә суырып ала, кешегә зыян иттерми. Гел саклап кына тора торган булган аны ак болыт.

Кеше аягы басмаган караңгы чокыр ые. Советтан аждаһа түгел, әллә нәрсәләр курыкты. Аждаһалар бетте инде ул вакытта ук. Хәзер әрәмәлек инде ул төштә. Арташ ягыннан урманны кырдылар. Бу яктан да такырайттылар. Леспромхоз бар ые. Промышленный основада кырдылар урманны. Аждаһа түгел, урман бете дә юктыр инде анда хәзер.

*Сөйләүче: Ибраһимов Мөбарәкша*
*Ибраһим улы (1931 елгы).*
*Түбән Ушма авылы*

**Башта – юха, аннан – аждаһа**
(мифологик хикәят)

Межа чокырында аждаһа бар дип сөйлиләр ие. Аждаһа – еланның азгыны. Куркыныч нәрсә инде. Кешегә зыян итсә, аны ак болыт суырып ала икән. Ак болытның аждаһаны суырганын күргәннәр. Янык урманы өстеннән күтәреп алып киткән, ди. Болыт суырып алганда аждаһа җирне, игеннәрне көйдереп киткән. Ак болыт аны Каф тавы артына алып барып ташлый, ди. Җил-давыллы көнне әйтәләр ие: «Каты давыллый, аждаһаны суыртадыр», – дип. Аждаһа ак болытка койрыкларын селки-селки суырылып менә торган булган, яман авазлар чыгарып.

Аждаһаны Межа чокырында яши диләр ие инде аны. Берсен суыртып алып китсә, икенчесе җитешкәндер инде. Межа чокырында еланнар күп ие анда. Аждаһа шул еланнар кавеме бит, еланнан, юхадан азганын аждаһа дигәннәр.

*Сөйләүче: Ибраһимов Хатип*
*Ибраһим улы (1939 елгы).*
*Түбән Ушма авылы*

**«Деревянка, железянка, ремешок»**
(мәзәк)

Безнең авылдан армиягә киткән берәүдән имтихан алалар икән. Ату коралының нинди өлешләрдән торганын әйтеп бирергә кушалар моңа. Солдат әйткән:

– Өч частьтан тора, – дигән.

– Нинди частьләр инде ул?

Коралны күргәне, кулына тотып караганы булса да, техник яктан белеме булмаган моның, корал өлешләренең исемнәрен шуңа атый алмаган. Аптырап калмаган үзе, оста җавап биргән:

– Деревянка, железянка, ремешок!

*Сөйләүче: Ибраһимов Мөбарәкша*
*Ибраһим улы (1931 елгы).*
*Түбән Ушма авылы*

## Түбән Ушма ник чукындырылмаган?
(тарихи риваять)

Чукындыручылар Югары Ушмыга чаклы килгәннәр. Югары Ушмыдан соң – Күчтем. Чукындыру чорында Күчтем әле булмаган. Аннары – Түбән Ушмы. Югары Ушмыга хәтле килгәннәр тегеләр. Авылы-авылы белән чукындыра килгәннәр. Әнә Чиябашы – тоташ керәшеннәр, Әҗмәкнең яртысы чукынган. Ишки – олы авыл, аңа кагылмаганнар. Сәртек – бәләкәй авыл булса да, урман кырыендагы авыл, шунда кереп качканнар, чукынмаганнар. Бүгенге көндә Югары Ушмы – мөселман авылы. Әмма теге заманда анда да чукындырулар булган. Шәмси абый сөйләде: «50 нче елларда болынга печән чабарга барганда бер керәшен карты утырып барган боларга. Керәшен Пакшынынннан икәнен әйткән. Малмыжкага баруы икән. Шул сөйләгән борынгы бабаларының Югары Ушмыныкылар булуын. «Шунда безнең әби-бабаларыбызны чукындырганнар. Икенче исемнәр биргәннәр. Кайсы кешеләр урманга качкан чукындырудан. Чукындыручылар киткәч, чукынган халык бу татар авылында калмаган, Пакшынга күчкәннәр. Әби-бабаларыбыз тумышлары белән Югары Ушмыныкы булып чыга», – дип сөйләгән. Керәшен Пакшыны диләр инде ул авылны.

Югары Ушмыга хәтле килгән чукындыруның Түбән Ушмыга зыяны тимәгән. Түбән Ушмы ул чагында олы юл өстендәге көчле, зур авыл булган. Халкы бик гайярь. Кара баганалы авыл булган ул. Авыл Краснай ягыннан, Тимер атавыннан (оста тимерчеләр династиясе яшәгән атау) башланып, Күчтемгә таба Беренче күпергә хәтле сузылган элек. Озынлыгы өч чакрым булган. Мең душлы Ушмы, дигәннәр. Әле меңнән артып киткән чаклары да булган.

Алай да чукындырып йөрүчеләр бер кагылган безнең авылга. Шулай дип сөйлиләр. Авылга килеп кергән чукындыручыларны Түбән Ушмылар кыйнап үтергән. Чокыр казып, күмеп тә куйганнар тегеләрне. Авылдан читтә күмгәннәр. Артларыннан эзләп килүчеләр сораган:

– Шундый-шундый кешеләр йөрдеме монда, күрдегезме? – дигәннәр инде.

– Күрдек, – дигәннәр, Түбән Ушмылар әйткән. – Фәлән-фәлән төстәге фәлән чаклы кешеләр керде монда, – дигәннәр.

– Кая алар?

– Әнә тегеләй таба киттеләр алар, – дип, Түбән Ушмы юнәлешеннән кыйбла якка таба төртеп күрсәткәннәр – Шуннан эзләгез кирәк кешеләрегезне, – дигәннәр. Бүтән чукындырырга дип килеп борчымаганнар Түбән Ушмыны.

*Сөйләүче: Мөхәммәтханова Флёра*
*Зиннур кызы (1939 елгы).*
*Түбән Ушма авылы*

**Үгез мөгезендәге Җир һәм Алып-кешеләр**
(мифологик хикәят)

Безнең әтиләр сөйли торган иде. Аларга борынгы кешеләр сөйли торган булган. Үгез Җирне менә шулайттырып (ике кулын башы өстенә күтәреп, бармакларын тырпайтып күрсәтә) күтәреп тора иде дип сөйләгәннәр. Мөгезенә куеп. Үгез үзе нәрсәдә торгандыр, белмим. Җир үгез мөгезендә торган, яссы булган. Әкият инде бу. Бездән көлә торган булмасын. Элекке кеше сөйләгән бит. Элек аның кешесе дә Алып булган. Әти сөйли торган иде: «Менә бу елгаларны атлап кына чыкканнар», – дип шул Алып-кешеләр. Алар унбиш метр озынлыкта булган».

*Сөйләүче: Мөхәммәтханова Флёра*
*Зиннур кызы (1939 елгы).*
*Түбән Ушма авылы*

**«Шул кирәк сиңа!»**
(мәзәк)

– Кая синең бер аягың? – дип сораган 5 яшьлек бер бала бер аягын сугышта өздереп кайткан сугыш ветераны Мөхәммәтгалиев Әбдерәкыйптән (кушаматы – Тәк-тәк).

– Сугышта өздердем, олан, сугышта, сугышта! – дип аңлата икән моңа Әбдерәкыйп. Бала, беркавым башын кыңгыр салып ветеранга карап торган да, әйтеп куйган:

– Шул кирәк сиңа, сугышып йөрмәссең!

*Сөйләүче: Ибраһимов Хатип*
*Ибраһим улы (1939 елгы).*
*Түбән Ушма авылы*

**Рыбный пирог – балык бөккәне**
(топонимик риваять)

Болыннарның һәрберсенең үз атамасы бар аның. Мамадыш районы, Красная Горка авылына караган болынның иң зур аланы Рыбный пирог дип атала. Тип-тигез олы болынлык ул. Вятканың ары ягында. Безнең авыл болыны – елганың бу ягында.

Элекке вакытта болыннарны бүлеп биргәннәр. Землямер бүлгән. Һәр кешенең җүнлерәк урыннан аласы килгән бит инде. Землямерга һәр авылдан старшийлары килә, моңа бүләк ташыйлар икән. Татарлар сарык тәкәсе суюны зур байлык санаган. Безнең авылдан шундый бер старший киткән землямерга, тәкә суеп, тегене сыйларга дип.

Шуннан хәзер җирләр ала башлагач, карасалар, кайда чытырман арасы, кайда агачлык-таллык, адәм үтеп керә алмаслык сазлык – бәләкәй-бәләкәй урыннар эләккән, ди, татарларга. Безнең авыл болынының тоташ олы җирләре, чыннан да, бик сирәк. Татарларның тәкә тиресе хәтле болынлыклары землямерга шул үзләре биргән тәкә аркасында имеш.

Краснай урыслары землямерга балык бөккәне пешергәннәр, эченә алтын акча тыкканнар, ди. Боларга җир бүлеп бирергә килгән землямер үлчәми дә, ди, ашый-эчә, сыйлана икән. Балык бөккәнен ашаган саен алтын тәңкәне кесәсенә тыгып куя, ди. Исергән. Киткәндә Краснай урыслары әйткәннәр:

– Син, Фәлән Фәләныч, җирне бүлмәдең бит әле. Безгә җир бирәсеңме? – дигәннәр.

Вятка елгасыннан ары таба – Анзиркага (чиркәүле бәләкәй генә авыл ул) җиткәндә (шуннан башлана инде урыс болынлыгы), теге землямер Краснайга таба карап, кулларын җәеп егылган да:

– Бирәм. Менә моның бөтенесе сезгә, – дигән. – Красная Горка, – дип кычкырган. Шуннан иге-чиге юк тигез болын Краснай

болыны булып киткән (соңыннан «Мамадыш» совхозы булды ул). Урыс болыны дибез инде моны. Ул урыннарны әле дә шул землямер ашаган балык бөккәненә бәйләп, Рыбный пирог дип йөртәләр. Менә шулай эчендә алтын тәңкәле балык бөккәне болын исеменә әйләнгән. Шул атама сеңеп калган. Рыбный пирог – суның теге ягындагы зур болынлык, Краснай урыслары болыны була инде.

*Сөйләүче: Ибраһимов Хатип Ибраһим улы (1939 елгы). Түбән Ушма авылы*

## Фәрит комбайны
(мәзәк хәл)

Түбән Ушмыда бәк текә Уйгын тавы бар. Мамадыш басуына барышлый юлда ул. Уйгын әрәмәлеге янында. Басуга барганда Салих абый улы Фәриткә (Фәрит – мәктәп директоры) шуннан комбайны белән менәргә туры килә икән. Мәктәп укытучыларын да комбайнга утырталар җәй көне.

«Ничек мендең, Фәрит, бу текә Уйгын тавын?» – дип сорыйлар икән паркта. «Мендем инде шунда, менеп җитә алмаган җирләрендә төшеп эткәләдем дә», – ди икән Фәрит.

*Сөйләүче: Ибраһимов Хатип Ибраһим улы (1939 елгы). Түбән Ушма авылы*

## Күкчишмәдә пар чишмә
(риваять)

Күкчишмә авылының халык телендәге исеме – Ташлык. Басуда ташлык монда, шуннан аталган Ташлык дип. Монда чишмәләр күп булган, шуңа бу тирәләрне Күп чишмә дип тә атап йөрткәннәр. «Күп чишмә»дән «Күкчишмә»гә әйләнгән аннары авылның исеме.

Корылык елны чишмәләр кипкән. Күкчишмә янындагы Корама елга да кипкән. Шуннан халык аны Кол-корама дип атый башлаган. Кол-корама үзәненнән өстә – Күкчишмә тавында пар чишмә бәреп чыккан шул елны. Корылык елларында пар чишмә халыкны сусаудан коткарып калган. Шуңа аны Изгеләр чишмәсе дип

атыйлар. Чишмәләр, тип-тигез булып янәшә әз генә ара агалар да, бертигез ара узып, кабат җир астына төшеп югалалар. Суы шифалы, тәмле.

*Сөйләүче: Габдрахманов Ильяс Габдрахман улы (1932 елгы). Күкчишмә авылы*

## «Бармам да әле!»
(мәзәк хәл)

Безнең авылның бер хатын кер юа икән. Кер юу порошогы беткән дә моның, ирен кибеткә җибәргән. Көтә икән иренең порошок алып кайтып биргәнен, көтә икән. Бик озак көткән. Инде ире кибеттән әйләнеп кайтыр вакыт әллә кайчан үткән. Хатын, инде кайткандыр, дип, ишек төбенә чыккан. Чыкса, ире ишек төбендә ботинка бавы бәйләп утыра, ди. Сорый икән бу иреннән:

– Бигрәк озак тордың, кая порошок? – ди икән.

– Әгәр дә күп сорасаң, бармам да әле! – дип җавап биргән, ди, ире, үпкәләп, авызын бөреп. Китеп тә өлгермәгән булган әле кибеткә.

*Сөйләүче: Шиһабиев Роберт Дәүли улы (1955 елгы). Өчиле (Үсәли) авылы*

## Умай утырту йоласы

Умай утырта торганнар ые элек. Бәби тапкан хатынның умае утырсын өчен эчен сыпыралар. Шул умай утырту була. «Умае утырсын!» – дигәннәр. Умай – бала ята торган аналык инде ул. Умай утырта торган кендек әбиләре бар ые, «Умаең утырсын, балакаем!» – дип, эчне сыпыра, юындыра торган ые.

*Сөйләүче: Шакирова Зәйнәп Әбделмәүли кызы (1912 елгы). Рече Кирмән авылы*

## Ияләр турында

Һәрвакыт ияләрне искә алу, аларны әйтеп дога кылу кирәк. Йорт иясе бар ул. Үзем күргәләдем. Кешесыман шәүлә инде ул. Ия риза булмаса, куркыта башлый, тынгысызлый. Болай тими ул кешегә бервакытта да. Бисмилла әйтеп укысаң, тыныч алар.

Абзар иясе малыңны яратмаса, маллар шыбыр тиргә баткан була. Кайбер сарайга сарык батмый, йә кәҗә батмый, сыер батмаска да мөмкин. Бу – ияләр яратмаганга.

(Чәй артыннан кычкырып, озаклап кылган догасында информант «Йорт ияләренең тынычлыгы өчен» дигән сүзләр дә әйтте.)

*Сөйләүче: Сәмигуллина Нурфия*
*Габдулла кызы (1958 елгы).*
*Көмеш Күл авылы*

## Көмешкүл

(топонимик риваять)

Авыл башта Биләтле дип аталган. Биләтле башы дигәне хәзер дә бар. Анысы – керәшен авылы. Биләтле соңыннан (Хрущев заманында) Көмешкүл дип үзгәртелгән. Күле бар иде аның элек. Бәләкәй генә бик матур күл иде. Биләтле башы белән ике арада иде. Ул күлне су күмде тора-бара. Анда буа буалар, су тулып, ләм белән капланды да, күл бетте шулай. Исеме калды.

*Сөйләүче: Юнысов Мидхәт*
*Гариф улы (1938 елгы).*
*Көмешкүл авылы*

## Ачлык елларның кызганыч мәзәге

– Әни, ипи бир әле, тамак ачты, – ди икән бер бәләкәй малай ачлык елларда.

– Әй, балам, ипи юк бит, – дигән анасы.

– Соң, әни, камыр булса да ярый миңа, – ди икән ач бала.

*Сөйләүче: Дәүләтшина Сария*
*Мәгъсүм кызы (1929 елгы).*
*Түбән Тәкәнеш авылы*

## Туй йоласы

Хәзер никах төрлечә була: егет ягында да уздыралар, кыз ягында да. Кем ничек. Элек болай иде: егет кызны алып кайта, икенче көнне мулла чакырып, егет ягында никах укыталар. Кызны җомгага каршы көндә алып кайталар. Алып кайткан көнне кыз егетнең анасы белән куна. Икенче көнне никах, никах укылгач, никах мунчасына җибәрәләр өйләнешүче яшьләрне. Гел шулай булган.

Кызны алып кайткач, берәү өйгә алдан кереп әйтә:

– Парлап кайттык! – ди. Шуннан соң өйдә көтеп торучылар булачак киленне каршы алырга чыга, кайтучыларны өйгә чакыралар. Кыз кергәндә тупсаның эчке ягына мендәр куялар. Егет өенә атлап кергән кыз ике аягы белән дә мендәргә баса. Моңа булачак кайнана әйтә:

– Төкле аягың белән! Исән-имин яшәргә язсын! Йомшак басып йөрер өчен дип салдым мендәрне.

Бал белән май каптыра кызга:

– Балдай тәмле телле бул! Майдай эре! – ди.

*Сөйләүче: Шакиров Ринат*
*Закир улы (1947 елгы).*
*Кече Кирмән авылы*

## «Хамаҗан абый берәрсен сүктеме әллә ул?»

(мәзәк хәл)

Авыл хуҗалыгы белгече агроном Сөләйманның (Мари Сөлие, мәрхүм инде) колагы ишетми. Колак аппараты белән йөри. Көн дә иртәнге алтыда колхоз белгечләре иртәнге нарядка җыела. Көннәрнең берендә Сөләйман шундый нарядка колак аппаратын кими килгән. Югалткан булганмы шунда.

Нарядта колхоз рәисе Мөхәммәтҗан (аны Хамаҗан дип йөрткәннәр) Шакиров (ул да мәрхүм) боларны утлы табада биетеп сүккән. Ул көнне таякның юан башы агрономга – Сөләйманга төшкән. Алай да Сөләйман үзен бик тыныч тоткан, берни булмагандай утырган нарядта.

Нарядтан чыккач, белгечләр идарә каршында тәмәке көйрәтеп җибәргәннәр. Шунда Сөләйман әкрен генә сорый икән:

– Хамаҗан абый берәрсен сүктеме әллә ул, авызыннан төкрекләре чәчрәде, – ди икән.

*Сөйләүче: Мөхәммәтҗанов Әсгать*
*Хатип улы (1969 елгы).*
*Түбән Ушма авылы*

## «Иптәшең кем?»

(мәзәк хәл)

Кызу урак өсте. Колхоз комбайнында – Мусин Закир. Еш кына ватыла икән. Бер ватылып яткан вакытында ул чактагы «Кызыл флаг» колхозының атаклы рәисе Мөхәммәтҗан Шакиров килеп

туктаган моның янына. Закир үзе эшли торган комбайн тирәсендә кайнаша икән, техникасын үзе генә рәтләп ята, ди. Комбайнчының ярдәмчесе дә булырга тиешлекне күздә тотып, рәис сораган:

– Иптәшең кем, Закир?

Теге, сорауны үзенчә аңлап, аптырап рәискә караган:

– Ник, Хәтирәбану бит, Мөхәмәтҗан абый, Хәтирәбану! – дип, беләсең бит инде үзең дә, дигәндәй гаҗәпләнеп, хатынының исемен әйтә икән.

Уттай урак өстендә эш тукталганга болай да ачуы чыккан рәис, тозлап-борычлап кычкырган тегеңә:

– Помощнигың кем дип әйтәм мин сиңа!..

*Сөйләүче: Мөхәммәтҗанов*
*Әсгать Хатип улы (1969 елгы).*
*Түбән Ушма авылы*

**Үсәлинең чукындырылудан калу тарихы**
(риваять)

Үсәлине (Өчилене) чукындырылудан качып килеп утыручылар төзегән. Чукындыручылар янәшә күрше авыл Югары Кыерлыга килеп кергәннәр чукындырырга. Шул вакыт авыл халкы зиратка җыелган булган. Шулар чукындырырга дип килгән кешеләр алдында озаклап тәкъбир әйткәннәр. Тегеләр шикләнеп киткәннәр чукындырмыйча. Югары Кыерлыны озак еллар Тәкъбир авылы дип тә йөрткәннәр шул хәлдән соң.

Ә Үсәли – урман эчендәге авыл, халык урманга качкан, аны шуңа күрә чукындырмаганнар.

Тагын бер янәшә күрше авыл – Владимир авылы. Аның чукындырылганга кадәрге исеме – Кече Бөрсет. Чукындырылудан качып, кайсы – урманга, кайсы – күрше чукынмаган татар авылына китүчеләр булган Владимирдан.

*Сөйләүче: Фазылов Мансур*
*Фазыл улы (1939 елгы).*
*Өчиле (Үсәли) авылы*

**Әлбиттә кертмәсләр**
(мәзәк хәл)

Безнең авылда авыл советы рәисе булып Тәк-тәк кушаматлы Мөхәммәтгалиев Әбдерәкыйп эшләгән 50 нче еллар. Кичке кинога укытучылар балаларны клубка кертмиләр. Элек шулай иде. Сугыш-

тан соң бала-чага күп иде бит ул. Аларны клубка кертү юк. Укытучылар кизү торалар клубта, балаларны куып җибәрергә, кертмәскә.

Клубка агач аяк белән титаклап килеп маташа торган Әбдерәкыйптән, яклау көтеп, балалар сорый икән: «Рәкыйп абый, безне клубка кертерләр микән?» – дип.

– Тәк-тәк, әлбиттә, кертерләр, әлбиттә, кертерләр, тәк-тәк, тәк-тәк, – дип, болардан ансат кына котылып, клубка кереп киткән авыл советы рәисе. Ул шулай «тәк-тәк»ләп сөйләшә торган иде, шуңа кушаматы да – Тәк-тәк. «Әлбәттә» дигәнне дә үзенчә «әлбиттә» дип әйтә.

Клубта кино башланган. Рәис, тәртипне барлап, кире әйләнеп чыгып килә икән, балалар тагын өелешеп килгәннәр моның янына:

– Рәкыйп абый, кертмәделәр бит, – дигәннәр, сөмсерләре коелып.

–Тәк-тәк, әлбиттә, кертмәсләр, әлбиттә, кертмәсләр... – дип, кайтып киткән, ди, Әбдерәкыйп.

*Сөйләүче: Ибраһимова Нурания*
*Гыйлемхан кызы (1939 елгы).*
*Түбән Ушма авылы*

## Дусай изгеләре
(топонимик риваять)

Борынгы вакытта Дусай авылында Мәккәдән кайтып килүче ике кеше үлгән. Мәккәдән хаҗ сәфәреннән кайтып килүләре булган. Безнең этинең атасы (1850 елгы) борынгылардан ишетеп сөйли торган булган моны. Тегеләр чирләп үлгәннәр, ди. Аларның кабере шунда, Дусай зиратында. Аларның каберен изгеләр кабере диләр.

*Сөйләүче: Мөхәммәтханова Флёра*
*Зиннур кызы (1939 елгы).*
*Түбән Ушма авылы.*

## Җәп сукасында
(мифологик риваять)

Берсендә Зират чокыры, Бөкшел чокыры диләр, шунда җәп сукасында идек. Җәп сукасы – туңга сөрү, көздән башкарыла. Язга чыккач, җирне тырмалыйсың да, йомшартып, чәчәсең. 1957 еллар. Дими – атаклы тракторчы, Гариф Димие (Динмөхәммәд) көрәшче кеше иде ул. Мин Димидә плугарь булып йөрим. Хәзерге гидролар

юк иде әле ул вакытта, рульле сукалар иде. Плугарьләр сука көйләп йөриләр иде трактор артыннан.

Дими сукасын тракторга әйбәтләп көйләгән иде. Целиналарда йөреп кайткан, тәҗрибәсе зур. Моның тракторы артына тагылган суканы көйләмәсәң дә шәп сукалый, шундый итеп җайлап куелган. Шуңа күрә Димидә плугарь булып йөргән кешегә сука көйләп йөрисе юк, руль тота идем.

Шул җәп сукасында төн куна эшлибез. Дими төнгә калмады, кичтән кайтып киткән иде. Ул сукада төн кунып ятмый, авылга гүләйт итәргә кайтырга ярата иде. Шундый кеше иде. Ул төнне мин басуда калдым төнгә, минем яшь вакыт, техника төзек булса, эшлибез дә эшлибез. Иртән килә теге. Күзләре шар булган, йөзе – ап-ак. Убыр күргән. Утлы ике шар булып тәгәри, ди. Дими төн кунарга авылга кайтып киткәч, кире килгәндә күргән Убырны. Зираттан чыккан да теге утлы ике шар, үзән буйлап, Ташлавылга таба тәгәрәгән. Убырдырмы, өрәктерме – кешегә тими алар, куркыталар гына. Утлы шар булып күренә дә кешенең күзенә, кеше курка инде.

*Сөйләүче: Ибраһимов Хатип*
*Ибраһим улы (1939 елгы).*
*Түбән Ушма авылы*

## Мифологик хикәят

Җир өч китта тора икән, дип сөйлиләр иде. Өч кит өстендә – бәк зур үгез. Шул үгез Җирне тотып тора икән. Җир читенә барып чыксаң, су башлана. Китлар бетеп, су башланган урынга барып чыккан буласың инде. Китлар иксез-чиксез суда имеш. Җир читеннән су, океан башлана. Бәләкәй вакытта ишеткән нәрсәләр инде бу. Төрле кешедән ишетеп, башка шулай кереп калган. Әкият бит инде.

*Сөйләүче: Ибраһимов Муллахәсән*
*Мөбарәкша улы (1962 елгы).*
*Түбән Ушма авылы*

## Ишки авылының килеп чыгышы турында
(топонимик риваять)

Ишки авылы хәзерге урында булмаган элек. Ишки – борынгы авыл. Ишкиләрнең баштагы авыллары Зур су янында булган. Зур су Чиябашыннан, Сәртектән килә. Бер килен Зур суга барган да суга

батып үлгән. Су анасы алган. Шул хәлдән соң авыл икенче урынга – өскәрәк күчә. Хәзерге Ишки шунда инде. Хәзерге Ишкигә иң беренче күчкән кеше Ишмөхәммәд исемле булган. Аны, исемен кыскартып, Ишкәй дип йөрткәннәр. Шуннан Ишкигә әйләнгән, бу авылны шул кеше исеме белән Ишки дип йөртәләр. Яңа Ишки урыны агачлык булган, кисеп, Ишки авылы ясаганнар.

*Сөйләүче: Мөхәммәтханова Флёра*
*Зиннур кызы (1939 елгы).*
*Түбән Ушма авылы*

## Өч йөрәк
(топонимик риваять)

Балантау астында Караклар юлы белән барганда бер басу бар. Тугызлы басу, диләр. Тугыз гектарлы булганга Тугызлы басу ул. Анда әллә нәрсә юк ул йөрәкләр. Тигез басу. Йөрәкләр тигезсез, авыш басуда була. Безнең авыл басуында күп инде ул йөрәкләр. Авыл үзе чокырга урнашкан бит. Ике йөрәк дигән җир дә бар, Өч йөрәк тә... Күп инде. Чокыр-чакыр саен. Чокырның уелып-уелып кергән җирләре инде, зур басудан ерганаклар белән аерылыбрак тора торган җирләр. Шундый урынны йөрәк диләр.

Югары оч басуында Өч йөрәк дигән шундый җир бар. Шул Айбулат уңайлары инде ул. Өч йөрәкнең соңгысы Кәрим үзәненә тикле бара. Йөрәк-йөрәк җирләр басудан читкәрәк кереп тора. Эшләргә, эшкәртергә җайсыз вак җирләр. Менә шундый өч урынны Өч йөрәк диләр. Исеме шундый.

Өч йөрәк – саташтыра торган урын ул. Трактористлар төнге чәчүдә шул урында эшлиләр дә кире чыга алмый азапланалар, ди. Чокыр белән әйләндереп алынган чәчү җирләре инде ул Өч йөрәк. Йөрәкнең һәркайсына бер урыннан гына кереп була. Төнге чәчүдән чыкканда караңгыда чыгар юлны табып булмый, диләр. Паркта иртә белән сөйлиләр ие: «Таң атканны көттем, чыга алмадым Өч йөрәктән», – дип. Йөрәк тирәли эчтә төн буе әйләнеп йөриләр дә йөриләр, чыгар юл юк. Башны бутый торган урын ул. Көйсез җир инде, анда тракторның гусеницалары салына, техника ватыла, диләр ие. Җендерме, нәрсәдер – башлары буталгандыр инде трактористларның караңгыда. Шул.

*Сөйләүче: Ибраһимов Хатип*
*Ибраһим улы (1939 елгы).*
*Түбән Ушма авылы*

## Ун таяклы уены
(уен фольклоры)

Таяк җыясың да аттырып чәчелеп китә торган итеп тезеп куясың. Бер гөрләүче кала. Уенда 6–7 кеше була. Гөрләүче гөрләп кала. Качучылар төрле җиргә кереп поса, качып бетәләр. Гөрләүче, таякларны күздән җибәрми генә, качканнарны эзләп табарга тиеш. Ул качкан берәрсен эзләү белән мәшгуль булган арада икенче бер уенчы качкан җиреннән чыга да таякларны аттырып җибәрә. Гөрләүче шуңа юл куйса, тагын гөрли. Әгәр таякларны чәчтерми генә бөтен кешене табып бетерсә, уен тәмам була. Качучыларны табу да, таякларны аттырмый саклый алу да гөрләүченең осталыгыннан, җитезлегеннән, тапкырлыгыннан тора. Качкан җирне чамалап:

– Фәлән, син шунда-шунда, качкан җиреңнән чык! – дип кычкырып, әйткәне дөрескә чыкса, теге кеше чыга инде качкан җиреннән. Гөрләүчене бутар өчен тиз генә өс киемнәрен, йә баш киемен алыштырып та кача торган идек. Беренче гөрләүчене санап калдырасың. Болай дип:

Ыргадан, мыргадан,
Мәче йөри елгадан.
Коерыгы кысылган,
Шарт иттереп у...ган.

Йә болай:

Бер, дидем – бермәк,
Ике, дидем – икемәк,
Өч, дидем – өчмәк,
Дүрт, дидем – дүртмәк,
Биш, дидем – бишмәк,
Алты, дидем – алтымәк,
Җиде, дидем – җикмәк,
Сигез, дидем – сикмәк,
Тугыз, дидем – тукмак,
Ун, дидем – уймак.
Чиләк-чиләк каймак,
Ул каймакны кая куйдың?
Җиргә бирдем.
Җир сиңа нәрсә бирде?
Үлән бирде.

Ул үләнне кая куйдың?
Казга ашаттым.
Каз сиңа нәрсә бирде?
Күкәй бирде.
Ул күкәйне кая куйдың?
Мичкә аттым.
Шатыр-шотыр яна калды,
Кунакларым килә калды.
Иске чиләкнең кысасы –
Башына утырып т...сы.

Гөрләүчене таяк тотып та билгели идек. Таякны чиратлап тотасың бөтен уенчылар, таяк башына чыккан кеше гөрли. Икенче, өченче уенга китсә инде, анда беренче табылган кеше гөрли, йә кабат саныйсың.

И кызык уен иде. Мәктәп бакчасында уйный торган идек туйганчы.

*Сөйләүче: Ибраһимова Нурания*
*Гыйлемхан кызы (1939 елгы).*
*Түбән Ушма авылы*

**Авыл көенә җырлар**

Түбән Ушмы, Югары Ушмы,
Уртасында – Никкүчтем.
Йөрәгемнең януына
Әрем кайнатып эчтем.

Кала Ушмы, Кала Ушмы
Зират таулары белән.
Армиягә барсаң иде
Сөйгән ярларың белән.

Армиягә барган идем
Шинель киярмен, диеп.
Ертык бишмәт тоттырдылар,
Ямап киярсең, диеп.

Фаяз китә, Фаяз китә,
Фаяз китә, каласыз,
Йөргән сукмаклары кала,
Сагынганда карарсыз.

Биек тауның башларына
Килгән былбыл атучы.
Атма былбыл, ат сандугач, –
Шул безне саргайтучы.

Исемнәре Нургата,
Агачны – җил,
Суны – дулкын,
Кешене сүз болгата.

Тезелеп кайта сабанчы,
Тезелеп кайта сабанчы,
Сайрый сабан тургайлары,
Шул чакларда ямансу.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Ясәви,
Теләмәгән агачына
Кошта оя ясамый.

*Сөйләүче: Мөхәммәтҗанов Җиһанша*
*Мөхәммәтҗан улы (1929 елгы)*

**Садри бәете**

Бу хәл моннан шактый еллар элек Түбән Шәндер (Түбән Шүләнгер) авылында була.

Ярлы егет Садрислам авылдагы Мәгърүфәне яратып йөри. Алар өйләнешергә, бергә булырга сүз куешалар. Ләкин кызның әти-әнисе туганлашу хакында ишетергә дә теләми. Кызларын көтүче Садрисламга түгел, мулла улына бирергә була исәпләре. Уңган, булган Мәгърүфәне мулла улы да, үземә барыр, дип йөргән була. Әмма Мәгърүфә белән көтүче Садрислам, чишмә буенда очрашып, качып кына сөешәләр, никахсыз бергә булалар, ягъни кыз егеткә ябышып чыга. 1917 елның җәендә боларның балалары туа. Мәгърүфәне алам дип йөргән мулла улы бу хәлгә бик гарьләнә. Шуннан указлы мулла Мәсләви Мәсгудов җитәкчелегендәге төркем ат җигеп Лубьянга мүк алып кайтырга дип киткән Садрисламны юлда сагалап тора, Мәгърүфәне дә өеннән алып чыгып, битләренә корым ягып, урам буйлап йөртәләр. Соңыннан, кабер казып, боларны терелэй җиргә күмәләр. Шушы хәлне кабул итмичә, җир ярылып киткән дип сөйлиләр иде.

Авылда боларга багышлап бәет чыгарганнар. Ике яшь кешенең данын таратмас өчен бәетне ул авылда халыкка укытмаганнар. Бу бәетне Кыерлыга Түбән Шүләнгердән утырмага килгән бер хатын качырып кына алып килә. Бәетнең бер өлеше болай:

Шүләнгер суы буйларында
Тугай читләре үзән,
Мәгърүфәне яр итүдән
Мәңге өметем өзмәм.

Ата-анасы, хәерче, дип,
Сөйгәнемне бирмиләр.
Ярлы хәлен күрмәгәннәр
Минем хәлне белмиләр.

Җомга кичен көтеп алып
Мәгърүфәмне яр иттем.
Сөйгәнем белән кавышып
Югымны да бар иттем.

Лубьяннардан кайтып киләм,
Ялгызым бит, берүзем.
Тыкрыкларга борылуга
Көтеп торган бит үлем.

Салкын җир куеннарына
Өчәү бергә кердек без.
Бәхилләшеп, дөнья белән
Бик тилмереп үлдек без.

*Сөйләүче: Газизова Дания*
*Шәрифулла кызы (1961 елгы).*
*Өчиле (Үсәли) авылы*

## Тәкәнеш исеменең килеп чыгышы турында
(топонимик риваять)

Тәкәнеш елгасы – Ушлан. Электән килгән исеме ул аның. Тәкәнеш исеменең килеп чыгышы шул Ушлан белән бәйле. Тәкәнеш – текә инеш дигәннән килеп чыккан. Ушлан елгасының текә ярына урнашканга Тәкәнеш дигәннәр.

*Сөйләүче: Ибраһимова Лидия*
*Алексеевна (1930 елгы).*
*Түбән Тәкәнеш авылы*

**Шәмәк авылы**
(топонимик риваять)

Бу якларга кешеләр, Иван Грозный вакытында чукындырылудан качып, мишәрләр ягыннан күчеп килеп утырганнннар. Татарстанда Шәмәк дигән авыл өч җирдә бар: Апас, Тәтеш, Мамадыш районнарында.

Безнең елга Арбаш ягыннан төшә. Башы – күрше Кукмара районында. Шуңа да елганың исеме – Башарбаш.

Чишмәләребез берничә. Түбән очта Вакыйф чишмәсе бар. Вакыйф ясаганга шундый исем кушканнар. Бүтәннәренең исеме юк. Әнә Башарбашны чыккач та бер чишмә – анысының суын күз авыруларыннан дәва диләр.

*Сөйләүче: Гыйниятуллин Мөнир*
*Шамил улы (1947 елгы).*
*Шәмәк авылы*

## НОКРАТ БУЕНДАГЫ АСЫЛ ИЛ

*Ильмир Ямалтдинов*

Кәйтәннәрне[1] кәйтән, ай итеек
Җефәккәйне кәйтән итеек, итеек.
Киләсе җыл шушы вакытларга
Уйный гына көллә[2] җитеек,
Ай җаный, асыл безнең ил.

Мамадыш районында чишмәләр күп, сулары – алтын, диләр. Тау чишмәседәй саф күңелле, тарихи нигезләре бер булган үзенчәлекле культурага ия ике этник төркем, татар милләтеннән булган халык яши биредә.

Әлеге район җирлегендә яшәүче халкыбызның фольклоры, авыз иҗаты белән кызыксыну фольклорчы галимнәр тарафыннан 1940 нчы еллар ахырында башлана. 1948 елда хәзерге Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре Хәмит Ярми (җитәкче) һәм Халидә Гатина Татарстанның Тәкәнеш районына (1963 елда Тәкәнеш районы Мамадыш районына кушыла) халык иҗатын җыю, туплау, өйрәнү өчен фольклор экспедициясе оештыралар. 1952 елда әлеге галимнәрне Мамадыш районы янәдән үзенә тарта. Алга таба да Х. Ярми тарафыннан бу төбәк белән кызыксыну кимеми. Монда шуны да әйтеп китәргә кирәктер, аның Тулбай авылы егете, танылган язучы Шәйхи Маннур белән иҗади һәм шәхси дуслыгының, да роле аз булмагандыр мөгаен. Шул төбәк сабантуйлары вакытында, Тулбай – Олыяз аралыгында агач янында төшкән Х. Ярми архивында саклана торган фотолар шуңа ишарәли.

[1] Кәйтән – укадан ишелгән бау.

[2] Көллә –көлә.

Һәм, ниһаять, алты дистә еллардан соң, 2013 елның июнь аенда элеге төбәктә яшәүче милләттәшләребезнең халык иҗатын туплау, өйрәнү Институт тарафыннан махсус оештырылган экспедиция составында эшләгән фольклорчылар – әлеге юллар авторы һәм Л. Мөхәммәтҗанова тарафыннан башкарылды.

Без Мамадыш районыннан халык авыз иҗаты материалларын – риваятьләр һәм авыл тарихлары, мәкаль-әйтемнәр, җырлар, йола фольклорына караган үрнәкләр, халык уеннары, мифологик хикәятләр һәм ышанулар, бәетләр, мәзәкләр язып алдык. Унтугыз авылда булып, кырыктан артык информанттан 240 тан артык берәмлек халык авыз иҗаты үрнәкләре алып кайттык.

Мамадышта яшәүче татарлар арасында иң киң таралган жанрларның берсе – *җырлар.* Йөздән артык җыр язып алынды, нигездә, кыска җырлар. Озын көйләр, бигрәк тә керәшеннәрдә нык сакланган, шулар арасында «Шахта көе», «Озата барма, дускай» да бар. Шактый гына *риваятьләр-легендалар*га тап булдык. Легендалар, тарихи һәм топонимик риваятьләр язып алынды. Алар арасында, борынгы олы гәүдәле Алып бабайларга, Адәмгә, зур сөякләре табылган – Ядегәй халкына бәйле легенда-риваятьләр белән беррәттән, дистәләгән чишмәләргә бәйле риваятьләр дә бар. Бигрәк тә халык күңелен (безнекен дә) яулап алганы – утыз градус эсселектә дә ике-өч көн буена салкын торган – Кыйблага карап чыккан – Бакырчы чишмәсе турындагысы. Ә инде авыл тарихларына (Баскан, Кече Кирмән, Урта Сон һ.б.) бәйлеләре шул авылларда яшәүче милләттәшләребезнең үзләренең тарихларына битараф булмаганлыкларының ачык мисалы. *Мифологик хикәятләр* – ияләр, җеннәр турындагы хикәятләр халык арасында борынгыдан сөйләнеп, яшәп килгән. Халык аларга ышанган, сөйләп буыннан-буынга тапшыра килгән. Бигрәк тә татар халкында киң таралганы – атның ялын үрүче абзар ияләре төнге сәгать уникедән соң мунчада була торган җеннәр хакындагылары. Әйтик, җеннәрдән курыкмыйча, бер дә ак җоны булмаган кара мәчене төнлә мунчада пешереп, барлык йозакларны да ача ала торган күкрәк өсте һәм тамак төбе сөяген булдыру турындагылар да бар; *халык уеннары* – нигездә бу төбәктә дә барлык татар халкы өчен хас уеннарның тасвирланмасы сакланган. Мәсәлән, – түгәрәк уен, «Унике таяк», «Лапталы» белән беррәттән, аулак өйләрдә традицион уйналып килгән «Йөзек салыш», «Йолдыз санашлар» да бар.

Мөнәҗәтләр, бәетләр бик аз. Шулай да, бу якларда татар халкында бик борынгыдан килгән традиция дәвам итә – бәетләр язылa. Яңа Мочалкино авылында Семенова Анфиса Макаровнадан (1941 елгы) «Николай бәете», Кече Кирмән авылында Миңлеханова Роза Мөхәммәтҗан кызыннан (1935 елгы) тормыш иптәше Гыйльфанга һәм улы Раилгә багышланган бәетләр язып алынды. Әкиятләр бөтенләй очрамады.

Мамадыш районы җирлегендә язып алынган, халкыбызның буыннан-буынга, телдән-телгә күчеп килгән фольклор үрнәкләреннән үзем язып алганнарының кайберләрен укучыларга да тәкъдим итәм.

## Мифологик хикәятләр: ияләр, җеннәр турында

**Җен.** Норма зиратында бар. Әллә кем каршы чыккан атына. Атын алып баралмаган.

Арташ юл өстендәге имәннәр янында бер зәхмәт. Анда чамалап йөрегез, ди торганнар ые.

Имеш, җен утырса арбага, ат тарталмый икән. Аны карарга кирәк икән, атның каршына чыгып, дугасы аркылы. Җен шуннан гына күренә икән һәм бик начар итеп сүгенергә кирәк икән җенгә төшеп калу өчен, аннан соң гына төшеп кала икән. Аннары ат алып китә инде.

*Сөйләүче: Газизова Хөснурый*
*Әһлулла кызы (1925 елгы).*
*Кече Кирмән авылы*

**Җеннәр.** Җеннәр менә белмим. Җеннәр менә безнең әтәй сөйлидер ие кара песине, менә бер дә ак җоны булмаган песине төннә мунчада пешерәләр икән. Шуның менә шушындагы (күкрәк өстен, тамак төбен күрсәтә) сөяген ала торган булганнардыр инде. Шул сөяген алгынчы җеннәр гел инде шушылай иттереп сине нитеп торалар икән. Син кулыңны алсаң, пешерә торган әйбереннән алырга торалар икән, җеннәр. Әзрәк кулыңны җибәрсәң, алырга гына торалар икән, дип сөйли иде безнең әти.

Шул әйберне менә Сәләхетдин, бикләә әйбәтләп чумаданыңны, вот чумаданны бикләп куям, ди, яңа йозаклар алып биклим, ди,

вәт шушылай гына иттерә, ача, ди. Иптәше ача. Менә иптәшендә булган, ди, шундый сөяк. Бергә эшләгәннәр алар шахтыда. Ул сөякне төннә мунчада песине кайнатып алалар икән. Төннә сәгать уникеләрдән соң. Бүтән песидә юк, ди. Шул сөяк бөтен йозакны да ачала, ди.

**Җен.** Әти хәзер. Абыйлары булган инде. Алар 6 малай булганнар.

Аулак өй ясыйлар икән. Вот хәзер вот мунчадан себерке белән чиләкне апкайталасыңмы? Безней әтәй әйткән: апкайтам, дигән, киткән апкайтырга. Һәр абыйсы мунча сукмагында зад-перед йөри икән инде хәзер. Шуннан чиләкне алдым, ди, алачыкка (*мунча алдына*) апчыгып куйдым, ди, чиләкне, себеркене алган идем килеп тоттылар, ди, моннан (кулдан). Болай иткәч (борылгач) бу якка качалар, ди. Куллары йомшак кына, ди. Әтәч кычкыргач, әтәй атылып барып төшкән. Төннә бу бәхәсләшеп барырга ярамый икән дип әйтәм икән, ди, мунчага. Акчага бәхәсләшкәннәр иптәшләре белән аулак өйдәге. Абыйсы йөри икән, ди, җеннәр моны буып үтерер микән, нишләтер микән, дип. Бер заман әтәс кыскыргас, әтәй кайтып килә икән чиләк белән себеркене алып. Абый тегеләргә сөйләгән, акчаны икебезгә бүләрбез, дип. Сабан туена булыр акча. Менә шулай булган безнең әтәй белән. Мин шуны мунчага барып алып кайтам, дигән алып кайта алмыйсың икән.

**Абзар иясе.** Абзар иясе бар. Әгәр дә абзар иясе малны яратса, мал җалт итеп торыр, ди. Җаратмаган мал булса, җабыга икән ул мал. Әтәй сөйлидерийе ансын. Яраткан малы булса, ул аны сыпырып кына тора торган була икән мал иясе. Ашаганы үзенә сеңә, таза-сау була. Җабык булмый. Теге яратмаса – җабыктыра икән.

Өй хуҗасы да бар диләр. Ансын белмим инде.

Ялын әйтәләр инде атның җен үрә, дип. Әллә кеше үргән аны. Абзар иясе дип әйтәләр иде инде аны. Үргәнне күргәнем бар. Үрелгән булса, нишләп алай ул. Безгә әйтә торганнар иде, мал янына кергәндә тавышыңны хм-хм дип, абзар иясе малларны куркытмасын дип. Мал янына килсәң, сикереп тора бит ул, курка ул. Шуңа тамак кырыбрак керсәң, мал курыкмый. Өчтән үрелгән була. Бу атны абзар иясе ярата дияләр, үрелсә. Бөтен атны үрми, ди, ул.

Мунчага керсәң:
– Хм-хм. Мунчада кемнәр бар?
– Коерыклы җеннәр бар.
– Балта-пычак кулда бар.

*Сөйләүче: Ибраһимова Нурания*
*Гыйльмехан кызы (1939 елгы).*
*Түбән Ушма авылы*

**Җенле карчык (хикәят).** Безнең авылда бер карчык бар ые. Миңнешәмсебану исемле ие ул. Миннебай карчыгы дип йөртәләр ие аны. Аны җенле дип сөйләшәләр ие. Миннебай хатынының өендә менә фәлән кешене үтереп тыккан баласы, шуның өй кыегында дип әйтеп кычкырган, шулай дип әйтеп кычкырган дигән булып, элек сөйләшкәннәрен без бала чакта ишеткәнем бар. Күрәзәче дә булмаган ул. Җене кычкырган, диләр иде аның. Башка кеше турында әйткән: шул кеше баласын шунда үтереп тыгып куйган, дип.

*Сөйләүче: Миңнеханова Роза*
*Мөхәммәтҗан кызы (1935 елгы).*
*Кече Кирмән авылы*

**Убыр. Җен.** Җен бар дип әйтәләрие ул, әйме. Без ат белән чабышу янәшә-тирәдә була иде берничә авыл. Чәш арты, Ямаш бөтенесе. Менә ут чыгарие ул, әйме, менә гел тәгәрәп барадырие ул, аны җенме, убырмы диләр иде, убырлы, җенле инде шунда. Ул вакытта машина, трактор юк иде. Каян килгән ул ут? Ул бара торгач бетәдерие.

**Абзар иясе.** Факт бар, абзар иясе минем үземнең атның ялын кайсы вакытта гел үреп бетерәдер ие. Яратканмы, яратмаганмы, белмим. Сүтсәң, сүтелеп, сүтмәсәң үзе сүтеләдерие ул. Аны кеше үрми бит. Шул абзар иясе була инде ул әйе. Кайсы көнне ат гел пешеп торадырие, гел суга батып, тирләп. Абзар иясе яратмаган, диләр ие. Атны яратса, чиста тора торгандыр, ә яратмаса йә сулана, йә нишлидер.

*Сөйләүче: Семенов Иван*
*Николаевич (1938 елгы).*
*Ташлыяр авылы*

## Риваятьләр-легендалар

**Алып бабай**. Бәләкәй кеше сука сукалапмы йөри икән. Алып бабай күргән дә «нишләп җир җыртып йөрүче нәрсә микән бу» дип кесәсенә салып алып кайткан, дип, шундый әкиятләр сөйли торганнар иде. Бер белүче карт булган имеш. Ул бездән соңгы заман кешесе, тимә, җибәр, урынына илтеп куй, дип әйткән. Алып бабай хатыны: Җил идем, давыл идем 7 көнгә бер ыштан тегә торганыем, дип әйтә икән дип. Димәк, шундый олы булган инде, ди, бер штанны 7 көн теккән 1 кешегә. Шундый булганнар алар, дип сөйли торганнар ие.

**Ядегәй халкы.** Безнең авылның зиратында яр җимерелә башлады да анда кеше сөякләре чыкты. Аларны әниләр, уракка барганда күреп, суда чайкап җуып, яңадан зиратка киртәсенең эченә кертеп күмә торган булганнар инде. Шуларны безнең әби безгә кадәр ядегәйләр дигән халык яшәгән, ди торгание. Димәк, шуларның сөякләре чыга.

*Сөйләүче: Газизова Хөснурый*
*Әһлулла кызы (1925 елгы).*
*Кече Кирмән авылы*

**Адәм.** Сөйлиләр ие. Хәзер менә шушылай атабыз Адам алып кайткан теге элек хәзерге буласы кеше белән. Сука сукалап ята икән. Шуннан алып кайткан, әтисе әйткән:

– Улым, бездән соң шушындый кешеләр булыр, каян алдың шунда илтеп куй, – дигән. Олы кешеләр булганнар. Әнә, безнең монда тауда Адам чабатасын каккан дигән тау бар. Адам каккан чабата, шулай өем булып калган.

*Сөйләүче: Мөхәмәтдинова Мәгъмүрә*
*Сәләхетдин кызы (1932 елгы).*
*Көмешкүл авылы*

**Урта Сон.** Теге Бәек (*Бөек*) күчешләр вакытында гуннар/суннар/шөннәрнең бер өлеше бу якка да килеп урнашкан. Шуңа күрә Сон елгасы, сон кабиләләре яшәгән, дип бара монда. Иң борынгы авыл Урта Сон, аннан соң 3 авыл Биләр ягыннан сөйләү буенча бер әби 3 улы белән килеп урнашкан. Безнең Түбән Сонныкы Габдрахман исемле, шул нигезләгән булган моннан 500 еллар элек. Сон

елгасының түбәндәге агымында булганга, исемен Түбән Сон дип атаганнар. Тегендәрәк Урта Сон, аннан Кече Сон һәм Югары Сон – яңа санала, колхозлашу чорында аерылып чыккан аерым авыл иде ансы, зияраты бар. Габдрахман дигән абзый авылны нигезләү, үстерү өчен бик күп көч куйган, диләр инде. Аның заманында беренче зират ачыла, ул үзе дә шуңа күмелгән, изгеләр зияраты. Саклы урынга сайлаган ул аны су кермәү өчен. Авыл үсеп, зияратны авыл башына үзгәрткәннәр. 1700 нче елларда холера, чума авыруы эләгә монда, бик күп кеше үлеп, зияратка тегендә ташып бетерә алмыйлар, менә бу урынга хәзерге мәктәп урынына зиярат ачыла. Ул шул бер гасырлар күмелә дә, аннан туктаталар. Авыл үсә 1984 елда мәктәп салырга кирәк, коммунистлар заманы, халык каршы килсә дә зиярат өстенә салалар. Урыны билгеле, монда бик күп каберләр, сөякләр чыга фундамент казыганда зияратның теге башына монда чыккан сөякләрне җыеп, тартмага тутырып илтеп күмгәннәр. Шунсы бар. Моны казучы экскаваторщик, әйтәләр казымаска дип, миңа тегеннән әйттеләр дип казый, моны казып бетерә. Икенче, каядыр экскаватор белән казыганда эшләп торган экскаватор вакытындадыр инде үзе чыга да соскычы бәреп үтерә үзен.

Түбән Сон үзенчәлекле авыл. Олыслар оештыра башлап Түбән Сонга тукталалар. Ул вакытта данлыклы бай Шәпи бай, һ.б. дин әһелләре каршы киләләр олыс үзәге булса монда кабак, тәмәке тарту, спиртлы эчемлекләр сату рөхсәт ителәчәк, руслар күпләп монда керәчәк, дип. Казандагы танышлар булу аркасында Олыс үзәген Түбән Сонда булдырмауга ирешә. Олыс үзәге – Үсәли дигән авылга күчерелә. Түбән Сон исеме сакланып кала – Нижнесюньский волость дип йөртелә. Сапи старшина булып Түбән Сонда аның да йорты исән әле – Дәүли-Дәүләтша бай тора старшина булып 18 ел буе, 1912 елда салдырган йорты исән әле – архитектура истәлеге.

Аның ярдәмчесе Баскан авылыннан Сәйфетдин дигән кеше. Алар бергә олысны җитәкләгәннәр. Аның самовары саклана безнең музейда. Бу здоровый, зур гәүдәле булган. Авылда авыл капкасын ачып торганнар бу кайтасын белеп, авыл капкасы ачылуга үзләренең капкасы ачылган булырга тиеш булган. Шундый тәртип, самовар кайнап торырга тиеш булган.

*Сөйләүче: Габидуллин Илшат*
*Гафиатулла улы (1969 елгы).*
*Баскан авылы*

**Баскан.** Баскан авылы – элек Акчура дип аталган. 1500 нче елларда Чаллы әмирлегенә кергән Пимәр авылыннан Акчура исемле бабай 2 энесе белән безнең якка сәүдә белән килгән дә, урынны ошатып, шунда авыл кора, шуның хөрмәтенә Акчура авылы, Акчура инеше, Акчура чишмәсе. Хәзерге көндә дә исемнәре бар, саклана. Ул бабай бик сәләтле оештыручы, Чистай һәм Чаллы – Казан якта сәүдә эше белән йөргән бу. Беренче булып каршы якка агач эшен, җил һәм су тегермәннәре оештыра, ләкин ул елларда җил һәм су хәвефле булган, чөнки ул авыл үзәндә урнашкан, бу төзегән корылмаларга зыян килә. Тагын шундый зыянлы хәвеф булса авылны башка урынга күчерергә кирәк булыр,дип әйтеп калдыра. Әйтеп калдыру гына түгел, шушы авыл күчәсе урыннан ерак түгел аланда Акчура авылының зиратын нигезли, ул үзе дә шунда күмелгән, дигән риваять бара. Ләкин бу зиярәтнең урыны төгәл билгеле түгел, ерак түгел аның яныннан ялгыз нарат үсеп утыра, бердәнбер безнең авылда ул зияратлар янында зур нарат булган. Хәзер дә шәп ул. Һәм үзе үлгәннән соң 1628–1630 еллар тирәсендә тагын бер су басу, җил хәвефе – давыл була. Авыл халкы бу урынга, сайлап куелган аланга күченәләр һәм исемен Акчура дип әйтмиләр, Акчура оныклары безнең авылыбыз яңадан үсеп китте, яңадан аякка басты, дип Баскан дигән исем бирәләр. Бу беренче риваять.

Икенче риваять. Акчура авылын элек урманнан чыгып юлбасарлар баса торган булганнар. Соңгысында яндырып, авыл күчәргә мәҗбүр була һәм шуңа күрә Баскан авылы дип атаганнар. Яисә юлбасарлар баскан. Без ул фикердә тормыйбыз. Кемдер үзенә үзе зыян китергән нәрсәне Баскан дип исем кушмаганнар бит инде. Без инде яңадан яши башлаган, яңадан аякка баскан. Бәлки җимерелгәннән соң яңадан аякка баскан.

Бу зиярат урыны хәзер авыл эчендә калган. Ул ялгыз нарат янында. Анда пуҗым бар. Без үскәндә анда бер әби тора иде, ул җенле урын шикелле иде, безне шулай куркыталар ие. Әйе үзе дә сихерче шикелле, өй эчләрендә дә әллә нәрсәләр ясалган, ул йортны сүттеләр инде, кияүгә китте дә ул әби. Ул хәзер мәрхүмә.

**Хәзинә.** Бу өем – алтыннар күмелгән урын. Моны әзрәк салыбрак йөри торган малайдан казыта башлаганнар. Аннан аны кемдер килеп куркыткан. Ярамый, сразу үләсең, дип. Усали байларыныкы дип әйтәләр. Зиярат эчендә. Әйтәләр, казылган төп өлеше читтәрәк,

моннан кереп, болар моны томалаган булырга тиеш, дип кенә. Кайдадыр басуда булырга тиеш. Моны күрәзәчеләргә эндәшеп карау да булды. Алар шулай дип әйтә ди. Бу бик тирәндә, бер атна эчендә барлыкка килгән ди бу өем. Әнә теге вакытта революциядән соң, теге байларны куа башлагач, репрессияләр башлангач. Өем каберлек формасында, ләкин аркылыга.

*Сөйләүче: Габидуллин Илшат*
*Гафиатулла улы (1969 елгы).*
*Баскан авылы*

70 чакрым җирдән килдек без... Пимәр авылы җыры (Балык бистәсе). Ул җырны моннан киткәндә җырлап киткәннәр. Безнең Акчура бабай монда килә, калганнары китә ул якка.

*Сөйләүче: Абдуллин Самат*
*Габдуллаҗан улы (1916 елгы).*
*Баскан авылы*

* * *

1700 дә ничә генә бит әле Чәше башыннан төшеп урнаша бит. Чәше башында Өскедән килгән кешеләр бар, диләр. Ничек инде керәшен авылына Өскедән килгән. Ә менә бу керәшеннәр Өске белән Биләтле арасында булган. Мансар тавы дигән җир бар. Ферма төзегәннәр ташка, анда баргач, табына торган булганнар. Өскедән йөгереп менде бер карт: «Ала күрмәгез моны, ала күрмәгез, бу керәшеннәрнең элеккеге табына торган җире булган». Шуннан хәзер нык матур җир булган бу, анда җиләк булган, керәшен балалары таптап бетермәгез җирне, авылга килә Биләтле дә, Өске дә. Әнә сезгә Яңа Горелый дигән җир бар шунда куып төшерәләр. Аннан алар бераз торалар. Качкыннар сыерларын, тавыкларын урлап бетерәләр. Яңадан монда тау өстенә күчеп менәләр. Аннары безнең авыл да шуннан төшеп китә. Менә Чәше башы дип нәрсәдән калган.

*Сөйләүче: Семенов Илья*
*Сергеевич (1932 елгы).*
*Ташлыяр авылы*

**Серле пуҗым.** Патша хезмәте заманында Түбән Шүләнгер авылында Ибрай дигән кеше солдат хезмәтеннән качып кайткан, авылга кайтып күренергә курыккан. Армиягә киткәндә инде аның

семьясы булган, хатыны, балалары. Төннә генә кайтып өендә кунып китә торган булган. Кыш көнендә, җәй көне дә урманның тирән үзән дигән җирендә землянка ясап, шунда яшәгән. Аның шунда яшәгәнен бөтен кеше белгән, чөнки хатыны атлаган саен бәби китереп торган. Шуннан Ибрай нәселе киткән инде. Аның нәселеннән кешеләр бар иде авылда. Ибрай шулхәтле өйрәнгән землянкада яшәвенә, ат асраган, бик тиз йөри торган чабышкы аты булган. Шул атына атланып кайта торган булган. Әти-әнисе янына да кайта бит инде ул, хатыны алар белән торган. Шул ат үлгән. Ул Ибраһимны авылга алып кайткан аты инде. Әбисе төннә чыгып керсә, сарай кып-кызыл булып күренә икән. Кергән дә иренә әйткән:

– Чыгып кара әле, безнең сарай яна бит, кып-кызыл, – ди икән.

Ире чыгып йөрмәгән:

– Булган инде алайса, – дигән. Иртәгәсенә карасалар теге сарайда ат үлгән булган. Бу чынмы, ялганмы шундый сүз йөри инде. Энергияле ат булган, әкиятләр сөйлиләрие искиткеч ат дип. Ул атны Ибрайга әтисе биргән.

Шул нигездә икенче бер киленнең корсагы юкка чыккан. Ниндидер серле урын. Килен нидән юкка чыккан үзе дә белми. Ну менә җен урлаганмы, Алла сакласын. Ул йоклаган җирдән хатынның корсагы юкка чыккан. Ул пуҗымда кеше яши хәзер. Нәрсәсе үзенчәлекле, – акылга җиңеләебрәк баралар кайберләре. Ибрай киткән урманга, җәяү. Үлгәнче шунда яшәгән.

* * *

Безнең авылга Шаһиләнгер дигән бабай килеп чыккан да, имеш тә, малайлары белән киңәшләшеп карап тора икән. Елгадан йомычка агып килә. Әйткән, малайлар карагыз әле, кемдер кайдадыр агач чаба, кешеләр тора торган урын булырга тиеш, дип. Киткәннәр карап та менә шушы инешне тапканнар да инде, малайларын башка чыгарган.

*Сөйләүче: Гыйлаева Земфира*
*Шакирҗан кызы (1949 елгы).*
*Түбән Шүләнгер авылы*

**Кече Кирмән**. Монда безнең Мамадыш – Ак кирмән дип аталган. Бу Кече Кирмән, монда ныгытмалар булган. Кирмән – ныгытма дигән сүз булырга тиеш. Бездә Кирмән елгасы ага. Ул башлана

бер 4 чишмәдән. Монда иң шәп чишмә – Тава чишмәсе, халык шуннан су алган инде колонка булганчы. Ул Тава чишмәсе безнең бабайга аталып чыгарылган бугай. Без теге урамда яшидериек. Монда янгач кына күчтек. Шул урамның беренче йорты булган. Безнең бабай, патша хезмәте дигәннәр бит иң элек, озак хезмәт иткән, русча сөйләшергә өйрәнеп кайткан да «Тово значит!» дип сөйләнә торган булган. Халык тава Абдулласы дигән. Абдуллин Фәрхулла Әһлулла аның улы инде минем әтием. Урамның иң кырыенда яшәгән тауга гына, төп йортлары уртадарак булган аларның, башка чыккан инде Фәрхулла бабай. Таудан төшеп китү белән Тава чишмәсе ага. Тау кырыенда булганда тава Фәрхулла дип йөрткәннәр инде, но электән килгән тауны «тово значит»тан килеп чыккан.

**Чегән чишмәсе** – гомергә атып су биреп тора. Монда чегән Зиннәте дигән бер бабай яшәгән. Менә тимерче алачыгы булган. Каракай гына кеше булган ул, бик усал булган. Шул вакытта ук мәкләрдән файдаланган ул, русча белгән. Икенче бер вариант: имеш, анда чегәннәр килеп, иткән, шуннан киткән чегән чишмәсе дип. Алай булмаган инде ул. Чегәннәр тимерче бит алар. Элек авылларда йөреп, чалгылар чүкеп, ураклар тешен биреп йөргәннәр халыкка. Бу бабай да ураклар тешен бирә иде.

**Бүрләк чишмәсе.** Бурләк елгасында бүрләк чишмәсе дигән бар. Ул ярдан агып чыга. Кирмән елгасына Нурулла турында гына килеп кушыла.

**Алмагач чишмәсе.** Ансы бик аз сулы бугай инде аның. Аның өстендә бик матур үзән шикелле ие бит елга. Анда җиләклек буладырые һәм бер алмагач үсеп утырадырые. Аның ярында ак балчык чыккан.

**Утар чишмәсе** барые. Ферма каплап китте инде аны.

**Бакырчы чишмәсе.** Элек анда бакыр чыгарып караганнар. Тикшергәннәр эчәр өчен иң файдалы су. Ул бакырчы чишмәсенең кер юа торган бер уймагы да бар. Ул кыйблага карап чыккан. Кыйблага карап чыккан чишмә халык өчен бик изге саналган.

Бүрләк чишмәсеннән соң теге якка Нурлыга таба төшеп китә, 10 чишмә бар анда.

Безнең авыл чукындырудан куркып, күчеп, иң актыкта шушында килеп утырганнар. Бик зур ие бу авыл, 4 мәчете 4 мәхәлләсе бүленгән.

**Трайт чишмәсе.** Трайт дигән бер бабай яшәгән инде. Әскәр чишмәсе дип тә әйттеләр. Трайт хатын-кызга кушыла торган исем инде.

**Казыган тау.** Аны әби патша казыткан булган, шушыннан узган әби патша кайткан юл, Себердән.

*Сөйләүче: Газизова Хөснурый*
*Әһлулла кызы (1925 елгы).*
*Кече Кирмән авылы*

**Ләүкә авылы.** Ләүкә дигән авыл булган Хәсәншаның теге ягында. Анда күчеп киткән кеше башта мунча салган да – Ләүкә дип атаганнар.

Хәсәнша авылына Хәсәнша исемле кешенең исеме бирелгән. Бу елганы Чытыр дип йөртәләрие. Читән корган ул кеше. Шуңа күрә Чытыр дип исем кушканнар, дип сөйләшә торганнарые. Үзебезнең авылның нәрсәдән Кече Кирмән – Кирмәнбашы дип аталганын белмәем.

Күҗәкә тавы, Урыс тавы, Арт сикерткән тау бар. Казыган тау – анысын казып эшләгәнгә, анысының точносын беләм. Юл салганнар ансына.

*Сөйләүче: Миңнеханова Роза*
*Мөхәммәтҗан кызы (1935 елгы).*
*Кече Кирмән авылы*

* * *

Новое Мочалкино (Ташлыяр), Шәдчебашы (Старое Мочалкино), Юкәче (Мочалкино) – нигездә керәшен авыллары. Аларның һәрберсенең исемнәре бар.

Ново Мочалкино – Яңа Мочалкино – борынгы исеме Ташлыяр. Шәче башы бар (Шәдче башы түгел ул). Ямаш – татар авылы. Монда удмуртлар яшәгәннәр. Чәше дигән сүз чүпле елга, ‘чүпле су’ дигәнне аңлаткан, тегендә урманда аның күле бар. Шул күлдән агып чыга да шул күл янындагы авылны Чәше башы диләр инде (суның башы дигәнне аңлата).

Мәхмүд Бөдәйлине исән-сау күргән кеше инде мин, ул, төрмәләрдә утырып чыккач, безгә кайткан иде. Безнең бабай белән Троицкида бергә укыган булганнар да. Безнең бабай үлгән иде инде, әби белән сөйләшеп утырдылар. Авылларга исем кушкан кеше Бөдәйли. Ямаш авылына ул кушкан. Ямаш авылы башта Новый горелый ельник булган. Анда булган чирмешләр-марилар. Вахит авылы башта Старый горелый ельник. Чыршы урманнарын яндырып килеп утырганнар да. Анда Мәкчим дигән кешеләр булган, аны Яңа һәм Иске Мәкчим дип тә йөрткәннәр. Мәхмүд Бөдәйли кайткан да Хөсәен Ямашев хөрмәтенә Ямашка шундый исем кушып киткән икән.

Безнең әбиләр авылыбызны элек Шәдче димиләр иде, Чәше дип йөртәләр иде, урысчадан Шәдче (Шадчи) ул.

*Сөйләүче: Фәләхов Азат*
*Алмаз улы (1955 елгы).*
*Шәдче авылы*

1552 елга туры килми, икенче чукындыру вакытында безнең авыл Комазан башыннан, чукындырудан качып, бу урынга түгел, ә су буена тегендә – түбәнгә күчкән. Анда алар торганнар күпмедер вакыт. Ансын төгәл әйтеп булмый. Шәҗәрәсен үзебез эшләдек.

*Сөйләүче: Сафина Сабира*
*Хамис кызы (1947 елгы).*
*Түбән Козгынчы авылы*

**Изгеләр зиратлы. Изгеләр чишмәсе.** Бездә бар 14 нче гасырга караган зират – изгеләр зираты дип атала. Изгеләр чишмәсе дип атала торган чишмә бар.

Бу зиратка, каяндыр, ханлыктан килгән кеше күмелгән дип әйтәләр. Шуңа күрә изгеләр зираты дип тә әйтәләр. Нииндидер хәбәр белән килгәнме инде ханлыктан. Безнең Кирмәнчек безнең төп үзәкләрнең берсе. Ул зират бар менә. Ә инде кайбер фаразларга килсәк, бездә экспедиция тоже булганые 1996 елда. Анда инде мондый мәгълүмат та әйтәләр: Яке фарсы сүзе, үзәктән читтә яшәүчеләрне аңлата. Димәк, каядыр үзәк Кирмәнчек, без шуннан читтә яшәүче халык. Бу туры килә инде б.э.к. 2000 нче еллар дип тә әйтәләр, беренче кешеләр яшәгән чор. Авыл урыны бар изгеләр зираты өстендә дә – Яке авылының элеккеге урыны.

Изгеләр чишмәсе риваять буенча. Ул безнең авылга килгән (Кәрим хәзрәт мулла Җәләлетдин). Изге кеше дип әйтәләр инде. Шул мулла Җәләлетдин, Кыбра елгасы аркылы чыкканда, зираттан әз генә аста изгеләр чишмәсе бар, таяк белән төртеп чишмә барлыкка китергән. Кешеләрнең йөрәкләренә сихәт бирсен, дип. Икенче чишмәне барлыкка китергән ирләренә сихәт бирсен», дип. Монда ике кое, ике коедан су алалар инде. Бу коелар берсе – күзгә, берсе – йөрәккә. Бик әйбәт дип әйтәләр инде, дәва саклана.

*Сөйләүче: Насыйбуллин Фоат*
*Галимулла улы (1965 елгы).*
*Түбән Яке авылы*

## Ышанулар, йолалар, гореф-гадәтләр

**Корман.** Элек корман булган. Боламык корманы, тавык корманы, мал суеп корман була безнең.

Боламык пешереп ярмадан, Ходайдан сорау, яңгыр сорау. Суга куялар инде су анасы, җир анасы дип теләк теләп шундый теләүче карчыклар, бар ие алар үлеп беттеләр инде. Безнең тыкрыкта тавык корманы була. Кем тавык бирә, менә минем дә тавык биргәнем бар, ничә тавык җыела. Күкәй туглап бик тәмне иттереп ботка пешерәләр. Күкәйне әрчеп менә су анасына ризык булсын, дип, суга салабыз инде, ботканы да инде. Ходайдан теләп, Ходай, шифалы яңгырларыңны бир, дип. Шулай иттереп инде чишмәдә, үзебез сулар эчәбез. Бер беребезгә су сибәбез. Монсы тавык корманында.

Безнең биек тауда бер чишмә бар, әйбәт кенә чишмә, шунда мал суеп корман ясыйлар инде. Анда шул ботка пешерәләр, тагын инде итен кем суя бирәләр анда бөтен авыл җыела киләлгән кеше. 40-50 м басугарак, читкәрәк барып, җир казып инде Ходайдан сорап, теләп җиргә күмеп куела инде. Ходайдан барлык әйбәт кешеләр, балалар хакына, маллар хакына яңгыр сорыйсың инде. Аны бик әйбәтләп оештырганнар. Иртәгә корман дигән көнне чистарынып, җуынып, ару киенеп барыла.

*Сөйләүче: Сапурина (Иванова)*
*Екатерина Гурьевна (1939 елгы).*
*Владимир авылы*

**Күз тию.** Күз атка да тия. Күз, кешене гүргә кертермен, малны казанга кертермен, дигән бит. Мал чирләсә суясың, пешереп ашыйсың, менә шул була казанга керү. Күз тимәс өчен миләш агачыннан ясап, каештан чуклап шушы төшкә (маңгай турына) куя торганыек. Күз тимәсен, дип, балаларга миләш агачы куя торган булаек.

*Сөйләүче: Мөхәмәтдинова Мәгъмүрә*
*Сәләхетдин кызы (1932 елгы).*
*Көмешкүл авылы*

**Тимрәү имләү**. Тимрәүле (тире чире булган, лишайлы – *Л.М.*) кешеләр тимрәүдән котылу юлын төрлечә эзләгәннәр. Дару-фәлән булмаган. Тимрәүдән котылам дип, йорт түбәсенә менеп утырып, узган-барганга кычкыра торган булганнар:

– Башыма тимрәү чыккан, – дип кычкыра торган булганнар түбәдән, узып барган кеше игътибар итсен, дип. Белгән кеше, тимрәү иярмәсен, дип: – Башыңа чыкса, күтеңә (арт ягыңа) дә чыксын тимрәү, дип әйтеп китеп бара торган булган. Шулай димәсә, чирле кешенең тимрәве моңа ияреп киткән саналган, ә түбәдәге кеше тимрәүдән котылган. Шулай үзен-үзе ышандырган.

*Түбән Ушма авылында Ибраһимов*
*Хатип Ибраһим улыннан (1939 елгы)*
*Л. Мөхәммәтҗанова язып алды*

* * *

«Безнең зиратта чачауник (чәчемнек) юк ул. Ул кайсыбер керәшен авылларында. Бездә юк. Татар дисәң – дине юк, урыс дисәң – теле юк, ике диннән тол калганбыз, – дип утырыр иде мескен безнең әни. Чиркәүнең чаңын да төшергәннәр. Шундый чачауник (*часовник*) мазар юк. Динне түгел безнең Владимирда кеше.

40ында зиратка барып чакырып кайту. Аш буласы көнне. Аннары җылын да. Зияратка барып, кабер кырыен 3 тапкыр әйләнәсең атаның үлеменә, исеменә аминне әйтеп. 40гы, елы яңарак үлгән кешегә була бит инде. Аннары туган тумачаларны, һәрберегез кайтыгыз, дип чакыралар инде. Аннан ары утыргач, бер заман утыргач искә алып, аннан ары озата чыгу урамга. Табак белән кашык куела иң арттан табынга. Үле табынындагы ашамлыкны алып менеп китәләр дә аны алып төшмиләр инде, зиратта кала, анда

куялар. Безнең авылда инде ул үлгән кешеләрнең кешеләре булмаган кешеләр бар. Әллә кайдан әллә кемнәр күмелгән бит инде, шулар өчен дип, сугышта үлгән кешеләр өчен дип. Аны каргалар ашап бетерә инде, алар ашамый. Аны өйгә аптөшелми зиягатка менгән әйберне. Үлекне күмгәч, кайткач, мунча ягыла инде. Үлекне күмгән көнне. Ашка (40, елы) каршы көнне ягыла инде. Каен себеркесе куела. Үләләр өчен атап каен себеркесе куела. Үләләр көне, үләләр чыккан көн була бит. Ул көнне мунча ягасың көндез. Тиз генә үзең җуынып чыгасың бөтен җирен чистартып, ләүкәдән тотынып, тәрәз төпләреннән тотынып, сабынын, суын, себеркесен әзерләп менә кемнәр киләсе килә, башта үзеңнекенә әйтәсең инде. Әнине, бу йорт ияләрен исеме белән әйтәсең, аннары кемнәрнең кайтасы килә, әрберегез монда кайтып юыныгыз, дип әйтеп чыгасың. Үләләр чыккан көн Олы көн алдыннан була, четверг көнне. Аннары, берәр атнадан соң, вторник көнне үләләр Бәйрәме, үләләрнең олы көне, ул көнне күкәйләр манып зиярәткә менелә. Пасхадан соң бер атна уза, вторник көнне. Олы көн алдыннан 3 көн чыгалар, аннары аларның кереп китү көннәре. Ул көнне бөтен кеше кайта, кем кайтала, зиятатта бәйрәм шикелле була инде. Манган күкәйне ватып шунда куясың инде, ашарга дип, кая ашасын инде ул, балакаем. Менә олы көн күкәе дип куя торган идем инде мин.

Мәет өстендә еларга ярамый, ди. Безнең әни, чык күз яшеңне дә чыгарма, диде. Төн саклаганда иманнар гына укыйлар. Псалтырны укып чыгарга тиеш, бетерергә дип язылган.

Чакырып кайтканнарны озатырга чыгу: иманнарны укып, урыны оҗмахта булсын, дип, и Ходаем, бер Ходаем, Ходай Тәгаләм үзеңнең фәрештәләрең белән бергә тотсаң иде без үлгән бәндәгезне дип исемнәре белән әйтеп Күк патшаларын, күктәге атабызны әйтеп озаталар инде урамга чыгып, зиратка таба озатып калалар. Аш ашыйсыңмы, ботка ашыйсыңмы, нәрсә ашыйсың шуны бер олырак чокырмы, кружками шунда тукланып ятсын дип шул кешене әйтеп, чокырга тутырасың чыккач, шуны апчыгып баганаың теге ягына саласың менә аның ризыгы инде ул, чокырдан бушатасың инде, җиргә койма аркылы, сул ягына.

Аның өчен кан чыгару бар. Тавык, дуңгыз ярамый, бәрән кирәк. Үзенеке булмаса, кешедән сатып алып суялар. Бөтенләй пешереп бетермиләр, яртысын пешерәләр. Үлене озатканда иман әйтелә.

Бер җыр әйтәм, мин шуны җырлыйм, әни шуны җырларга әйткән ие. Үлгәннәргә җырламасаң, әйбәт кеше булмаган, дип ышанганнар.

Иртәдән үк торып тышка чыксам,
Чыкланганнар икән үләннәр.
Ашадык, ди, эчтек, хөрмәт күрдек,
Бәхилләб үк ятсын үлгәннәр.

Шуны җырлыйм мин. Әни шуны әйттерә иде.

*Сөйләүче: Сапурина (Иванова)*
*Екатерина Гурьевна (1939 елгы).*
*Владимир авылы*

**Нардуган.** Кич утыраиек җыелышып. Кешеләр киенешеп керерләрие. Кайсы шәрәтән толып бөркәнеп йөрер ие, кайсы такмак әйтеп биеп чыгып китәрие, кайсы гармунга биеп чыгып китәрие. Аннары алар артыннан үзебез чыгып китәриек киенеп. Кайсы маймыл, кайсы аю булыр ие, кайсы кәҗә булырие. Менә шундыйлар киеп чыгып китәриек, керәшен әйберләре киеп. Чиләккә бәреп, тавыш чыгарып, кереп биеп чыгып китәләрие танытмыйча, кайсын танып каласың, кайсын танымыйча.

Анна түтәйнең энесе ел саен бөтен җирен корымга буяп, шәпшәрә тәнгә толып киеп килеп керерләр ие. Өсләрен ачалар ие дә ябып куялар ие. Хәзер нардуган юк та бит инде. Әле все-таки балачага йөри башлаган, безгә керүче булмады.

*Сөйләүче: Долгова Нина*
*Григорьевна (1938 елгы).*
*Владимир авылы*

Күз төшеп йөргән кызлар бар. Озатканны белсәләр (егет кызны) кызның капка төбеннән егет капка төбенә опилка сибәләр, юл ясыйлар, юлны күрсәтә – шушы егет белән йөри икән бу кыз.

*Сөйләүче: Семенов Илья*
*Сергеевич (1932 елгы).*
*Ташлыяр авылы*

Абыебыздан сорыйм: «Нишләп элек пыяла да булмаган, ник шуның хәтле тәрәзә тутырганнар өйгә» дим. Егетләр, ничә тәрәзәң

бар? – дип сораганнар кызлар егетләрдән. 3 ле тәрәзәле өйле егеткә кияүгә бармаганнар, хәерче, дигәннәр.

*Сөйләүче: Семенова Анфиса*
*Макаровна (1941 елгы).*
*Ташлыяр (Новое Мочалкино) авылы*

Кар бетүгә, җир кипсә, **сабан туе** ясар идек. Бер 3 көндә теге авылда да, бу авылда да бетте. Менә бу революциядән соң гына беләм бит инде. Аннары сабанга чыктык, сабаннан чыккач, менә урысларның Пасхалары бар бит, аннан 50 көннән соң Троицк дигән тагы бәйрәмнәре бар. 3 көн бәйрәм ясый. Ат чаба, мәйдан була. Түбән Кыерлы Троицк деньда катнашты, урыс авылы булмаса да. Чөнки Түбән авыл да, Колычшы да якын аларга. Аннан узды менә бүген чәршәмбе, иртәгә пәнҗешәмбе, берсекөнгә җомга көнне Комазан җыены, 20 сендә Кирмән җыены. Шул төштәге авыллар. Аннан соң монда Төбәк дигән авыл бар – Төбәк ягы җыены. Аннан соң Чаллы – Чаллы җыены. Атна саен җыен. Аннан Сон җыены. Чөнки Усали түгел ие, Түбән Сон волость булган ул. Әле аның волость камитәләредә бар иде. Сон җыены июльнең 10 нарында – җомга көн кайда туры килә иде. Һәр атна саен җомга көнне 4 көн иттеләр аны. Сабалардан да киләләр иде. Ике якта иген, җыен такыр басуда булды, иген тапталмасын өчен. Кызлар җыелып «Мөхәммәдия»ләр укыганнар. Безнең әниләр апа булгач та, шулай булды. Мин белгән чагындагы кызлар – күрше кызлар инде – бер әби өендә җыелып кич утырырлар ие дә, анда төрле уеннар уйныйлар идее. Түгәрәк уен. Сабан беткәч, **җыеннар башланганчы** безнең авыл егетләр-кызлары болынга төштеләр. Җомга көнне генә ул. Аталары җомгага китә, кызлар аналарыннан сорыйлар да тиз генә болынга төшәләр. Шул 1 сәгать эчендә Усали җегетләре дә киләр ие, Катмыш егетләре дә. Мине кызлар сакларга җибәрәләр ие. Кем килә моның янына, кайткач та әйтерсең яме, дип. Әбидә бер кыз тора иде. Теге әби мине кисәтә. Ярар-ярар. Әйтми торганыем алар җанына килгән егетләрне. Безнең авылның мулласы бар. Данлыклы бер мулла. Кызы – Разия апа. Сабадан килгәннәр алар. Шунда кунакка бара торганыем Сабага. Сатышныкые абыстай. Сатышка да бара идем. Анда Мишә суы узып китә икән. Разия апага җәза бирделәр – җырла әле дип. Мулла кызы ничек итеп җырлар икән, дип торам инде.

Безнең Мишә суларында
Вак балыклар йөзалмый.
Минем җаныем үзе сөя
Шуңар күрә назламый, –

дип җырлады.

Һаман да шул минем колагымда. Аның да сөйгән егете булгандыр инде шулай иттереп матур җырламас ие.

*Сөйләүче: Абдуллин Самат*
*Габдуллаҗан улы (1916 елгы).*
*Баскан авылы*

## Бәетләр

### Гыйльфанга

*Бу язманы 2001 елның 23 октябрь кичендә вакытсыз арабыздан киткән Миңнеханов Гыйльфан истәлегенә багышлап яздым. Тормыш иптәше Рауза Миңнеханова.*

2001 нең көз айлары
Бигрәк шыксыз иде.
66 яшендә Гыйльфан
Кара гүрләргә керде.

Гыйльфан калган киемнәрең
Балаларың кияләр.
Әтекәем, кара гүргә
Иртә кердең, дияләр.

Гыйльфан синең нурлы йөзең
Иртә белән күрмәдем.
Эшкә диеп чыгып китеп,
Үлгәнеңне белмәдем.

Эшләргә чыгып киткәндә
Балта иде кулыңда.
Кичтән генә балалар белән
Уйнап яттың урында.

Гыйльфан гармуныңны алып,
Уйнадың матур көйгә.
Руфинәм, диеп эндәшеп,
Кайта идең син өйгә.

Гыйльфан үзең исән чакта
Балаларны яраттың.
Кайгы-сагышларың булса,
Гармун уйнап тараттың.

Аклы ситсы күлмәгемнең
Өзеп алдым сәдәфен.
Гыйльфан синең үлемеңнең
Белә алмадым сәбәбен.

Юл кырыенда яткансың,
Машина да узмаган.
Ничек болай бер кеше дә
Ярдәм кулы сузмаган.

Өйләрдән чыгып киткәндә,
Киендең өй алдында.
Сары тракторың белән
Торасың күз алдымда.

Бармакларың саен Гыйльфан
Йөзекләр кия идең.
Руфинәңне алларыңа
Утыртып сөя идең.

Гыйльфан, күрешә алмыйбыз –
Еракларда аралар.
Ярый әле истәлеккә
Калды миңа балалар.

Тракторларда йөргәндә
Талгандыр беләкләрең.
Салкын суда ятмас идең,
Янгандыр йөрәкләрең.

Гыйльфан минем исемемне
Язып куйдың беләккә.
Мәңге онытылмаслык итеп
Яра салдың йөрәккә.
(«Рауза» дип язып куеп, 2 кош
төшергән иде беләккә – *Р.М.*)

Гыйльфан синең үлемнәрең
Бар кешегә аяныч.
Серләремне серләшергә
Балаларым таяныч.

Зиратларга менеп карыйм,
Гыйльфан синең каберең.
Бергә яшәгән чакларның
Белмәгәнбез кадерен.

Сыгыла каен, бөгелә каен
Таң җиле искән саен.
Карточкалырыңа карыйм,
Исемә төшкән саен.

Сары тракторың белән
Кукурузлар ургансың.
Урамнарда үләрмен, дип
Гомер уйламагансың.

Көннәр буе эшләп аргач,
Чыккансыңдыр кайтырга.
Балаларың, туганнарың,
Җыелдылар озатырга.

Комбайннарда эшләдең,
Бик күп үрләр үрләдең;
Пенсиягә чыккач кына
Рәхәтләрен күрмәдең.

Гыйльфан атлар җиккән чакта
Тарагансың ялларын;
Урамнарда, салкын суда
Чыкты синең җаннарың.

Зәңгәр һаваларны ярып
Оча аэропланнар;
Өйне бетереп керү иде
Безнең корган планнар.
(Өйне син башлаганыең,
бетереп кермәгәниек – *Р.М.*)

Үзем исән чакта, диеп,
Өйләр сала башладың
Бик авырлык белән генә
Тракторны ташладың.

Өй түбәләрен яптың
Челтәр ясап калайдан.
Сиңа озын гомер теләп,
Сорамаганбыз Ходайдан.

Олы алмаш, дип эшкә кердең
Ясарга өй аллары;
Йортларыбыз матур булды
Син генә күралмадың.

Гыйльфан салган өебезгә
Икәү бергә кермәдек;
Үкенечкә шушы калды,
Изгелеген күрмәдең.

Китапларга язсам дагын,
Бетмәс синең һөнәрең.
Урамнарга ямьнәр бирә
Синең салган өйләрең.

Үкенечкә шунсы калды,
Керә алмадың өйләргә.
Торба утыртып, буяп куйдым
Җаның чыккан ерләргә.

Гәүдәләрең җиңел булды,
Җитез булды кулларың.
Сине бик тә сагыналар
Кызларың һәм улларың.

Эшкә барырга дип чыккач,
Уңмагандыр юлларың.
Бар эштә дә оста иде
Синең алтын кулларың.

Телгән ременнәрең калды
Дилбегәләр үрергә.
Җир астыннан юллар булса,
Барыр идем күрергә.

Җәйнең матур көннәрендә
Аш пешердең болында.
Чалгы чүкегән чакта
Чүкеч булды кулыңда.

Башларыңа кыңгыр салып
Фуражка кия идең.
Сары каешларны телеп
Чыбыркы үрә идең.

Урманнарда печән чаптың
Түгәрәк матур аланда.
Бигерәк олы кайгы килде
Бер дә уйламаганда.

Сары тракторың белән
Басуларны буйладың.
Бәхиллек сорый алмадым,
Кайтырсың дип уйладым.

Тәрәзәдән карый – карый
Көттем синең кайтканың;
Көннәр буе көтсәм дә мин,
Исән килеш кайтмадың.

Гыйльфан сине эзләп чыктым,
Эзләсәм дә тапмадым.
Ерак түгел салкын суда
Ятканыңны белмәдем.

Гыйльфан, сине уйлап ятып,
Сызылып таңнар ата.
Әни елама сабыр бул, дип
Балаларым юата.

Гыйльфан, зиратларга менәм
Кабереңне күрергә.
Күрешүләр мөмкин түгел,
Аерылдык гомергә.

Бик күп нефть чыга, диләр
Баулы белән Әлмәттә.
Безнең өчен күп тырыштың
Урының булсын җәннәттә.

Каршы алып, озатып калдың
Раиләңне чатларда.
Йөрәкләре ничек түзгән
Сине алып кайткан чакларда.

Аклы күлмәкләр теккәндә
Якалары уела.
Сине уйлап йөзләремә
Кара-сары коела.

Кыр казының канатлары
Коела кагынганда.
Төшләремә дә кермиләр,
Әллә бик сагынганга.

Язмыш җиле мәхәббәтнең
Канатларын каерды,
Утка салды, суга салды,
Тик синнән дә аерды.

Калдым сыңар канат булып,
Пар канатым каерылды.
Балам белән Гыйльфанымнан
Мине Ходай аерды.

Балаларым, бик тырыштым
Менә алмадым үрләргә
Раил белән Гыйльфан гына
Алып керә гүрләргә.

Сандугачның балалары
Сайрый алмый ояда.
Бәхетлеләр бер исәп тә
Күрми яши дөньяда.

Безнең авыл зиратында
Бер кабер бар ләхетсез.
Туганнарым арасында
Мин булганмын бәхетсез.

Урын өсләренә яткач,
Уйларны уйлап ятам.
Үзем кебекләргә барып,
Күңелемне юатам.

Өй артындагы күлләрдә
Үрдәкләрем йөзәдер.
Бала белән ир исәбен
Ходай миңа бирәдер.

Бакчаларга чыгу белән
Чәчәкләргә кагылам.
Гыйльфан белән бергә булган
Көннәремне сагынам.

Өй артындагы шомыртым,
Яннарында алмагач.
Тормышымның бер яме юк
Гыйльфан янымда булмагач.

Биек тауның башларында
Үсеп утыра җитен.
Бергә яшәү рәхәт иде,
Аерылгач, бик читен.

Агыйделнең суы тирән,
Төпләре тик камышлы.
Синнән башка узган көннәр
Моңлы һәм дә сагышлы.

Гыйльфан яннарымда булсаң
Уйлар уйламас идем.
Чирләп ятып җиксендерсәң,
Болай еламас идем.

Кара булды кашларың,
Күпме күрде башларың;
Җыйсаң, күлләр булыр иде
Минем түккән яшьләрем.

Урамнарга чыксам әгәр
Әче җилләр исәдер.
Биш баланың бергесенең
Күрдек әче исәбен.

Суга барып, судан кайтам
Бакча эченнән генә.
Һич берәүгә сиздермичә,
Сызам эчемнән генә.

Бакчаларга чәчкән идем
Булса да җитен булды.
Гыйльфан сине озатуы
Бик тә читен булды.

Биек тауның башларында
Күрдем тузан тузганын;
Кырык өч ел вакыт узган,
Сизмәдек тә узганын.

Вакыт җиткәч агачның да
Яфраклары коела.
Бер ел вакыт минем өчен
Ун ел кебек тоела

Ишек алдым түгәрәк күл,
Балык салдым уйнамый.
Сәгать түгел, минуты юк,
Гыйльфан, сине уйламый.

Су буенда үрдәкләр,
Үргә таба үрпәкләр.
Анам да юк, атам да юк
Гыйльфан, син дә ташлап киттең,
Мине кемнәр хөрмәтләр.

Балаларны бик яраттың,
Унбер булды оныгың.
Раилеңнең исемнәрен
Оныгыңа куйдырдың.

Өч малаең, үзең кебек,
Механизатор булдылар.
Баш очыңа таш утырттык,
Чардуганнар куйдылар.

Гармуныңны алып уйнадың
Безнең авыл көенә.
Исән чыгып, үлеп кайттың
Туган – үскән өеңә.

Гыйльфан, сине көтеп торып.
Күзкәйләрем талдылар.
Больницага алып барып,
Гәүдәләрең ярдылар.

Исемеңне язар идем
Алтын йөзек кашына;
Әгәр сине кайта дисәләр,
Чыгар идем каршыңа.

Үлгән җирләреңә, Гыйльфан,
Үткәндә карап үтәм.
Кайтыр вакытларың җиткәч,
Кайтырсың диеп көтәм.

Икәү бергә печән чаптык
Яке урман буенда.
Урамнарда үләрмен, дип
Булмагандыр уеңда.

Җәйне күңелле уздырдык,
Яктык без учагын да;
Рәхәтләнеп яллар иттек
Табигать кочагында.

Бер-бер артлы исәбегез
Йөрәгемә теzелде.
Гыйльфан, синең гомерләрең
Вакыт җитми өзелде.

Үрләргә үрләсе иде,
Мондый ачы хәсрәтләрне
Балаларың, туганнарың
Гомергә күрмәсә иде.

Күзләремә йокы керми,
Төннәр буе уйланам.
Балаларым бар бит әле,
Диеп кенә юанам.

Күңелемне сагыш баса,
Ак яулыгым ябынам.
Кырык өч ел гомер иткән
Гыйльфанымны сагынам.

Тау тирәкле су буенда
Сайрый моңлы былбыл кош.
Җәйләрне бергә үткәрдек,
Бик ямансу була кыш.

Гыйльфан, клубларга мендең
Доминолар уйнарга;
Салдың кара кайгыларга,
Белмим, ниләр уйларга.

Уйлар уйлармын инде,
Уйлар уйлап, җырлар
җырлап,
Сагынып елармын инде.

Көннәр буе уйлап йөрим
Төшкә кермисең бер дә,
Җәен, кышын, язын, көзен
Ятасың кара гүрдә.

Аклы ситсы күлмәгемнең
Сәдәф тишекләре юк;
Үлгәч кавышканнар булмый,
Гүрнең ишекләре юк.

Безнең урам аркылы
Ага ферма сазлары.
Шул сазларга ятып чыкты
Гыйльфанымның җаннары.

*«Йөрәк булды диделәр инде. Менә шушы күршеләрдән эштән чыкканда китте ул. Әнә урамда торба утыртып куйдым мин. Эзләп чыктым таба алмадым. Менә шушы өйдәге малай табып кайтты аны. Абыйсын урманнан тапты, монысын урамнан тапты».*

**Газиз балакаем Раил улыма**

Чишмә суы алыр өчен,
Чыгам инешләр аша.
Күңелемдәге моң-сагышны
Чыгарам шигырь аша.

Күзләремә йокы керми
Каләм алдым әле кулыма.
Истәлеккә дип шигырь язам
Газиз балам Раил улыма.

Улым, сиңа шигырь язам
Яшел тышлы дәфтәр битенә.
Исләремнән һич тә чыгара алмыйм,
Урыннарың булсын оҗмах түрендә.

Кышлар үтә, ямьле җәйләр җитә
Бакча тула тагын гөлләргә;
Раил синең гөлләреңне
Ошатамын сулган гөлләргә.

Бакчаларга гөлләр чәчкән идем,
Матур булып чәчәк атканнар.
Бер үзләре генә белә
Баласын югалтканнар.

Кыйблалардан искән җилләр
Агач яфракларын кузгата.
Һич дәва юк минем йөрәгемә,
Бала хәсрәтләре сызлата.

Балаң кайта, дип әйтсәләр,
Тауларга менәр идем.
Ал балаңны, бир җаныңны,
Дисәләр, бирер идем.

Урманнарда искән ачы җилләр
Агач ботакларын каерды.
Салкын үлем, ачы язмыш
Газиз баламнан да аерды.

Соңгы юлга улым озатканда
Һич күреп туялмадым.
Егерме тугыз яшьләрендә
Үләр, дип уйламадым.

Күл буена барам әле,
Карыйм яшел камышка.
Биш баламның берсесе
Салды сары сагышка.

Балам, миңа истәлеккә
Синең карточкаң калды.
Бала исәбе авыр икән,
Саулыкларымны алды.

Улым, болай бик сагынсам,
Түзә алмас йөрәгем.
Унөч ел үтеп китсә дә,
(Быел егерме булды инде аңа)
Өзелә шул үзәгем.

Тормыш юлы сикәлтәле
Авыр атлап баруы.
Бала исәбенә каршы
Юк шул аның даруы.

Иртә торып тышка чыксам,
Сызылып ата таңнар.
Үзләре күргәннәр генә
Минем хәлемне аңлар.

Оя корып ризык ташый
Кош та балаларына.
Озын гомер, бәхет телим
Калган балаларыма.

* * *

Балаларым, бәгырь кисәкләрем,
Васият итеп әйтәм мин сезгә:
Матур-матур гомер итегез сез
Терәк булып бер-берегезгә.

Балаларым, туганнарым,
Барчагыздан риза, бәхилмен;
Соңгы юлга мине озатканда,
Салсын сезгә Ходай рәхимен.

Йөземдәге яулыгымның
Ачып карарсыз читен.
Малайларым алай булмас
Кызларыма бик читен.

Каберләргә кереп яткач
Күрешә алмабыз өйдә яңадан,
Рухым сөенер, изге теләк теләп
Калдырмагыз мине догадан.

Балаларым хәер-дога сезгә
Рәхәттә үтсен көнегез,
Васиятем шул: апагызны
Минем кебек якын күрегез.

Балаларым, мине һәрчак сагынырсыз,
Кызларым уйлап йөрерсез.
Малайларым, кияүләрем, туганнарым,
Каберемә ташлар куярсыз.

Улым, бәләм, бәләм хәлләреңне
Заманалар бик авыр.
Эштән кайткан чакларыңда
Кем сине каршы алыр.

Улым, минем каберемә
Куярсыз чардуганнар.
Әгәр мине искә алсалар,
Килеп карар туганнар.

Кошлар да бик моңлы сайрый
Җәй көннәре ямьлегә.
Балаларым, рәнҗемәгез,
Аерылабыз мәңгегә.

*Сөйләүче: Миңнеханова Роза*
*Мөхәммәтҗан кызы (1935 елгы).*
*Кече Кирмән авылы (Кирмәнбаш)*

**Николай бәете**

*Минем малай үлде дә, моны без җандырып алып кайттык. Бөтен көе күмә алмадык. Менә шуңа багышланган бәет бу:*

Армиягә киткән чакта,
Карадым өйгә каерылып.
Шул китүдән чыгып киттек
Туган илдән аерылып.

Киткән чакта гармун уйнап
Минем кулларым талды,
Шунда җырлаган җырларым
Истәлек булып калды.

Уйнадык та, җырладык та,
Төрле-төрле көйләргә,
Исән йөреп, саулар кайттык
Туган үскән өйләргә.

Әбәү, Алла, аурый башым
Әллә чәчем җиткәнгә.
Әллә чәчләрем җиткәнгә
Әллә читкә киткәнгә.

Әнкәй, агартып ю яме
Кулыңа төшкән керне.
Тюмень якларына киттек,
Ул бит бигрәк серле.

Тарадым, шомарта алмадым,
Чәчләрем үргә торгач.
Яшәргә мөмкин булмады
Матур тормышлар коргач.

Әткәй-әнкәй тере булдык,
Баскан җирдән ут чыкты.
Алтынчы июль көнендә
Авызымнан җаным чыкты.

Өйдәге яшел баяным
Уйный төрле көйләрдә.
Үләсе төнне төне буе
Күңелем йөрде өйләрдә.

Чыккан чакта карадым мин
Карточка төсләремә.
Футболка белән фуфайка
Кидем мин өсләремә.

Төнге сәгать уникедә
Мин өйдән чыгып киттем.
Явызларга туры килдем,
Кеше кулыннан үттем.

Ялгыз будка эчендә
Утыра идем бер үзем.
Кайтып та күрә алмадым,
Калды әйтәсе сүзем.

Җәй көне өй түрендә
Күлгә кадәрле үлән.
Ни өчен, ничек үлгәнне?
Мин үзем генә беләм.

Тюменьдә йортлар сирәк-сирәк,
Аның яртысы руслар.
Әткәй, дусларга ышанма,
Ашады башны дуслар.

Киткән чакта озатып калды
Тюменьның киң урамы.
Адаштырды, саташтырды
Июль аеның канлы бураны.

Күл кырында иде бит
Минем йөргән үз лодкам.
Кайсы дусның башы җиткән,
Мине суларга аткан.

Көтүе белән очып йөри
Күл өстендә кыр казы.
Тюмень күлләрендә булган
Әҗәлләремнең базы.

Лодкаларны бикли торган
Ике ягында зур келә.
Өстәге эш киеме белән
Кем суга батып үлә.

Буйларым озын булса да
Кыска кидем күлмәгем.
Лодкада үлгән, дип уйламагыз,
Мин бит анда үлмәдем.

Кошлар да бит су эчерә
Суга басып бәбкәен.
Ниләр өчен, ник үлгәнне?
Белмәдегез, энкәем!

Лодкам минем зәңгәр төстә,
Ишкәге иде такта.
Сөйләнерләр, киңәшерләр
Дусларым минем хакта.

Лодка шунда тора иде
Күл буйлары катканчы.
Мин югалган күлләр тынмас
Иптәшләрем тапканчы.

Бергә эшләгән иптәшемнең
Исемнәре Миннәхмәт.
Суда җебеп бетәр идем
Табучыларга мең рәхмәт.

Әни, бәхиллегең ала алмадым,
Үстердең бит син кочып.
Морг морҗасыннан чыктым
Төтеннәр булып очып.

Үлгәч тә кайта алмадым,
Булмады шул хутларым.
Ут эчендә янган кебек
Утырып калды йортларым.

Әткәй-энкәй,ачуланма,
Тора алмадым яныгызда.
Ирексез җанымны бирдем,
Оҗмахта йөрер җаным да.

Ярларга сыймыйча ярсып,
Ага суның салкыны.
Мин мичләрдә янган чакта
Сизелгәндер ялкыны.

Мин утларда янган чакта
Кереп су сибәрсеңме?
Мин янган утларда янсаң,
Әнкәем, түзәрсеңме?

Эшкә барган чакларымда
Күрә идем шул мичнең
әйләнәсен.
Кем уйлаган, Алла кушкан
Шунда көлгә әйләнсен.

Әткәй, үләсе төнемдә
Кулымда иде сәгать.
Җиңел кешенең гомере кыска,
Җиңел булмасын гадәт.

Яз көне тәрәз төбемдә
Шиңде минем гөлләрем.
Туган өйгә кайтып керде
Утта янган көлләрем.

Кайта алмадым, күрә алмадым,
Су буйлары арткандыр.
Бер кайткач та, кабат киттем
Әҗәлләрем тарткандыр.

(Чаллыга кайтып эшкә керде,
шунда кабат китте. – *А.С.)*

Төшемдә өйләргә кайттым,
Кия алмадым башмагым.
Кайтырга дип бик тырыштым,
Теләгемә ашмадым.

Урман уртасында алан,
Аның читендә балан.
Суга кипкән гөлләр кебек
Аерылды бит балаң.

Иртә торсам, кыр үрдәге
Кычкыра иде моңлы итеп.
Башларымны югалттым
Илләрдән чыгып китеп.

Чит җирләргә чыгып киткәч,
Кошлар да бит туганың.
Әнкәемнең иң бәхетсез
Сәгатендә туганмын.

Тюмень күле бормалы
Канаулы бит кырлары.
Яшьтән үләргә туры килде
Кырык яшь тә тулмады.

Әнкәй, мине тапкан чакта
Ак биләүләргә төрдең.
Утыз бер яшьләргә җиткәч
Үз кипеннегеңә төрдең.

Инешкә бара алмадык
Яныбызда күл булгач.
Бер-беребезне күрә алмадык
Аралар ерак булгач.

Күңелләрем өйдә йөрер
Күрмәмен үзегезне.
Гомергә яшь белән юарга
Калдырдым күзегезне.

Урындыкта басып калды
Уйный торган гармуным.
Туганнар, таратышыгыз
Әткәй-әнкәйнең моңын.

Пласмас көймәләрдә йөрдем,
Түгел иде бит калай.
Мин бик бәхетсез булганмын,
Булмасын ул бер малай.

Үсеп буйларыма җиттем,
Әткәй, бирмәдең киңәш.
Бик кыска гомерле булдым,
Минем кебек булмагыз,
сеңлекәш.

Өйләнгәч исемә төште
Дусмәт тавы үрләре.
Бөреләнде, чәчкә атмады
Яшьлегемнең гөлләре.

Урманнарга барган чакта
Очрады өч бөркет.
Бергә уйнап, бергә үстек,
Без бит өч кенә бөртек.

Әткәй, кайтып күрә алмадым
Яңа келәтләреңне.
Төсем итеп йөртегез
Минем бүрекләремне.

Йөрәге бар йоклап ятмас.
Чык төшкәнче уянсын.
Миннән калган гармунымны
Туганнарым уйнасын.

Үтерүче, кулы белгәч,
Үзе таба хәйләсен.
Миннән калган кул сәгатьне,
Әткәй, үзең бәйләрсең.

Тюмень сулары бик салкын,
Күле дә бит бормалы.
Кайтам, дип йөргәч кенә
Илгә кайтып булмады.

Алмагачта алма булса,
Ала идем үрелеп.
Бу әҗәлләр миңа гына
Килде инде күренеп.

Мине батырган күлнең
Уртасы да тирән түгел.
Уфтанмагыз, моңаймагыз,
Ятим сез генә түгел.

Дөнья хәлен белеп булмый,
Бикле булсын келәгез.
Әнкәй, минем балаларга
Озын гомер теләгез.

Балаларымның исеме
Альберт белән Диана.
Әнкәгезгә, сез, әйтегез,
Булмасын үги ана.

Иртә торып тышка чыксам
Болыт каплаган күкне.
Альбина, мине онытма яме,
Таба алмассың минем күкне.

Сезгә хатлар язган чакта
Очсыз булды каләмем.
Альбина сезгә хатлар язса,
Миннән булмас сәламе.

Альбина, башыңдагы
бүрегеңне
Кечкенә, дип зурайтма.
Балаларым сау-тазалар
Кеше арасында моңайтма.

Бар документым да калды
Сервантның тартмасында.
Беттем дә мин, югалдым да
Отпуска атнасында.

Җир җиләге җыйган чакта
Җыйдым яфраксызын.
Минем гомер кыска булды,
Булсын кешенең озын.

Кызарып пешкән чагында
Җир җиләге тәмлерәк.
Әткәй-әнкәй атасыз үскән,
Ата белән ямьлерәк.

Кашларым кара булганга
Буятмадым кашымны.
Туганнар белән бергә-бергә
Әнкәй, ашый алмадык пешкән
ашыңны.

Яшь вакытта уйный идек
Түбәнге тарлауларда.
Минем кебек моңны агач
Үсә утырауларда.

Кошлар да бит очкан чакта
Таный әнекәйләрен.
Кеше күзләренә карап
Калды бәбекәйләрем.

Өемдәге гармунымның
Исемнәре Димьян.
Әткәй-әнкәй, туганнарым,
Калды минем семьям.

Яшь вакытта йөрәкле идеек,
Йөри идек пар атта.
Гәүдәм – Тюмень мичләрендә,
Көлләрем – зиратта.

Альбина, яшәгән чагында
Белдек тормыш кадерен.
Туган авылым зиратында
Булсын минем каберем.

Гомерем дә кыска булган
Белмәдем кадерләрне.
Әткәем, оятлык китермәдек,
Карап тор каберләрне.

Әбиемнән ерак түгел
Зиратта каберем.
Бергә-бергә бик күңелле
Белмибез шул кадерен.

Туган илемне яраттым
Мин һаман, Тюмень, дидем.
Әнкәй, үлгәч барсагыз да
Таный да алмас идең.

Миннән калган кул сәгатьне
Заводкасын дөрес итегез.
Әткәй, бәхиллегем шул
Тигез, тыныч гомер итегез.

Миннән калган киемнәрне
Тезеп чөйгә элегез.
Ачы җилләр, буран булса,
Мин елый дип, белегез.

Озын юлга чыккан чакта
Аерылмасын юлыгыз
Кайтыр, дип көтсәгез дә
Кайтмас инде улыгыз.

Әткәй-әнкәй, туганнарым,
Ташлар куярсыз язып.
Мине исегезгә алырсыз
Ташым каршына басып.

Минем кебек бик тә жалко
Үтермәгез бал кортын.
Мрамор ташлар астында
Булган мәңгелек йортым.

Чардуганым озын булса
Җитәр микән буегыз.
Әткәй, минем карточканы
Рамнатып куегыз.

Иртә торып битең югач,
Чәчегезне тарарсыз.
Онытмагыз, мине сагынганда
Шушы истәлеккә карарсыз.

Кусагыз да китмәс инде
Тәрәзәдән кошыгыз.
Соңгы күрешүне дә күршә алмадык,
Мәңгелеккә хушыгыз!

Илләремне бик сагындым
Булмады ялгыз тартып.
Әнкәй, ашың салма миңа
Калыр кашыгың артык.

Иртә торып тышка чыксам,
Каршыда кара урман.
Сез көтмәгез, мин кайта алмам,
Киттем мәңгелек юлдан.

Туганнарым, сезгә әйтәм
Булмагыз сез сабырсыз.
Бергә-бергә җыелганда
Мине дә исегезгә алырсыз.

Урындыкта утырып калды
Уйный торган гармуным.
Әллә шулай буласыга
Яшьтән үк булды моңым.

Йолдызкаем-йолдызкаем,
Яктырасың көн саен.
Кеше кулларыннан үттек
Сез үтмәгез, туганкаем.

*Сөйләүче: Семенова Анфиса*
*Макаровна (1941 елгы).*
*Ташлыяр авылы*

## Җырлар

Әйдәгез, туганнар, ерлашыек,
Ерлап яшәүләре лә күңелле.
Уйнап та ла, көлеп тату җөрик,
Уздырыек әле дә гомерне.

Менә бу, 1800 елларда безнең әнинең аталары егет чагындан, сабан туенда уен көенә җырлаган җыр. Әни яраткан көй инде бу. Бар инде дә сүзләр:

Сандугачлар сайрый, ай, чут-чут, дип,
Безнең илдән матур ла ил җук, дип.
Җирләребез ямьле, суыбыз тәмле,
Дусларыбыз бигрәк әйбәт, дип.

Су буйларыннан бара торгач,
Чыбык сындырып алдым ла таллыктан.
Алга таба шушылай йөрү өчен,
Ходай аермасын ла саулыктан.

Бу – XIX гасыр ахырында **сабан туенда** җырланган.
Табыннарда икенче көйләр булган:

Җырлап кына җырлап без карыйык,
Килешсә дә безнең лә көебез.
Килешсә дә безнең лә көебез,
Килешсә дә безнең көйләребез,
Ялан шулай бергәлә җөрербез.
Ялан шулай бергәлә җөрербез.

Кодаларга:

Эзләдек ти сезне, таптык сезне
Бакчаларда йөргәндәй эзегездән.

Бакчаларда йөргәндәй эзегездән.
Сезнең әйбәтлегегез шуннан беленә
Авызыгыздан чыккандай сүзегездән.
Авызыгыздан чыккандай сүзегездән.

* * *

Айлар ушбыдай дей, ай ушбыдай,
Ушбыдайлар түгел лә, ушбыдай.
Сезләрнедей безгә, безне сезгә
Сөеп кавыштырсайы бер Ходай.
Сезләрнедәй бездән, безне сездән
Аермасыныйла бер Ходай.

* * *

Владимир авыл көе, озын көй:

Әйдә лә дуслар җырлыйык әле
Авылыбыз көенә шул, авылыбыз көенә.
Шушыла көйгә лә без җырласак
Күңелебез сөенә.

«Владимир авылының уен көе бу. Болынга төшкәндә, печәнгә төшкәндә гел җырлап җөреләә ие, хәзер бетте ул.

Безнең әни әйтә ие, түбән очта бер гармунчы булган. Ә хәзер капка төбенә килеп җитәләр малайлар, нәрсә уйнаганын белмибез. Менә түбән очта уйный, ди, гармунчы безнең очка шуның көе – җыры аерым ачык билгеле, ди торган ие. Менә шул вакыттагы көйне әйтәм:

Актәй каеннарның өемнәре
Яфыраккай белән, туз белән, туз белән.
Җәйге уеннарның и ямьнәре
Кулларыннан тоткан кыз белән,
Ай жаный, асыл безнең ил.

Кәйтәннәрне кәйтән, ай итеек,
Җефәккәйне кәйтән итеек, итеек.
Киләсе җыл шушы вакытларга
Уйный гына көллә җитеек,
Ай жаный, асыл безнең ил.

Менә әниләр вакытында да шушы көйгә җырлаганнар, җегетләр җырлаганнар.

*Сөйләүче: Сапурина (Иванова)*
*Екатерина Гурьевна (1939 елгы).*
*Владимир авылы*

**Васфикамиләкәем**

Мәк чәчәге, мәк чәчәге,
Мәк чәчәге сөйкемле.
Сезне шулай күрәем
Таң йолдызы шикелле.

Васфикамиләкәем лә
Өзелә үзәкәем.

Өй артында шомыртым ла
Чәчәкләре хуш исле.
Мин шул чәчәкләргә карыйм,
Чөнки ул синең төсле.

Васфикамиләкәем лә
Өзелә үзәкәем.

*Сөйләүче: Миңнеханова Роза*
*Мөхәммәтҗан кызы (1935 елгы).*
*Кече Кирмән авылы*

**Ташлыяр**

Безнең авыл туры урам,
Авыл башы наратлык.
Ташламадык авылыбызны,
Бигерәк тә яраттык.

Кушымта:

Ташлыярым, Ташлыяр
Чишмәләре данлыклы,
Инеш буйлары таллыклы,
Сулары да балыклы.

Ташлыярның урамнары
Тар да түгел, киң түгел.
Кайбер йортларга карасаң,
Башка авылдан ким түгел.

Кушымта:

Ташлыярым, Ташлыяр
Чишмәләре данлыклы,
Инеш буйлары таллыклы,
Сулары да балыклы.

Ташлыярга кергән чакта
Старыйга ялгыш китмә.
Хезмәтне бик сөйгән генә
Авылда хезмәт итә.

Кушымта:

Ташлыярым, Ташлыяр
Чишмәләре данлыклы,
Инеш буйлары таллыклы,
Сулары да балыклы.

* * *

Сандугачның балалары
Талларны сыгылдыра.
Бергә чакта берни түгел,
Аерылгач, сагындыра.

Ат эчергән җирләремдә
Сызгыра торган идем.
Авыр сүзләр әйтергә дә
Кызгана торган идем.

Мич алдында капкач
Шап итәдер япкач,
Бик күңелле булыр әле
Сөяркәсе кайткач.

Сандугачларны санадым
Тезелеп кагынганда.
Инде кемнәргә карармын
Өзелеп сагынганда.

Мин менә «шаулый урман»ны җырлыйм. Кайберәүләр, сагындыра, дип җырлый, сагындырмый шул, җөрәккә төшкән сүзләр алар – ух алла арбасы:

**Шаулый урман**

Шаулый урман, шаулый урман
Җилләр искәнгә.
Әнкәем орыша иде,
Күтәртмәле чабатаны
Ике көнгә берне тишкәнгә.

Шаулый урман, шаулый урман
Җилләр искәнгә.
Бер онытылмый әнкәемнең
Нәләт төшкән ух алласы,
Әллә шуны тартып үскәнгә.

Шаулый урман, коела яфрак
Җилләр искәнгә.
Ташламадык әнкәйләрне
Суккан күлмәк, киндер ыштан
Суккан кием киеп үссәк тә.
Ташламагыз әнкәйләрне.

* * *

Озата барма, дускай, озата барма,
Олы юл бит, бәлки, адашмам.
Син бит минем яшьлек мәхәббәтем,
Башка күзләр белән алмашма.

Озата барма, дускай, озата барма,
Олы юл бит кайта алмассың.
Минем өстән башкаларны сөйсәң
Барыбер мине оныта алмассың.

Озата барма, дускай, озата барма,
Олы юлда ялгыз калырсың.
Мине ташлап башкаларны алсаң,
Гомер буе ялгыз калырсың.

* * *

Атларны да җиктем дә мин яратып, дусларым, сезгә әйтәм,
Кайтыр юлларга таба каратып.

Без китәбез сездән бик яратып, дусларым, сезгә әйтәм,
Сез калырсызмы икән яратып.

Урман урталарында, әй суларда, дусларым, сезгә әйтәм,
Казлар каңгылдашалар, дусларым.

Без китәсе, сез каласы, юлларыбыз, дусларым, сезгә әйтәм,
Көннәр килеп безгә дә якынлашалар.

Элекке өйдә сарайлар киң арада, дусларым, сезгә әйтәм,
Сандугачлар басып та сайраша.

Сезнең күңелләрегез әллә ничек, дусларым, сезгә әйтәм,
Безнең күңел сезләрне ярата.

Менә туй ашларда шушылай инде ул безнең керәшеннәрдә. Үзенә күрә җыруы бар, сүз белән әйтеп булмый бит, менә моң белән бирә. Утыра торгач җыру үзеннән-үзе килеп чыга. Бездә алып баручылар юк. Үзеннән-үзе кодалар алып бара.

* * *

Кайбер хатын морҗа бизи
Морҗасын сыламича,
Ир пешергән ашны ашамый
Бер генә җыламыйча.

Хатыннар күп төрлеле:
Кайсы була тегүче,
Кайсы була төрле яклы,
Кайсы була сүгүче.

Югары очка менеп җиткәч,
Наратлык ерак түгел.
Һушың булса бик пар булсын,
Бай булса, кирәк түгел.

Авыл күперен чыккач та
Чыш артына юллар бар,
Бик тиң булган мәхәббәтне
Шиш табарсың, эзлә, бар.

Бу җыр Ташлыяр авылы җирлегендә туган.

**Туй җырлары**

Җир дә җиләкләрен дә лә миннәр ашадым,
Чөмен өзеп җирләргә дә, әй, ташладым.

Сез дә кодалар безгә дә айларда килгәч
Аек баштан җырулар да, әй, башладым.

Түшләремә таккан да ла бишләр тәңкәмнең
Ничек итеп чутларым да, әй, алыем.

Килми генә килгәндә лә, ай, кодаларның
Ничек итеп күңелләрен, әй, табыем.

Килеп кенә кердегез дә, ай, өебезгә,
Гәрнитурлар элдең дә лә ай чөемә,

Гәрнитурдан тамганда ла тамчылар кеүек
Күрендегез минем дә лә, ай, күземә.

**Зимагурлар җыры**

Зимагурлар таллыкта
Кайгырмыйлар мал юкка.
Кайгырсалар кайгыралар
Тәмәкеләре юкка.

Зимагур ул ни кайгырсын –
Бармагы тулы йөзек.
Утлардан да, сулардан да
Барыбер чыга йөзеп.

Зимагур ул ник кайгырсын –
Кесәсе әллә ничә.
Үзең монда утырганда
Сыерың сатып эчә.

Зимагурлар янәшәңдә
Үзен мескенгә сала.
Исәнме, дип исәнләшмә,
Кесәңнән акчаңны ала.

Зимагурның ние булмас,
Муенында ципочкы,
Аягында тишек носки,
Авызында живачкы.

Зимагурлар килеп керә
Арт яктагы ишектән.
Үзенә кирәген алып,
Чыгып китә тишектән.

Яз көнендә зимагурлар
Куе-куе таллыкта.
Алар ник алай йөрмәсен,
Аталары председатель, аналары баныкта.

**Кара яулык**

Кошлар кайталар шулай, булса да җылы,
Бик күп бәхетсезләр туган сугышлар чыккан елны.

Кара яулык бәйләмәде шәле булган кешеләр,
Үткәндә сәлам бирмәде аталы үскән кешеләр.

Әңкәй кара яулыкларын басмага басып юган,
Басмага басып юган.

Шул суларда битен юган, шуңа бәхетсез булган.
Ул бит бәхетсез булганга без дә бәхетсез туган.

Кара яулыклар килешә, бәйли белсәң очларын.
Бөек Ватан сугышлары аталарны очлады.

*Сөйләүче: Семенова Анфиса*
*Макаровна (1941 елгы).*
*Ташлыяр авылы*

**Бишек җыры**

Хуплар хубый, алма кеби
Пешкән, тулгансың.
Син шул чагыңда, бу чагыңда
Матур булгансың.

Аппакаем, алмакаем,
Йоклаек икәү.
Йокла иркә, йокла бәбкә,
Бәбкә бәлли-бәү.

*Сөйләүче: Гыйлаева Земфира*
*Шакирҗан кызы (1949 елгы).*
*Түбән Шүләнгер авылы*

**«Баскан» көенә:**

Ал бидыраларың булгач,
Ал суның салкыннарын.
Уйлап чашам, җырлап басам
Йөрәгемнең ялкыннарын.
Уйлап чашам, җырлап басам
Йөрәгемнең ялкыннарын.

Менә моны мин бәләкәй чакта ук минем үги әтием җырлый торган ие. «Безнең Баскан» дие торганнар ие моны. Шуңар күрә моны онытмаска кирәк, – дип.

Исә җилләр, исә җилләр,
Искән җилләр пайдасыз.
Төннә төшләремдә күрәм,
Көндез әллә кайда сез.

Кулымдагы балдагымның
Исемнәре Хәдичә.
Сез куштыгыз, мин җырладым
Булдым инде сезнеңчә.

*Сөйләүче: Абдуллин Самат*
*Габдуллаҗан улы (1916 елгы).*
*Баскан авылы*

### Уеннар, аулак өйләр

**Түгәрәк уен** уйнау. Җегете чыга, кызмы чыга анда, шулай әйтешеп инде, шуңар кушып җыр җырлана. Түгәрәк уйныйбыз. Гармун булмаган көе уйныйбыз. Назаларны тел белән әйтеп. **Наза** уены бик матур була торган ие. Назада бер сыңар кеше була бит анда. Пар калмый, аңа шушы җыр җырлыйлар, ул тик тора:

Наза-Наза, Наза дигән кыз бала
Бөрлегәне түгелгән.
Көндә наза уйнаганга
Наза чыкмый күңелдән.

**Лапталы** уйный торган иек. Тупны бәрәләр дә бер ягы уйный, бер ягы уйнамый, шуны тотып алсаң, уен синеке була. Туп сыер җабагасыннан әвәләп ясый идек.

**Тупка талаш.** Менә капкага тупны бәрәсең, бөтен кеше ул тупны алырга тырыша, бөтен кеше. Тоталмаса, һаман шулай бара. Кем җитешә, тупны тота да ыргыта өлгер кеше. Туп өчен талаш.

*Сөйләүче: Сапурина (Иванова)*
*Екатерина Гурьевна (1939).*
*Владимир авылы*

**Туп белән уйнау.** Тупны башта үзебез ясый идек сыер җабагасын яз көне болай җүешләп (*уып-уып күрсәтә*). Сыерның мамыгы коела бит яз көне шуны туп итеп ясый идек. Сикертә торган туплар юк иде башта.

**Тау шуу.** Кыш көне кыршаулы әйбер булса, төбе дә булмый иде, әнә шуны әйләндереп куя идек тә, шуңар сыер бугы ягадырыек та, су сибеп катырадырыек та чуман белән әйләнә-әйләнә шуа торганыек таудан. Әйе чиләк купша инде. Элек бит ул теге карнауша диләр ие, түбәле әйберләр була ие.

**Мәлли.** Шакмаклар ясыйлар иде түгәрәк, нечкә. Кара-каршы тезәләр ие. Тукмак була торганые ата торган. Шуны атышып уйныйлар идее. Кем җыга, кем җыкмый.

**Биш таш.** 5 таш ала идек тә, ничә кеше кара-каршы утыраек та. Аның да биш таш, минем дә. Биш таш буладырие инде ташларны тезеп куясың. Дүртесен дүрт почмак кебек куясың, берсен уртага

куясың. Теге кеше ләшкәсе (таш) белән чирттереп җибәрә дә синекен чыгара, аннан теге кеше уйный. Кырыйдан ташларга тидерсәң – беткәнче уйныйсың, уртага тидерсәң –сразу җәза була.

Ул чакта уйнарга бирмиләр иде әниләр каз көттерәләр, биби көттерәләр иде. Чәчәкләр җыеп, ромашкалар җыеп такияләр үрә идек башка кия торган.

**Текән.** 6 шакмак. Иң беренчесенә ташны ыргытасың да сикереп шакмак саен бер аяк белән тибәсең, күчереп барасың. Таш сызыкка туры килсә, икенче кешегә чират күчә. Шакмакларны таяк белән сызып чыга идек.

*Сөйләүче: Долгова Нина*
*Григорьевна (1938 елгы).*
*Владимир авылы*

Кар бетүгә, әзрәк җир чыкса, җаланаяклап сызыклы уйнарга чыга идек. Таш атасың да этеп җибәрергә тиеш бер аякта. «Тут мы?» дигән булып күзне йомып сызыкка басмас өчен. Ике аяк белән. «Тут мы?». Сызыкка бассаң, не тут! ...

**«Чебенле».** Ул чебенлесе 2 җәплекә агач булырые. Кадап куясың дагын, җырактан басып, тегеңә җибәрәсең, тидерергә кирәк чтобы. Тисә инде икенче тимәгә син уйныйсың. Теге агач куелган аның башына ни. *X* – агачтан ясалган, җәплекә арасына куеп. Төшеп китәргә тиеш *x*. Агач белән ата идек, тәпәч шикелле бәләкәйрәк кенә агач ясый торган идек тотып ала торган. *X* бәләкәй генә була.

**«Әбәкле».** Бер кеше көтүче була дагын. Бер кешегә әбәк бирә дәген, йөгерәсең. «Әбәк» дип сугасың да йөгерәсең, ул куарга тиеш. Ул куып сине тота икән, син уеннан чыгасың, икенче кеше белән уйный башлыйлар. Лапки кебек.

**«Штуклы».** Бөтен кеше кача. Бер кеше кала. Гүрләй. Аның кулында таяк. Әгәр дә таба икән штук-штук дип исемен әйтә, таяк белән суга билгеләнеп куелган урынга. Иң элек кемгә таба – ул гүрли. Карамыйча гүр-гүр дисең, яисә санап торасың (гүрләү) шул арада бөтен кеше качып бетә.

**Аулак өй.** Кызлар егетләр белән сөйләшәбез. Кайсы өйдә икәнен сөйләшәсең. Әйберләр җыешабыз бер-беребездән, продукты. Бәлешләр салабыз, чәйләр куеп, кызлар-җегетләр аулак өй ясый торган ие. Менә бәйрәмнәр особенно шулай була торган иде,

октябрь бәйрәмнәрендә, әти-әниләр кунакка китәр ие. Анда җырлап, уйнап, кул эше эшләп башта. Берәр шәл читен бәйли торган иек, аннары уйнарга керешә торганыек. Җегетләр килгәч уйный торганыек. Ишек ачык инде анда, кем керә.

«Каеш сугышлы», «Йолдыз санашлы» дигән булып уйный торганыек.

**«Йолдыз санашлы».** Җәза биргәч йолдыз санарга кушалар. Сиңа костюмның җиңе була. Аркаң белән терәлеп утырасың да шуннан (җиң аша) йолдыз санарга тиеш буласың. Сиңа аннан су җибәрәләр (салалар). Җәза булгач. Бер кызны җегет тышка апчыгып китә торган ие. Аннан керәләр ие.

**«Инә яшерешле».** Кадыйсың бер җиреңә, шуны эзләп табарга тиеш икенче кеше, сыпырып-сыпырып бөтен җирне карыйлар ие.

*Сөйләүче: Миңнеханова Роза*
*Мөхәммәтҗан кызы. (1935 елгы).*
*Кече Кирмән авылы*

Кич белә качышлы уйныйдырыек, буралар булса дүрт почмаклы, унике таяклы дигән бер уен бар иде анда.

**Унике таяк.** Унике таякны җыеп куясың да, басып ишәсең, шул таякны җыеп бетергәнче качып бетәсең дә, качкан кешеләрне эзли, тапмаса, тагы кала, тапса, беренче тапкан кешене каравылга куша.

«Сызыклы» уйныйдырыек.»Тәкә ташлы».Биш таш дип атала бугай ул. Сикертеп бишкә кадәр менгезсәң тотасың, сикертеп менгезеп тотасың. Биш ташны чәчеп ташлыйсың да, кулны капка итеп ясап куясың да капкадан керттереп бетерәсең инде. Икенче кул белән бәреп җибәрәсең дә капкага керергә тиеш бишесе дә.

### Уен җырлары

Түгәрәк эчендә тотынып әйләнәсең дә җырлыйсың инде:

Җырлыйк әле, җырлыйк әле,
Җырлыйк әле, иптәшләр.
Иптәшләр үзебезнеке
Бәлки гаеп итмәсләр.

Җырлыйк әле, җырлыйк әле,
Җырлыйк әле өчне дә;
Җырламас идем өчне дә
Җырламый килешми дә.

Җырлыйк әле, җырлыйк әле,
Җырлыйк әле икене;
Җырламас идем икене,
Чөнки дусларым сөйкемле.

Җырлыйк әле, җырлыйк әле,
Җырлыйк әле дүрт булсын.
Уң кашларым, сул кашларым
Тарта хәерле булсын.

Җырлыйк әле, җырлыйк әле,
Җырлыйк әле алтыны;
Җырламас идем алтыны
Бүген безнең ял көне.

Җырлыйк әле, җырлыйк әле,
Җырлыйк әле җидене;
Җырламас идем җидене
Җырлавыгыз сөйкемле.

Шулай иттереп тезеп китәдериек инде. Уникегә тикле җырлыйдырыек.

*Сөйләүче: Газизова Хөснурый*
*Әһлулла кызы (1925 елгы).*
*Рече Кирмән авылы.*

**Тәгәрмәч тәгәрәтү.** Чыбык белән тәгәрмәч тә тәгәрәттек. Ул вакытта агач арбалар буладырые. Аның бүкәннәрен ике ягыннан кыршау белән кыршаулыйлар, төшеп китәрие дә коры вакытта, ул юлда ятырые да без аны алып кайтабыз да малайлар, тимер чыбыклар ул вакытта югие, чиләк колагыннан ясап, аның башына агач куеп, чыңгыр-чыңгыр барадырые, йөгереп барасың.

**Йомырка тәгәрәтү.** Йомырка җыяларые малайлар. Аны чирәмне генә урында инде, кайда корырак яр, сазлы булмаган җирдә тәгәрәтеп уйный идек. Кем ничә күкәйгә тидертә, аудара инде аны. Кайберсе 4–5 әрне ала, кайберсе берне дә алалмый.

*Сөйләүче: Семенов Илья*
*Сергеевич (1932 елгы).*
*Ташлыяр авылы*

**Уен.** Әни болай өйрәтәдерие: өстәлгә кулын куйдырта баш бармагы белән һәм:

Песнәк би-би-би,
Киндер орлыгын җый-җый,
Саесканның койрыгын
Ничә санасаң уналты.

Уналты дигәндә шап итеп куя да, кете-кете көлә бала-чага.

*Сөйләүче: Гыйлаева Земфира*
*Шакирҗан кызы (1949 елгы).*
*Түбән Шүләңгер авылы*

## Санамышлар

– Бөкре мулла кая киткән?
– Тозга киткән.

– Кайчан кайта?

– Яз кайта, яз кайтмаса көз кайта.

* * *

Ыргадан, быргадан
Мәче йөри елгадан
Шүләнгер авылында.

*Сөйләүче: Гыйлаева Земфира*
*Шакирҗан кызы (1949 елгы).*
*Түбән Шүләңгер авылы*

**Мәзәкләр**

Улы беренче класска барган. Укытучы сорау бирә икән:

– Кая, нинди җыр беләсең?

Ник инде, бәләкәй кеше бит инде ул әйме.

– Чабатага бака җигеп кунакка кил, матурым, – дигән укучы малай.

–Утыр! – дип әйткән укытучы.

*Сөйләүче: Мөхәммәтдинова Мәгъмүрә*
*Сәләхетдин кызы (1932 елгы).*
*Көмешкүл авылы*

Шушы Ишки җирлегендә туган бер мәзәк бар. Без бит инде сугыш чоры балалары. Гомер буе сугыш чорының авырлыклары ияреп килде. Без балалар үстергән вакытта тормышлар авыр ие. Балаларым йүнле иде минем. 8 бала бер заман. Аларның бу кайчан кайтканнарын, кайчан ашаганнарын, нишләгәннәрен белергә дә вакытыбыз булмады, һәрвакыт эштә. Алар уенчык белән дә уйный белмәделәр, уенчык алам, дип калага барасың мени инде. Аларның уенчыклары: кисәү агачы белән табагач – мылтык, уклау – автомат, урындыклар – машина-трактор, ашый торган калаклар – машина ачкычлары. Менә шулай уйныйлар иде алар. Бер көнне кич белән бер малаемның кайтмыйча калганы исемә килеп төште. Төннә уянып киттем – сәгать 11 ләр тирәсендә. Мин әйтәм безнең бер малай кайтмады, эзли башладык, мендәрләрне актарам, юрганнарны актарам. Әтисе әйтә, син аларны эзләп табалмассың инде ди аякларын гына сана, ди. Алар 8 бала булгач – 16 аяк булырга тиеш бит, ди. Саный-саный 15 аяк гына. Мин әйтәм 15 кенә аяк чыга бит.

Нишләп 15 кенә булсын, син әллә ычкындыңмы, безнең бөтен балаларның да аягы икешәр, бер аяклы бала юк бит безнең, ди. Актарабыз, чутлыйбыз, саныйбыз, һаман 15 кенә чыга. Мәйтәм, туктале, күрше Әминәгә кереп сорыйм, дим. Башлы хатын, белмичә калмас. Балаларның аяклары ничә дип сорыйм. – Син, ди, әллә ычкындыңмы, төнге сәгать 12 дә кереп уятыр идеңме. Минәйтәм син дә белмисең, мин дә белмим, математикадан көчкә-мөчкә 3–4 легә укыдык та, саный белмибез ай мин әйтәм тукта әле, эзлик әле, саныйк әле яңадан, санаган идек берсе аягын бөкләп яткан икән, чыкты инде 16, барсы да кайткан булып чыктылар.

*Сөйләүче: Гафурова Саҗидә*
*Газим кызы (1938 елгы).*
*Ишки авылы*

## Халык сүзләре, мәкаль-әйтемнәр

Кошның матурлыгы төсе белән,
Кешенең матурлыгы эше белән.

Киләчәк бүген башлана.

Ашап-эчкәндә дус яхшы,
Кайгылы көндә үз яхшы.

Җирне сөйгән ач булмас.

*Сөйләүче: Семенов Илья*
*Сергеевич (1932 елгы).*
*Ташлыяр авылы.*

Шәүлегән су чыгарган,
Карга-козгын кинәнгән.

Яшим әле, яшим, дигән – үлеп киткән,
Үләм инде, үләм, дигән – йөзгә җиткән, ди.

*Сөйләүче: Семенова Анфиса*
*Макаровна (1941 елгы).*
*Ташлыяр авылы*

Күз кешене – гүргә, малны казанга кертә.

*Сөйләүче: Мөхәмәтдинова Мәгъмүрә*
*Сәләхетдин кызы (1932 елгы).*
*Көмешкүл авылы*

# НАРОДНОЕ МУЗЫКАЛЬНОЕ ТВОРЧЕСТВО: ПРОШЛОЕ И НАСТОЯЩЕЕ

*Эльмира Каюмова*

В основу статьи лег экспедиционный материал, собранный автором в июне 2013 г. С этномузыковедческой точки зрения обследовано 26 населенных пунктов. Опрошено более 100 информантов. Этнические группы: казанские татары (мусульмане) и кряшены (христиане). Рассмотрим обе народные музыкальные традиции и их состояние более подробно.

### Музыкально-поэтическое творчество татар-мусульман

Записанные от татар-мусульман образцы можно распределить по следующим разделам: 1) песенный фольклор – песни (лирические, игровые), такмаки; 2) жанры «книжного интонирования» – баиты, мунаджаты, книжные напевы; 3) религиозная музыка – коранические распевы, азаны, салаваты, зикры; 4) детский фольклор – колыбельные песни; 5) инструментальные наигрыши; 6) композиторская музыка. Удалось побывать в музее знаменитых музыкантов Яруллиных (Загидуллы, Фарида и Мирсаида), расположенном в д. Малая Сунь (Кече Сөн)[1].

**Песенный фольклор.** В качестве *авыл көе*, исполняемых обычно во время проводов солдат, молодежных уличных гуляний, сбора подарков перед сабантуем и т.д., бытовали популярные напевы «Шахта» (дд. Н. Ошма, Тулбай), «Герман» (дд. М. Кирмени, Сартык), «Алмагачы» (дд. Усали, С. Кирмени, Ишкеево, Шемяк, Сартык, Тулбай), «Сарман» (дд. Н. Ошма, Тулбай), «Озату»

---

[1] Местное население произносит *Сон*: *Кече Сон*, *Түбән Сон*, *Югары Сон*.

(д. Н. Таканыш), «Ак Иделнең парахоты» («Кибәче авылы көе», д. Кук-Чишма), «Уйна, дустым, гармуныңны» (дд. Шадчи, Ишкеево).

Особой любовью пользовалась песня «Уракчы кыз». Об этом свидетельствует тот факт, что существовавший в конце 1970-х – начале 1980-х гг. фольклорный ансамбль д. Олуяз носил имя этой песни. «Уракчы кыз» занимает прочное место и в репертуаре современных исполнителей, среди них – детский фольклорный коллектив д. М. Кирмени (руководитель – Ф. Дульмиев).

В музыкальном быту были распространены такие общеизвестные образцы, как «Сибелә чәчем», «Алтын алка», «Идел бит ул», «Күбәләгем», «Туган тел», «Җаныем-бәгърем», «Түгәрәк күл», «Мәдинә-гөлкәем», «Рамай», «Гөлҗамал».

Оригинальную подборку из десятков куплетов, начинающихся с одинаковых слов («Кулымдагы йөзегемнең», «Агыйдел»), на мелодии игровых песен исполнила солистка фольклорного ансамбля д. Ишкеево Х.М. Валиуллина (79 лет) – см. Приложение I, № 4.

Кроме того, зафиксированы редко встречающиеся примеры: «Төлке төшкән тарлауга», «Элмәлек» (башкирская) – в д. В. Сунь, от Г.Х. Фаляховой, 1950 г.р.; «Батыр егетләр» (про воинов-афганцев), «Кыр батырлары» (перетекстовка советской песни «Три танкиста» – муз. Братьев Покрасс, сл. Б. Ласкина) – в д. Н. Яки, от М.М. Мубаракшиной, 1942 г.р.

Круг игровых песен образуют «Чүпләмле» (дд. Н. Ошма, Олуяз, Н. Сунь), «Ал чия төпләрендә» (дд. Ишкеево, В. Сунь), «Наза» (или «Назалы» – дд. Ишкеево, Н. Таканыш), «Бас әле станокка» (д. Н. Сунь), «Суда, суда», «Талы, талы» (д. Уразбахтино), «Шәл бәйләдем» (д. Ишкеево), «Боз көе» (д. Олуяз), «Бармак уены» (д. Шадчи).

Колыбельные песни записаны в селениях Шемяк (Шимәк), Нижняя Сунь (Түбән Сөн), Верхний Берсут (Югары Кыерлы), Сартык (Сәртек), Уразбахтино (Уразбахты).

